www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 38 (1454) 29 сентябрь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

5

Үзе исән вакытта ике генә китап чыгарып өлгерсә дә, Норлат егете Ирек Диндаров татар дөньясында талантлы журналист һәм өметле каләм иясе булып танылган иде.

14-15

1757 елда Пруссия походына барган рус гаскәре сафында 500 кешелек татар-башкорт җайдаклары да барган, аларны Актаныш районындагы Такталачык морзасы Тимер Мутин җитәкләгән.



16-17

Совет хәрби разведкасын данга күмгән каһарманнар арасында әтисе – немец, әнисе рус вәкиле булган Рихард Зорге аерым урын алып тора.

Дәвер-буыннарны тоташтырып, Әдип рухын саклый бу нигез!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Бөтендөнья мирас комитетының Согыд Гарәбстанында узган киңәйтелгән 45 нче сессиясендә Казан университетының Энгельгардт обсерваториясе ЮНЕСКО мирасы объектларына кертелде.

● РФ премьер-министры Михаил Мишустин карары нигезендә, Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы пилотсыз очкычларын кертү буенча эксперимент үткәреләчәк төбәкләр исемлегенә кертелде.

● Татарстан Рәисе Р.Миңнеханов һәм Үзбәкстан премьер-министры А.Арипов IT-парк мөмкинлекләре белән танышу максатыннан Б.Рәмиев исемендәге IT-паркта һәм Казанның 21 нче мәктәбендә булды.

● Казанда әдәбият белгечләре, журналистлар, язучылар һәм шагыйрьләр катнашында язучы Василий Аксеновның тормышы һәм иҗатына багышланган «Аксенов-фест» фестивале узды.

● Кировта беренче тапкыр 300 талантлы музыкант, шул исәптән Татарстан Республикасының дәүләт академия симфоник оркестры катнашында Россиянең симфоник оркестрлары фестивале узачак.

● Татарстанда граждан авиациясе пилотларын һәм һава судноларына хезмәт күрсәтү техникларын әзерләү буенча очу мәктәбе ачыла.

● Республикада яшәүчеләргә мәгълүмат бирү, табибка язылу, поликлиникага беркетү һ.б. төрле ярдәм күрсәтү буенча Татарстанда Сәламәтлек саклау министрлыгының бердәм контакт-үзәге булдырылды.

● Россия рестораторлары һәм отельерлары федерациясенең Татарстандагы вәкиллеге башлыгы Нурислам Шәрифуллин республика учреждениеләрендә аш-су осталары һәм барменнар җитешмәгәнлеген белдерде.

● Санкт-Петербургта узган Андрей Петров исемендәге Халыкара композиторлар конкурсында Эльмир Низамов иҗат иткән Эльмира Кәлимуллина башкаруындагы «Мин җырымда калам» җыры финалга узды.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

29 сентябрь – рәссам, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның халык рәссамы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Сергей Осипович Лывинның тууына 100 ел (1923–2000).

1 октябрь – халык музыка уен коралларында уйнау остасы, ТАССРның атказанган артисты Фәйзи (Фәйзерахман) Бикмөхәммәт улы Биккининның тууына 125 ел (1898–1968);

– театр рәссамы, нәкышче, Башкортстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Таң Гомәр улы Еникеевка 75 яшь (1948).

5 октябрь – шагыйрә Зәйнәп Хуҗихан кызы Бәшированың тууына 120 ел (1903– 1984);

– Яшел Үзән фанера заводы төзелүгә 125 ел (1898).

СЫНАМЫШЛАР

1 октябрьдә кыр казлары китсә, Покрауда (14 октябрьдә) кар ятар ● Октябрьдә шөпшә һәм төклетуралар күренсә, кыш суык булыр ● Чия яфрагы коелып бетмичә, кар ятмый.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 42 минутта** чыкты, һәм ул **17 сәгать 28 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **11 сәгать 46 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **39 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **6 октябрьдә 11 сәгать 07 минут** тәшкил итәчәк.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Сентябрь-октябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 29 сентябрь, 1, 2, 4 октябрь.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(29 сентябрь-6 октябрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1445 ЕЛ

Бүген рабигүл әүвәл аеның 14 нче көне

ҖАН АВАЗЫ



Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ

БЮДЖЕТ – ТОРМЫШ КӨЗГЕСЕ

Законнар әзерләү, республика бюджеты үтәлеше барышын даими күзәтеп тору, ихтыяҗ булган саен аңа төзәтмәләр кертү – Татарстан Дәүләт Советы депутатларының төп бурычларыннан берсе. Депутатлар бюджетны тормышыбызның көзгесе, илнең иң мөһим финанс документы дип исәпли.

Гадәттәгечә, бюджеттан акча алучы министрлыклар белән киңәшмәләр үткәрелә. Ведомстволарның ихтыяҗлары бюджет мөмкинлекләре белән чагыштырыла. Барлык эре салым түләүчеләр белән алдагы елга матди байлык җитештерү динамикасы һәм перспективалары, салымнар һәм җыемнар күләме буенча күп тапкыр консультацияләр үткәрелә. Җирле бюджетларның салым базасы, ул территорияләрдә салым түләүче предприятиеләрнең үсеш перспективалары хакында җирле хакимиятләр вәкилләре белән очрашулар оештырыла. Соңгы елда да килеп туган бюджет каршылыклары турында һәр район һәм шәһәр вәкилләре белән очрашулар булды.

Зона киңәшмәләре дә оештырыла. Аларга янәшәдә урнашкан берничә районның, шәһәрнең вәкилләре җыела. Бу киңәшмәләр эшендә Дәүләт Советы рәисе, аның урынбасарлары, даими комиссияләр рәисләре, премьер-министр катнаша, алдагы ел бюджетын формалаштыручының аерым проблемаларын хәл итү юлларын эзләүгә, бюджетларда мөнәсәбәтләрне камилләштерүгә кагылышлы мәсьәләләр күтәрелә. Бу киңәшмәләрдә әйтелгән тәнкыйть фикерләре, тәкъдимнәр анализлана, бюджетны эшләүне дәвам иткәндә алар мөмкин кадәр искә алына.

Республика җитәкчесе Р. Миңнеханов та бюджет проекты эшләнешен үз контролендә тота, аны әзер дип тапкач кына Дәүләт Советына җибәрә. Донор төбәкләрне стимуллаштыру системасы кулланыла. Аның мәгънәсе көйләүче салымнардан һәм керемнәрдән донор төбәкләр өчен өстәмә өлеш чыгарудан гыйбарәт. Шул рәвешле бюджетның чыгым күрсәткечләре гражданнарны социаль яклаулы, җирле үзидарә органнарын, бюджет оешмаларын, матди өлкәнең өстенлекле тармакларын түбәндәгерәк бюджетларга дотацияләр бүлүне таләп итә.

Бюджетның икенче юнәлеше – товар җитештерүчеләргә реаль ярдәм күрсәтүгә, «Татнефть»кә, АлАЗга һәм КамАЗга традицион салым ташламаларыннан тыш, бюджетта беренче тапкыр булларак, башта промышленность предприятиеләренә ярдәм чаралары чагыла. Беренчедән, промышленность предприятиеләре өчен лизинг фонды оештыру аша стимуллаштыру аркылы. Агымдагы салымнарны вакытында түләүче промышленность предприятиеләре табыш салымыннан азат ителәләр. Беренче тапкыр буларак, җиңел промышленность предприятиеләренә салым ташламалары ясау рәвешендә максатчан ярдәм күрсәтелә. Болардан тыш хөкүмәткә халык куллану товарлары җитештерү производстволарын киңәйтү һәм яңаларын оештыру буенча хупланган бизнес проектларын гамәлгә ашыру өчен промышленность предприятиеләренә инвестиция салым кредитлары бирергә рөхсәт ителә.

Бюджетның керемнәр өлеше бюджетның чираттагы бәяләреннән көтелә торган, икътисад һәм сәнгать министрлыгының алдагы елга социаль-икътисадый үсешенең фаразланган күрсәткечләреннән чыгып формалаштырылды. Бер үк вакытта микроикътисадый дәрәҗәле, икенче төрле әйткәндә, икътисадның әйдәп баручы тармакларын һәм бюджетны формалаштыручы предприятиеләрне үстерү буенча фараз күрсәткечләреннән дә файдаланыла.

Нефть, газ, химия һәм машина төзелеше тармаклары республика икътисадының нигезен тәшкил итә. «Без «Татнефть» компаниясенә нефть чыгаруда һәм эшкәртүдә чит ил товарларын алыштыру эше белән системалы шөгыльләнгәне, чит ил тудырган кыенлыкларны җиңүдәге уңышлары өчен зур ихтирам. Бу – эшне илебез технологияләрен һәм җиһазларын файдаланып оештыруның бер мисалы, – диде республика җитәкчесе Р.Миңнеханов парламентка юлламасында. – Нефть компанияләре нәтиҗәле хезмәт күрсәтте. Аларны оештыру турындагы карарны Татарстанның беренче Президенты М.Шәймиев 25 ел элек кабул иткән иде. Шул вакыт эчендә бу кече компанияләрнең өлеше 3 проценттан 20 процентка күтәрелде».

Узган ел йомгаклары буенча Татарстанның 36 миллион тонна нефть чыгару мәгълүм.

«ТАНЕКО» компаниясендә нефть чималын кабул итү һәм эшкәртү буенча җиһазларның башлангыч куәтен елына 16,3 миллион тоннага кадәр арттыру (мазут җитештерүдән тыш), дүрт яңа җайланманы файдалануга кертү юнәлешендә зур эш башкарыла.

«ТАИФ–НК» шулай ук нәтиҗәле эшли. Болар һәммәсе чимал эшкәртүне 23 миллион тоннага җиткерү мөмкинлеген тудырачак. «СИБУР» компаниясе «Түбән Кама нефтехим» һәм «Казан органик синтез» предприятиеләрендә этилен һәм поликарбонат заводларын яңартып кору, электр энергиясен җитештерү җайланмалары төзү кебек инвестиция проектларын гамәлгә ашыру дәвам итә.

2024 елда ЭП–600 олефиннары җитештерү буенча яңа компанияне сафка кертү планлаштырыла.

Моннан тыш «СИБУР» һәм «Алабуга» махсус икътисади зонасы Түбән Камада индустрия паркын ачу турында килешү төзеде. «Түбән Кама Нефтехим» чыгара торган продукциянең төрлелеге арадаш тармакларда җитештерүне үстерү өчен киң мөмкинлекләр ача.

Татарстанда 37 газ ягулыгы сату станциясе, 3 крио автомобиль ягулыгы салу станциясе урнашкан. Тагын 9 ягулык салу станциясен төзү эшләре алып барыла. «Алабуга» махсус икътисади зонасындагы «Данафлекс» компаниясе кабаттан эшкәртеп була торган яңа төр пленка материаллары җитештерү буенча 2,5 миллиард сумлык проектны гамәлгә ашыра.

Машина төзелеш өлкәсендә КамАЗда җитештерү күләмнәрен саклап калу буенча эш алып барыла. Предприятия модельләрне арттыруны дәвам итә. Бу завод сыйфаты яхшыртылган, чит ил товарларын алмаштыру программасы тулысынча тәгәлләнгән яңа буын К-5 йөк машиналарының тулы бер модельләр сафын җитештерә башлаячак.

Казан авиация заводын яңартып кору эшләре дәвам итә. Предприятие алдында гражданнар өчен ТУ–214 очкычларын серияле рәвештә җитештерүне елына 20 очкычка җитештерү бурычы тора. Казан вертолет заводы быел «Ансат» вертолетларын җитештерүдә чит ил товарларын алмаштыру программасын тәмамлауны планлаштыра. Барлык модельләр буенча җитештерү күләмен елына 100 вертолеттан да кимрәк булмаслык итеп саклап калу мөһим.

Зеленодольскийның А.Горький исемендәге заводы узган ел беренче «Метеор»ны куллануга тапшырды. Ул пассажирлар флотын торгызуны тәэмин итәргә тиеш. Зур компанияләр белән беррәттән, Чистайда «Бетар» компаниясе робот-манипуляторлар җитештерү буенча яңа мәйданчык ача. «Меттем» компаниясе автомобильләр төзү тармагы өчен электр компонентларын җитештерүне башлап җибәрде. Бөгелмәдә «НТЭС» компаниясе кече төягеч машиналар чыгаруны җайга салды.

Илебез Президенты В.Путин гаскәрләрне заманча корал һәм техника белән тәэмин итүне кыска гына вакыт эчендә арттыру бурычын куйды. Бүген Татарстан оборона-җитештерү комплексы предприятиеләре аны үтәүдә катнаша һәм дәүләтебез иминлеген тәэмин итүгә зур өлеш кертә.

Элеккечә үк керемнәрнең төп чыганагы булып өстәмә бәяләргә, табышка салымнар, акцизлар, физик затларның керемнәренә салымнар кала. Соңгы елларда алар тупланган бюджетның керемнәре гомуми сумма 50-70 процентын тәшкил итә.

Тупланган бюджетның керемнәр өлешендә өстәмә бәяләр салымы 20 процент тәшкил итә. Шәһәр һәм районнарның җирле бюджетларын физик затларның керем суммасы, милеккә салым, табыш салымы исәбенә формалаштыру төп юнәлешкә әверелеп бара. Сатудан салым, җир асты байлыклары өчен түләү, җир салымы республика, шәһәр һәм район бюджетларына законнарда билгеләнгән ныклы нормативлар буенча күчерелә.

(Дәвамы 4 нче биттә).

Таулы Карабахта капитуляция

19 сентябрьдә Әзәрбайҗан Таулы Карабахта «конституцион тәртипне саклау» максатыннан антитеррор операциясен игълан итте. Әзәрбайҗан белдерүенчә, тынычлык урнаштыру өчен, әзербайҗаннар алдында Карабахтан әрмән хәрбиләрен чыгару һәм Степанакерттагы режимны тарату бурычы тора иде. Әзәрбайҗан җитәкчелеге әйтүенчә, алар Таулы Карабахтагы хәрби көчләрне юк итәргә теләгән.

Таулы Карабах территориясендә урнашкан әрмән формированиеләре коралларын ташлый. Бу – башка кораллы көчләргә дә кагыла. Алар барысы да хәрби позицияләрен калдыра. Барлык законсыз формированиеләр таратылырга тиеш.

Советлар Союзы вакытында башлыча әрмәннәр яшәгән Таулы Карабах Әзәрбайҗан автономиясе иде. Үзгәртеп кору елларында Таулы Карабахтагы әрмәннәр белән азәрбайҗаннар арасында сугыш башлана. Бу сугышта Әзәрбайҗан җиңелә, Әрмәнстан Таулы Карабахны гына түгел, Әзәрбайҗанның 7 районын басып ала, андагы халыкны куа.

2020 елгы сугышта Әзәрбайҗан Таулы Карабахта җиңүгә ирешә. 1988-1992 елгы сугышта оттырган 7 районны һәм Таулы Карабахның бер өлешен – Шуша шәһәре тирәсен Әзәрбайҗанга кайтарды. Төбәккә Россия хәрбиләре тынычлык урнаштыру көчләре буларак кертелде. Таулы Карабахның бер өлеше әрмәннәр контролендә калды. Алар Лачын шәһәре янындагы юл аша Әрмәнстан белән бәйләнештә иде.

Соңгы вакытларда бу төбәктә вазгыять катлауланды. Атышлар да булды, Лачын коридорына бәйле конфликтлар да башланды. Ике як та бер-берсен 2020 елгы килешүне сакламауда гаепләп килде.

Әзәрбайҗан Таулы Карабахны үзенең төбәге дип саный һәм анда контроль урнаштырырга тели. Искәртеп үтик, Таулы Карабахны Әрмәнстан җитәкчелеге рәсми рәвештә үз территориясе дип беркайчан да атамады һәм әле дә атамый.

Таулы Карабах җитәкчелеге 19 сентябрьдә үк әзербайҗаннарның Карабах төбәген утка тотуы турында хәбәр итте. Карабах җитәкчелеге бу операцияне, тулы масштаблы сугыш, дип белдерде. «Сугыш һавада да, җирдә дә бара. Степанакертка әле кермәделәр. Соң көчкәчә сакларга тырышачакбыз», – дигән Карабахның элекке дәүләт министры Рубен Варданян.

Степанакерт Әзәрбайҗаннан сугышны туктатуны һәм тынычлык турында сөйләшүләр башлауны сорады. Әрмәнстан Берләшкән Милләтләр оешмасын Әзәрбайҗанга каршы чаралар күрергә чакырды. Әрмәнстанның премьер-министры Никол Пашинян Әзәрбайҗан җитәкчелеген гаепләп чыгыш ясады. Аның әйтүенчә, Әрмәнстан хәрбиләре сугышта катнашмый. Әрмәнстанның үзендә Пашинянга каршы митинглар башланды һәм өзлексез рәвештә дәвам итә. Ә Россия хәрбиләре күзәтүе астында Карабахтагы әрмәннәрне хәрби машиналарга утыртып, Әрмәнстан территориясенә күчерүләр бара.

Россия ике яктан да сугышны туктатуны сорап карады. Бер тәүлек вакыт узуга ук, Әзәрбайҗанның Саклану министрлыгы Таулы Карабахта «террорчылыкка каршы операция»не туктату турында рәсми рәвештә игълан итте. URA.RU конфликтның нинди шартларда туктатылуын кыскача аңлата.

Капитуляция шартлары буенча, Әзәрбайҗан Таулы Карабах армиясенең калган өлешләрен һәм халкын эвакуацияләү өчен «коридор» бирергә тиеш булачак. Карабахның халкын эвакуацияләүдә Россиянең тынычлык урнаштыручы көчләре катнашты. Алар шулай ук Әзәрбайҗанның Карабахтагы операциясен туктатуга ярдәм итте.

Әзәрбайҗан 21 сентябрьдә Таулы Карабах халкы белән тынычлык сөйләшүләре уздырды. Диалогта ил президенты Илһам Алиев та катнашты. Шул ук вакытта Ереванда Карабахтагы әрмән халкының Баку белән сөйләшүләргә әзерлеген аңлыйлар, дип хәбәр итә Reuters.

РФ Оборона министрлыгы Россия тынычлык урнаштыручыларының Таулы Карабахта капитуляциядән соң үз миссияләрен дәвам итүләрен раслады. Тыныч халыкка ярдәм итү дәвам итәчәк.

Әзәрбайҗан белән кораллы бәрелешләр барышында Карабах армиясе тәүлек эчендә 1000нән артык кешесен югалтты. Шулай ук танылмаган территория сугышчыларының хәрби коралларын беткән, дип хәбәр итә «Baza». Үз чиратында, Бакуның Кораллы көчләре 500 кеше югалткан. Шул ук вакытта Әзәрбайҗан ягыннан 60 мең кешелек армия чыгуы билгеләп үтелә.

Югарыда әйтелгәнчә, Карабахта террорчылыкка каршы операция – ике як арасында беренче генә хәрби бәрелеш түгел. Таулы Карабах – Закавказье төбәге, анда танылмаган Таулы Карабах Республикасы (НКР) урнашкан. Бу территория тирәсендә беренчә тапкыр хәрби бәрелешләр булды. Беренче Карабах Кораллы низагы 1992 елдан 1994 елга кадәр барды. Икенчесе – 2020 елның 27 сентябреннән 10 ноябренә кадәр. Нәтиҗәдә, Әрмәнстан премьер-министры Никол Пашинян, илнең хәзерге хакимияте Таулы Карабахны Әзәрбайҗанныкы итеп таный, дип раслады.

intertat.tatar.

Нәзарәт янә чакыра

Диния Нәзарәте намаз укырга һәм Ислам дине нигезләренә өйрәтүче «Ислам. Беренче адымнар» курсларының 12 нче сезонына тыңлаучылар җыя башлады. Укулар шушы елның 14 октябрендә башлана. Шәкертләр кыска вакытлы курс дәвамында – 8 гадәти дәрес эчендә (атнага бер тапкыр) – намаз укырга һәм Ислам дине нигезләренә өйрәнә алачак. Дәресләр түләүсез. Курсларга инде язылу башланды.

Беренче кереш дәрес 2023 елның 14 октябрендә Нәзарәт бинасында (Г.Тукай ур., 38) иртәнге сәгать сигездә (8:00) уза. Дәресләрне мөфтиятнең яшь волонтерлары алып бара. Аерым алганда, шәкертләр госел һәм тәһарәт алырга, намаз укырга өйрәнәчәк; гакыйдәнең асылына төшенәчәк, сира – Мөхәммәд пәйгамбәрнең ﷺ тормышы белән танышачак, ураза тәртипләре буенча дәресләр тыңлаячак.

Ислам динендә беренче адымнарын ясаучылар һәр атнаны шимбә көнне иртәнге сәгать 08.00дән көндезге сәгать 12.00гә кадәр Казанның Галиев мәчетенә (Г.Тукай ур., 40) җыелачак.

Соңгы дәрес – 2 декабрьдә – ул көнне Коръән мәҗлесе, курсларга йомгак ясау, сертификатлар тапшыру көтелә.

«Ислам. Беренче адымнар» проекты ислам дине кушканча яшәргә теләүче, әмма 5 ел дәвамында мәчет каршындагы курсларга йөрергә мөмкинлеге булмаган кешеләр өчен махсус оештырыла. Укулар татар һәм рус телләрендә алып барыла.

Курсларда катнашу өчен 13 октябрьгә кадәр https://clck.ru/EZQEj сылтамасы буенча кереп теркәлергә яки +7 (843) 237-86-18 телефоны буенча шалтыратырга кирәк.

Эльмира СИРАҖИ.

1 нче биттә – Актаныш районының Уразай авылында Риза Ишморат тууга 120 ел тулу тантанасыннан бер күренеш. В.Имамов фотосы.

Уралдагы авылда татар телен саклау оешмасы

Свердловск өлкәсендәге Коншак районының Бәгәрәк Тамагы авылында коммерцияле булмаган «Чиләбе өлкәсе Коншак муниципаль районы Бәгәрәк Тамагы авыл җирлегенең татар мәдәниятен, традицияләрен һәм телен саклау һәм үстерү буенча җирле иҗтимагый оешмасы»н төзегәннәр. Бу хакта Татарстанның Свердловск өлкәсендә Даими вәкиллеге хәбәр итә.

Оешманың максаты — авыл җирлегендә татар мәдәниятен, гореф-гадәтләрен һәм телен саклау һәм үстерү өчен гражданнарны берләштерү. Оешма юридик зат булып санала һәм 2023 елның 31 июлендә Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Чиләбе өлкәсе буенча идарәсендә теркәлгән.

Оешма советы рәисе итеп Эльза Газизова сайланган. Ул — җәмәгать эшлеклесе һәм Бәгәрәк Тамагы авылы туган якны өйрәнү музее җитәкчесе, 2001 елдан 2017 елга кадәр Бәгәрәк Тамагы авыл җирлеге башлыгы булган. Ул елларда ул авылның социаль-икътисади үсеше өчен бик күп эшләр башкара. Хәзер аның тәкъдиме белән җитәкчелек, халык һәм җирле эшмәкәрләр ярдәме белән Бәгәрәк Тамагы авылы үзәгендә Җәмигъ мәчете төзелеше тәмамлана.

Яңа иҗтимагый оешманың мөһим эшләренең берсе — Бәгәрәк Тамагы авылы урта мәктәбендә татар теле кабинетына капиталь ремонт. Бу елның 1 сентябрендә яңартылган татар теле кабинеты укучыларга үз ишекләрен ачкан. Алга таба кабинетны уку һәм методик әдәбият белән тулыландыру таләп ителә. Авыл халкы һәм укытучылар Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм республика югары уку йортлары ярдәменә өметләнә.

Татар теле кабинетында түшәм һәм стеналар, идәнне тулысынча штукатурлаганнар, керамик гранит плиткалар җәйгәннәр, яктырткыч приборларны, тәрәзә кәрнизләрен алыштырганнар, яңа пәрдәләр элгәннәр. Болар барысы да иганәчеләр һәм җирле халык акчасына эшләнгән. Район мәгариф идарәсе яңа җиһазлар сатып алган. Янгынга каршы яңа ишек һәм аның өстенә такта урнаштырганнар, диелә хәбәрдә.

tatar-inform.tatar.

Балашихада газ шартлау

Мәскәү өлкәсенең Балашиха шәһәрендә газ шартлау нәтиҗәсендә күпкатлы йорт зыян күргән. Бер кеше һәлак булган, тагын ике кеше җәрәхәтләр алган. Бу хакта РИА Новости хәбәр итә.

Октябрь урамындагы йортның дүртенче катында шартлау булган. Нәтиҗәдә, өченче, дүртенче һәм бишенче катлар җимерелеп төшкән. Ким дигәндә 10 фатир зыян күргән.

Хәзерге вакытта урында ашыгыч хезмәтләр эшли, зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтелә. Исән калучыларны эзләүче коткаручылар өстенә стена ишелеп төшкән. Куркыныч кадрлар интернетта чыкты.

Беренчел мәгълүматларга караганда, коткаручылар җимерекләр арасында кычкырып яткан хатын-кыз белән баланы чыгармакчы булган. Йорт стенасы икенче тапкыр ишелеп төшкәннән соң, аларның тавышлары бөтен ишетелмәгән. Стена җимерелгәнче, коткаручылар 3 нче каттагы фатирга төшкән плитәләрне күтәрергә тырышкан. 36 яшьлек хатын-кыз һәм аның 5 яшьлек кызы 5 нче каттан төшкән плитәләр астында калган.

Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы



һәлак булган хезмәткәрләре турында мәгълүмат чыгарды. Алар – Магомед Нальгиев һәм Олег Калмыков.

«Бу – безнең хезмәткәрләрнең гаиләләре һәм ведомство өчен зур югалту. Башкалар хакына үз гомерләрен корбан иткән коткаручыларның батырлыгы безнең йөрәкләрдә мәңгегә калыр... Без барыбыз да бер эшне сайладык – кешеләрне коткару. Геройларны онытмыйк», – диде Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы башлыгы Александр Куренков.

Мәскәү өлкәсе Сәламәтлек саклау министрлыгы түбәндәге саннарны җиткерде: Балашихадагы фатирда газ шартлаудан 5 кеше һәлак булды, 13 кеше зыян күрде. 7 кеше хастаханәдә ята, 6 кеше хастаханәгә барудан баш тарткан.

intertat.tatar.

Вәһапов исемендәге XX фестиваль җиңүчеләре

● Гран-при иясе Дамир Таипов.

19 сентябрьдә Казанның Зур концертлар залында Рәшит Вәһапов исемендәге фестивальнең егерменче юбилей концерты узды. Анда Р.Вәһапов исемендәге XX Халыкара татар җыры фестивале лауреатлары ачыкланды.

Беренче урынга лаек булучылар:

«Камера-концерт җырын башкару» номинациясендә Руслан Закиров (Казан шәһәренең балалар иҗаты үзәге хезмәткәре), Гөлшат Гирфанова (Хөсәен Әхмәтов исемендәге Башкорт дәүләт филармониясе артисты).

«Татар җыры – башка милләт вәкилләре башкаруында» номинациясендә Амиран Шамоев (Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе), Чжан Чжихао (Нәҗиб Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе).

«Халыкчан башкару» номинациясендә Инсаф Ганибаев (Ильяс Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллияте) һәм Адилә Мөбәрәкова (Казан шәһәренең 7нче балалар музыка мәктәбе укытучысы).

«Инструменталь башкару» номинациясендә Алмаз Әсхәдуллин җитәкчелегендәге «Алпар» төркеме (Казан).

«Халык мәхәббәте» номинациясендә җиңүче тамашачыларның алкышларыннан чыгып билгеләнде. Анда Кытай егете Чжан Чжихао җинде, аңа диплом бирделәр.

Р.Вәһапов исемендәге татар җыры фестиваленең махсус премиясенә Рөстәм Хөсәенов (Казан шәһәренең 21нче балалар музыка мәктәбе укучысы), Рәмзил Кашапов (Туймазы,Башкортостан) лаек булды.

Р.Вәһапов исемендәге Халыкара татар җыры фестивале яшь башкаручылар бәйгесенең иң югары бүләге – **Гран-при** иясе булып 2 кешегә бирелде. Алар: Акылбәк Пиязов (Үзбәкстан), Дамир Таипов (Башкортстан).

Татар-информ.

Расих Фәсхетдинов фотосы.

Айсылу Лотфуллина җиңүе

«Иң яхшы туган тел һәм әдәбият укытучысы» дип аталган Бөтенроссия һөнәри бәйгесенә йомгак быел Төньяк Кавказ республикаларында ясалды.

Беренче тапкыр әлеге бәйге 2022 елда уздырылган иде. Быелгы чарада Россиянең төрле төбәкләреннән иң яхшы дип сайлап алынган 72 укытучы һәм 32 тәрбияче катнашты. Укытучылар – Карачаево-Черкессия республикасының мәркәзе Черкесск шәһәрендә, тәрбиячеләр исә Төньяк Осетия-Алания башкаласы Владикавказда һөнәри осталык буенча көч сынашты. Татарстан данын Казан шәһәренең 13 нче татар гимназиясе укытучысы Алинә Шәгәрәева һәм 41 нче балалар бакчасы тәрбиячесе Айсылу Лотфуллина яклады. Катнашучылар арасында шулай ук Түмән шәһәренең 52 санлы этномәдәни компонентлы мәктәбенең татар теле һәм татар әдәбияты укытучысы, милләттәшебез Халидә Кирамова да бар иде.

Укытучылар һәм тәрбиячеләр финалга ике тур аша узды. Алар нәтиҗәсе буенча Түмән өлкәсеннән Х.Кирамова – ТОП-15, Татарстаннан А.Шәгәрәева беренче бишлеккә кереп, финалга чыкты, ә Айсылу Лотфуллина җиңү яулады.

750 турист алданган

Дубайга «очсыз» турлар сатып алу юлы белән алданган туристлар саны инде 749 кеше исәпләнә. Бу хакта адвокат Руслан Нагиев социаль челтәрдәге үз сәхифәсендә хәбәр итә. Хокук яклаучы сүзләренә караганда, зыян күрүчеләр аңа ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән. Хәзер адвокат зыян күрүчеләрне санап бара һәм аларга килгән зыянны бәяли. Блогерлар гамәленнән барлыгы 749 кеше зыян күргән.

«Бүгенге көнгә актуаль мәгълүмат: Дубайга арзан турлар вакыйгасында 749 зыян күрүче һәм 20 млн сумнан артык гомуми зыян», – ди ул.

Күптән түгел «Татар-информ» редакциясенә Дубайда яшәүче танылган ирле-хатынлы блогерлардан турлар сатып алып алданган берничә кеше мөрәҗәгать иткән иде. Зыян күрүчеләрнең берсе алданган кешеләр чатында йөздән артык кеше булуын сөйләде. Көннән-көн бу сан арта гына бара.

● Иртән алма ашауның кәһвә эчүгә караганда йокыдан яхшырак айнытуы дәлилләнгән.

● Гонолулу пешекчеләре сигезаяк итен кер юу машинасында юып йомшарта.

● Теләсә кайсы диңгез яки елга балыгы – иң файдалы ризыклардан берсе. Ул организмны җиңел аксымга туендыра, хәтерне яхшырта, тирене нәфисләндерә, зыянлы холестеринга каршы көрәшә.

● Яңа җыелган яки дөрес туңдырылган җир җиләге кәефне күтәрергә, дәрт өстәргә сәләтле, чөнки аңарда организмның тонусын күтәрү өчен җаваплы витаминнар күп.

● Зәңгәр күзлеләр караңгыда башкалардан яхшырак күрә.

● Дөньяда макарон эшләнмәләренең 350 дән артык төре мәгълүм.

● Арахис – чикләвек түгел, бәлки ясмык, фасоль кебек үк кузаклы үсемлек, ул динамит җитештергәндә файдаланыла.

БЮДЖЕТ – ТОРМЫШ КӨЗГЕСЕ

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Агросәнәгать комплексы – республика икътисадының иң әһәмиятле тармакларыннан берсе. Узган ел бөртекле культуралар югары уңыш бирде. Ул 5 миллион тоннадан артыграк булды. Тулаем алганда, 1,8 миллион тонна шикәр чөгендере, үсемлек мае җитештерә торган культуралар – 600 мең тонна, бәрәңге – 800 мең тонна, яшелчәләр 260 мең тонна җыеп алынды.

Татарстан азык-төлек продуктларының төп төрләре белән тулысынча тәэмин ителгән һәм ул республикадан читтәге төбәкләргә дә шактый зур күләмдә продуктлар чыгара ала. Авыл хезмәтчәннәре алдында ирешелгән күрсәткечләрне югалтмау һәм авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүне арттыру юнәлешендә җитди бурычлар тора. Болар туфракның уңдырышлыгын үстерү исәбенә башкарылырга мөмкин.

Республика – терлекчелек төбәге. Мөгезле эре терлекнең баш саны ягыннан без илдә беренчеләр сагында. Алдынгы урыныбызны саклау мөһим. Сөт җитештерү буенча 2 миллион тонна, ит җитештерү буенча 550 мең тонна күрсәткечләренә ирешү – республиканың бурычы.

Татарстан республикасы шәһәрләрендә ел саен авыл хуҗалыгы ярминкәләре оештырыла. Авыл хезмәтчәннәре шәһәрләргә кулай бәядән продуктлар алып килә. Шәһәр халкы моның өчен бик рәхмәтле.

Бакчачылык һәм яшелчәчелек эше аерым социаль әһәмияткә ия. Миллионнан артык татарстанлы үзләренең бакчаларында һәм йорт янындагы җир кишәрлекләрендә эшли һәм ял итә. Гражданнар өчен бу – ял гына түгел, бәлки үзләрен экологик яктан зарарсыз азык-төлек белән тәэмин итү мөмкинлеге дә.

2017 елдан башлап республика җитәкчелеге бакчачылык ширкәтләренә ярдәм күрсәтә. Моның өчен елына 3,5 миллиард сум акча бүленгән. Бу аны бакчачылык ширкәтләрен су, электр энергиясе белән тәэмин итү, юллар салу һәм чүп чыгару өчен тотыла.

Кешеләр турында кайгырту – элеккечә үк республика җитәкчелегенең игътибар үзәгендә. Татарстан тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән илкүләм проектларны һәм республика программаларын тулы күләмдә үтәүне дәвам итә. Аларның саны инде 44 кә җитте. Татарстан бюджетыннан 46 миллиард сумнан артык акча бүлеп бирелде.

Барлык программа һәм проектларны гамәлгә ашыруда аларның үзара килештерелгән булуын тәэмин итү төп әһәмияткә ия. Бу эшкә комплексны карау зарур. Торак төзү белән генә чикләнмичә, социаль, транспорт, инженерлык, бизнес корылмаларын төзүгә, шулай ук территорияны тулаем төзекләндерүгә игътибар бирү шарт. Моның өчен яңа кварталларны планлаштыручы оешмалар җаваплы.

Программаларны гамәлгә ашырганда, беренче чиратта, гражданнарның ихтыяҗларын истә тотарга кирәк. Бу исә хакимиятнең һәм җәмгыятьнең яшәү һәм эшләү өчен уңайлы тирәлек булдырырга омтылышларын берләштерергә мөмкинлек бирәчәк.

Гомер атын булмый туктатып... Заманында бергәләп шау-гөр килгән чордашлар бер-бер артлы бакыйлыкка күчә. Кайчандыр Чаллы каласының абруйлы шәхесе саналган, бүген инде иҗатташ дуслары хәтерендә генә яшәүче Ирек Гали улы Диндаровның да тууына 70 ел тулды.

Талантлы язучы, кыю журналист иде

(Язучы Ирек Диндаровның тууына 70 ел тулу уңаеннан)

Ирек Диндаров, беренче чиратта, журналист буларак танылу алган шәхес иде. Туры сүзле, сөйләшкәндә сүз очын урап-чолгап азаплануны бер дә яратмый иде. Күзгә туп-туры карап сөйләшә, мәгънәсе чамалы нәрсә сөйли башласаң, күзен кыса төшеп, сынаулы караш ташлый да, йә сүзне төгәлләнгәнгә санап, каядыр ашыгып китеп бара, йә алдындагы кәгазьгә нидер яза башлый. Ирек белән шактый еллар аралашып, аңлашып яшәдек. Еллар агышы күп нәрсәләрне оныттыра, күп кешеләр хәтердән җуела. Тик Ирек истә: чордашым, фикердәшем, каләмдәшем, ихлас дустым буларак һәрчак йөрәктә яши ул.

И.Диндаров безнең Чаллы каласы өчен гади бер журналист кына түгел иде. Ул мәктәп елларыннан иҗатка керешкән һәм гомеренең ахырына кадәр иҗат утында янды. Язучылык эше безнең илдә һөнәр саналмаса да, каләм иясеннән акыл һәм физик энергия, туктаусыз эзләнү, тынгысызлык таләп итә. Ирек тә дөньяга битараф булмаган, хисле, үзенең карашларына туры килмәгән һәр нәрсәгә тәнкыйди карашлы, хәтта килешмәүчән позициядә торучы шәхес иде. Ул язучы буларак Чаллы шәһәрендә формалашты, бергәләп «Ләйсән» әдәби-иҗат берләшмәсенә йөрдек, ул миннән ике генә елга соңарып, 1998 елдан Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде.

Ирек, һичшиксез, татар әдәбияты тарихында лаеклы урын алырга тиешле каләм иясе иде. Аның кабатланмас стиле, рухы, күтәргән темалары булды. Исән чагында ике китап чыгарып өлгерде, вафатыннан соң туганнары ярдәме белән КАМАЗ нәшриятында «Йолдыз җиле» исемле проза җыентыгы дөнья күрде. Куанычлы хәл, Ирек Диндаровның иҗатын барлау туктап тормый. Әле соңгы елларда гына Татарстан китап нәшрияты язучының проза әсәрләре тупланган «Соңгы аманәт» дигән китабын чыгарды. Китапны төзүче – бертуган абыйсы, язучы һәм журналист Илдус Диндаров. Ирекнең быелгы юбилей елында да Илдус үз энесенең истәлеген онытмау өчен җан атып йөри. Публицистикасына килсәк, анысы әле үзенең тикшеренүләрен көтә.

Ирек Диндаров үзгәртеп коруның иң шаулы елларында Татарстан радиосының Чаллы бүлеген җитәкләде. Гел халык арасында, вакыйгаларның кайнап торган ноктасыннан бер минут кичекмичә хәбәрләр яудырып, халкыбызның милли уяңы үсешенә бәйләп бетергесез өлеш керткән фидакарь зат иде ул. Ирекнең активлыгы, турылыгы, чигенә белмәве кемнәрнеңдер «бавырына» тиде, туксанынчы ел башында ул җитәкләгән бүлекне ябып, аның урынына шәһәр хакимиятенең «үз» радиосын төзергә омтылышлар ясала башлады. Көрәш аяусыз барды. Югыйсә, ярты миллионлы шәһәрдә, аның күпчелеген татарлар тәшкил итә, ике радио да артык булмас иде, бер-берсен тулылыландырып кына торасы да бит. Ул елларда андый мөмкинчелекне күрү булмады, бары Ирекка эшләргә форсат бирмәү ягын уйладылар. Баштагы мәлләрдә И.Диндаровны Казан радиосы җитәкчеләре яклаcа да, күрәсең, шәһәр чиновниклары кирәкле «төймәләргә» басу җаен тапты, үҗәтләнә торгач, теләкләренә ирештеләр – бөтен халык яратып тыңлый торган радио эшләүдән туктады. Инициативалы, тыгыш, тәҗрибәле егетне хакимият урамга ук чыгарып ташламады ташлавын – аңа шәһәр хакимиятенең матбугат үзәген оештыру эшен тапшырдылар. Бу инде аны бераз булса да журналистны аратада тоту өчен кылынган гамәл иде. Монда да Ирек кушканны үтәүче булып утырмады, журналистларның киңәшчесенә әйләнде, янышнан кеше өзелми иде. Шул елларда шәһәрнең татар журналистлары берлеген төзү нияте белән янып йөри башлады. Тик бу омтылышына да аяк чалучылар табылды. Әлеге идея тормышка ашмый калды. Ирек һаман да бирешмәскә тырышты, бөтен көчен, күңелен иҗатка, язучылык эшенә салды.

Аның әдәби эшчәнлеге нәсерләр язу белән башланды. Нәсер безнең әдәбиятта сирәк күренеш. Егерменче гасыр башында безнең әдәбиятта искә алырлык тәҗрибәләр ясалган жанр, егерменче елларда Фәхри Әсгать, Мәхмүт Максуд иҗатларында иҗади үстерелә, Гадел Кутуй исә аны яңа биеклекә күтәрә. Менә шушы сирәк жанрда эшләп, Ирек Диндаров нәсернең матур үрнәкләрен биреп калды. «Туйбикә чишмәсе», «Уяну», «Изге ай», «Азатлык турында баллада» дип исемләнгән нәсерләрдә кичерешләр табигый һәм шул ук вакытта катлаулы да. Тәэсирле сөйләм, эчке киренкелек, тыйнак моң – И.Диндаров нәсерләре өчен хас сыйфатлар. Бер-бер артлы ике китабы дөнья күрде: балалар яратып укыган «Әбләев хикмәтләре» һәм «Төркиягә сәяхәт». 1999 елның март аенда, вафатына бер ай чамасы калган көннәрдә, Чаллыдагы иң зур мәктәпләрнең берсендә – 47 нче мәктәптә Ирек Диндаров белән очрашу оештырылды. Ирек үз янына Чаллы язучылар оешмасы рәисе Вахит Имамовны һәм мине дә чакырды. Балалар аның ихласлыгына, тәрбиялегенә сокланды. Һәр сүзе үлчәнгән, һәр сүзен балалар үз күңелләренә сеңдереп кенә торды. Күрәсең, тумыштан педагог булгандыр ул. Ирекнең балалар өчен язган «Әбләев хикмәтләре» дигән китабы басылып чыккан иде. Укучылар аңа кергән хикәяләрне сәхнәләштереп, осталык белән уйнады. Тамаша кылучы балаларның хис-кичерешләрен, егыла-егыла көлүләрен, Әбләевне гөнаһсыз да, әмма кысага да сыешмый торган кыланмышлары өчен җәзага тартулары өчен әрнеп утыруларын күрсәң, шаккатырлык иде. И.Диндаров сөенеп, тыйнак кына елмаеп балаларны күзәтте. «Болай булгач, сезнең өчен тагын язам әле!» – диде ул укучылар белән саубуллашканда. Балалар язучысы саналган күп кенә каләм ияләре мондый очрашуны, гаҗәеп ихлас күтәренкелекне күргәннәре булдымы икән?.. Без Ирек өчен ихлас куанып кайткан идек әлеге очрашудан.

Ирек Диндаров илдә «капкалар ачылгач», беренчеләрдән булып Төркиягә сәяхәт кылды һәм анда күргәннәрен аерым китап итеп чыгарды. «Төркиягә сәяхәт» китабында минем истә калганы – бик күп тарихи фактлар яктыртуы өстенә, аның бер татар авылына баруы, анда күргәннәрен тетрәндерерлек итеп сурәтләве иде. Шулай ук бу китапка берничә кызыклы, безнең өчен яңа булган темалар күтәргән новеллаларын да кертте.

Таланты мул булса да, язу эшенә сак карый иде Ирек. Ни язасын, ни өчен язарга тиешлеген ачыклап бетермичә беркайчан да каләмгә үрелмәде. Һәр җөмләсен кат-кат эшкәртүе белән ул әлеккеге олуг әдәбият әһелләрен хәтерләтә иде. Мин аны мыштырдауда гаепләп, ашыгырак язарга кыстасам, көлеп: «Бөекләр бер селтәнүдә яза торганнардыр инде, мин исә әкрен-әкрен алга барам, ашыгасы җирем юк бит», – ди торган иде. Үзенә, иҗатына үтә җаваплы караудан килгән сыйфаты иде аның каударланмавы.

Ирек Диндаров нәзакәтле кеше иде. Сөйләшүе, киенүе, язу рәвеше, эш стиле моны һәрдаим искәртеп тора, ул бер дә эленке-салынкылыкны сөймәде. Укытучылар гаиләсендә туып-үскәнгә шулайдыр дип уйлыйм. Әтисе Гали ага - кайчандыр журналист буларак та танылу алган шәхес. Аның эшен уллары Илдус белән Ирек дәвам итте. Икесе дә Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлады. Илдус Диндаров озак еллар «Ватаным Татарстан»ның Норлат төбәге үзхәбәрчесе булып эшләде, танылган шагыйрь, язучы, төбәк тарихына багышланган берничә китап, шул исәптән, туган авылын яктырткан «Язмышлар балкышы – Бикколым» китабы авторы да әле. Ирекнең исә, алдан искәрткәнчә, университеттан соңгы тормышы, язмышы Чаллы каласы белән бәйле.

И.Диндаров Октябрь (Норлат) районы Биккол авылында 1953 елның 5 сентябрендә туган. Урта мәктәпне тәмамлый. Университеттан соң, 1974 елда Тукай районы газетасында әдәби хезмәткәр, район профсоюз оешмасында җаваплы вазыйфа били. Тукай районы газетасы булган «Якты юл»да бер-бер артлы нәсерләре, парчалары дөнья күрә башлый. Данлыклы «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенең актив әгъзасы булып китә. Үзгәртеп кору елларында ул «Татарстан» радиосының Чаллы бүлеге мөдире итеп билгеләнде. Тыңлаучылар һәр көнне, төш вакытында радиодан яңгыраган җанга ятышлы йомшак тавышны хәтерлидер әле – Чаллы яңалыклары белән эфирга Ирек Диндаров чыга иде. Аны шәһәрдәшләр үз итеп «Ирек радиосы» дип атады. Яңа кала төзелешенең үзәгендә кайнаган егет бернәрсәгә дә битараф булмады. Җитешсезлек, хаксызлык күрсә, йодрыгын җиң эченнән күрсәтеп утыручылардан түгел иде, шундук чәчрәп чыгып, үз фикерен ярып сала иде. Бездә элек тә, хәзер дә үзфикерле кешеләрне өнәп җиткермиләр, моны Ирек үз шәхесендә тулысынча татыды. Аның иҗатка килү чоры Эдуард Касыймов, Хәниф Хөснуллин, Кадыйр Сибгатуллин, Ямаш Игънәй, Нәҗип Мәдияровларның татар әдәбиятында чын танылу алган дәверенә туры килде. Чаллыда әдәби мохит кайнап торган чаклар иде бу.

Иҗат кешесе катлаулы хисләр дөньясында яши. Ирекне дә төрле халәттә күрә идем. Кояштай балкып йөргән чагына да, сөмсере коелган чакларына да шаһит булдым. Аздан хәтере кала, юктан күңеле була иде. Әмма беркайчан да кешеләргә ачу саклап йөрмәде. Ваклыклардан өстен кала белү өчен дә шәхси өлгергәнлек, көч кирәк шул.

Ирекнең әдәби ниятләре тормышка ашмый калды. Анда булачак әсәрләренә чимал хәттин ашкан иде. Давыллы үзгәреш елларында барча вакыйгалар аның күз алдыннан үтте. Эш бүлмәсе кайнап тора, милләткә җиткерәсе сүзе булган һәр кеше радиога чыгып, фикерен әйтә иде. Җитәкчеләр, милли хәрәкәт вәкилләре, шәһәр халкы – барысы да Ирек радиосын тыңлый, аңа ышана иде. Инде бераз тынычланып, күп нәрсәгә күз ачылгач, шул еллар хакында Ирек Диндаров «Мәйдан» повестын яза башлады. Тик гаять кызыклы булырга тиешле бу әсәр төгәлләнә алмый калды, көтелмәгән үлем талантлы каләм иясе безнең арабыздан алып китте. 1999 елның 30 нчы апреле иртәсе иде ул. 2001 елда шәһәр хакимияте һәм Татарстан Язучылар берлеге миңа Чаллы шәһәрендә өр-яңа әдәби-иҗтимагый журнал төзү вазыйфасын тапшыргач, икеләнмичә, яңа басмага «Мәйдан» дип исем куштык. Моны Ирекнең сүз ирегe өчен гаять авыр көрәшен күз алдында тотып эшләнгәнгә гамәл дип тә санау урынлыдыр.

Факил САФИН,
филология фәннәре кандидаты.

«Тик син, тормыш, җырлап кал, яме!»

(Күренекле шагыйрә Нурия Измайлованы юксыну)

(Дәвамы. Башы 37 нче санда).

Башкортстан китап нәшрияты белән дә араны өзми, кайбер дәреслекләрне тәрҗемәләде, миннән урысча-башкортча сүзлек соратты. Әдәби иҗат дип янган күңеле ятмагандыр бу шөгыльгә, «Акчага алданып, география тәрҗемә итеп ятарга туры килә», – дип ризасызлыгын сиздерде. Тәрҗемәнең әҗере дә һуш китәрлек түгел иде...

Мәскәү чоры аның иң колачлы, куәтле иҗат мәле булгандыр, мөгаен. Казанда «Яратам», «Алтын тарак», «Мин зур үскәч», «Минем җәй», «Иң серле әкиятем», «Җирдә», «Ак малай – минем энем» китаплары басылып чыкты, Мәскәүдә урыс телендә «Ива на ветру» җыентыгы дөнья күрде. 1979 елда Татарстан язучылар берлегендә беренче китабын карауга Нурия илһамланып кайтты, канәгать калды:

– Казанда кульязманы тикшерделәр. «Мондый триумф белән бер секция утырышы да үткәне юк иде», – диделәр. Әллә берсеннән-берсе арттырырга тырышып, мактадылар да мактадылар... Хәсән Туфан, Сибгать Хәким, Нури Арслан: «Союзга алырга кирәк», – диделәр, китап чыккач, билгеле. Нуриянең 2500 укучыга, барча милләттәшләргә, якты дөньяга «Яратам» дип ярып салган шул беренче аерым җыентыгы ике елдан соң басылды, алдагы елында ул Язучылар берлегенә кабул ителде.

«Ива на ветру» китабын Нурия үзе юлга-юл урысчага авыштыргач: «Тәрҗемәгә Марина Кудимовага бирделәр, бик талантлы шагыйрә, подстрочникларны яратты», – дип куанды. Басма дөнья күргәч: «Урысча китап чыкты. Тышы шәп, эче дә ничауа. Татарча чыгарып булмаган байтак әйберләр кереп китте – шунысы ярады», – дип сөенде.

«Адашкан» җыентыгындагы «Тагын, тагын җырла, Нурия!» дигән баш сүзендә югары уку йортындагы сабакташы, әдәбият белгече, тәнкыйтьче, шагыйрь, филология фәннәре кандидаты Равил Рахмани шагыйрәнең иҗатына шактый тәфсилле анализ ясый. Һичшиксез, Нурия Измайлованың уйчан йөрәк, хисле зирәк акыл белән язылган, Аллаһ тарафыннан бирелгән табигый талант чагылышы булган иҗат хәзинәсеннән асыл энҗеләрне табып, аларны сәйләндә балкытып, укучыларга күрсәтүче әдәбият белгечләре киләчәктә дә табылыр, шәт.

Нурия белән ул Мәскәүгә киткән көннәрдән хатлашып тордык, сагыныштык. «Сине еш искә төшерәм», – дип язды, «Нигә хат язмыйсың, кызый? Эре бәрәңге ашадыңмы әллә?» – дип үпкә белдергән чаклары да булды. Уфа, нәшрият яңалыклары белән кызыксынды, хезмәттәшләрне исемләп, сәламнәр юллады, хәлләрен сорашты. Мәскәүгә кунакка чакырды, барганнарны сөенеп, иң якын туганнарыдай кунакчыл каршылады.

1989 елның азагында хезмәттәшем Лилия Насыйбуллина белән Мәскәүдә мөхәррирләр курсында укып алдык. Нурияләргә барып, көткән түгәрәк дөньяларын күрдек, кадер иттеләр.

Кайсыбер йомышларында Нурия мине арадашчы күрде. Урындагы хакимият һәм тәртипләр тәнкыйтьләнгән, җитешсезлекләр төртеп күрсәтелгән мәкаләсен, йомшартмый гына, «Кызыл таң»га әзерләгән идем берчак. Басылып чыккач: «Әнкәй сүкте инде, әмма халыкны үз тормышына ачык күз белән карарга өйрәтү дә ярый», – дип язды хатында.

Үзгә якын күрүен сиздереп, үсендереп тә куя иде. Моңа куәт – почта аша яңа китабын җибәргәндәге юллар: «Мәнә синең чынлап та поэзияне аңлаучы, яратучы икәнеңне белгәнгә, алты авторскийның берсен сиңа салам». Нуриянең җыйнак кына шигырьләре «Китап» нәшриятында Башкортстандагы татар мәктәпләре өчен дөнья күргән уку китапларында да урын алды.

ПРИНСТОНДА

«Мин утыз яшьтә генә «утрак» тормышта яши башладым. Аңарчы 5-6 авылда, 2 шәһәрдә яшәп өлгергән идем инде. Байтак кына юлларда да йөрелде», – дип яза Нурия Измайлова «Иң серле әкиятем» китабында. Инде дә мосафирлык аны коры җирдән житеп булмас җирләргә – океан аръягындагы Америкага ук, 74 ел гомереңнең иң озын дәверен үткәрәчәк, бакыйлыкка күчкәнче 27 ел дәвамында яшәячәк урынга – Принстон шәһәренә алып китте. Карап торышка корычтай кырыс, әмма чынында өрфиядәй нечкә күңелле шагыйрә җирсегәндер ят туфракта... Моңсуланган чакларында үзенең җилле-буранлы иҗатында, шигърияттә юаныч тапкандыр.

«Ялгызларны яратмыйлар,
Яшерелгән ялгызлык
Елмайган тешләр артына,
Зарланырга зар булып...
Мин дә тешне кыскан да ул,
Җаным күздән түгелә...
Мин генә җитмәгән икән
Бу ялгызлар илендә!» –

дигән юлларда ачы хакыйкать, Нуриянең җан зары чагыладыр: Америкага бер ел алдарак киткән ире башкага сыена; уллары зур калаларда белем алып, башка штатларда эш таба; Америкага күченгән ике сеңлесе дә бүтән штатларда тормыш кора.

– Монда аптырамыйлар, кайсы штатта яшәү җайлырак тоела, шунда күченәләр дә куялар, – ди иде Нурия.

Америкада тупланүенә дүрт ел үтүгә шагыйрә, башлыча өр-яңа әсәрләрен туплап, укучыларга күләмле җыентыгын – «Адашкан» китабын тәкъдим итте. Биредә мәхәббәт, бала һәм ана, туган җир кебек элекке, таныш темаларга яңа сәхифә – Американы ачу килеп кушылды. Шагыйрәнең кайгы-борчылулары, хәстәр-хәсрәтләре тирәнрәк, тормышны аңлавы җитдирәк һәм сабыррак тасвирлана яңа әсәрләрдә:

«Океан аръягында
Үлү күпкә җиңелрәк.
Яшәү – очсызрак монда:
Бер тәңкәгә – бер күлмәк.
Гомер кадерсезрәк.»;

«Ак калфакның урынсыз чагы,
Язмышларның узмышсыз чагы.
Ак калфакның бизәксез чагы...
(«Җырларның да кирәксез чагы!»)

Кирәксез, дип әйтәсе дә, җырларыннан аерылмаган язучының әсәрләре аша без дә ачабыз Американы, яшәештә, көн итмештә төп максат матди нәтиҗә булган мохитне, базар, алу-сату мөнәсәбәтләрен кызаллыйбыз. «Язылмаган хатлар», «Тауга карап, таулар булып» тупланмаларында бу чалымнар тагын да калкурак гәүдәләнә. Әдибәнең милли хисләре, туган халкыбызга, ана телебезгә кагылышлы кичерешләре дә ят ярларда яңа төсмерләнеш таба.

Әйтергә кирәк, Нурия милләтчә дә булмады, милләтен кимсетмәде дә. Гомумән, башкаларны милләте буенча гына түгел, теләсә нинди башка сәбәптән кимсетүне яхшысынмады, дөньяга яратылган һәр адәм кеше буларак санлануга лаек, дип санады ул:

«Ямьсез күреп ямьсез дия күрмә –
Һәр чәчәкнең аның төсе бар.
Сөйкемсез сөяк буламы? –
Һәркемнең әнисе бар!»

Милләтне ул дөньяга тәүге аваз салынган туган җир кебек мөкатдәс, тумыштан Ходайдан бирелгән бүләк итеп кабул итте. Чынлап та, кешеләрнең генә түгел, ару әйберләрнең дә милли сыйфаты табигый лабаса, «татар калфагы», «башкорт балы» кебек сүзтезмәләр юктан бар булганмыни?

(Дәвамы киләсе санда).

Динә МОРЗАКАЕВА.

Олпат галимнең яңа китабы



Күренекле галим, филология фәннәре докторы Хатыйп ага Миңнегулов безне яңадан-яңа фәнни хезмәтләре һәм табадан гына төшкән китаплары белән сөендереп тора. Менә сентябрь аенда гына ул редакциябезгә «Татарская литература и Восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики)» дип аталган өр-яңа китабын бүләк итте.

Хатыйп аганың татар гына түгел, бәлки барча шәрык әдәбияты буенча бик зур белгеч булуы мәгълүм. Әлеге яңа китабында да ул атаклы сүз сәнгате һәйкәлләре булып саналган «Калила и Димна», «Тутинаме», «1001 ночь» һ.б. хезмәтләргә анализ ясый һәм фәнни бәя бирә.

Олуг галимебез үз заманында татар милләтенең асыл зыялылары өчен дә үрнәк булган шәрык үрнәкләрен генә анализлап калмый, бәлки аларны тәрҗемә кылган Габделгалләм Фәйзханов, Фатыйх Халиди, татар теленә тәрҗемә ителми калган, ә төркечә басылган «1001 көн» әсәре буенча повестьлар тудырган Ш.Рәхмәтуллин иҗатына да туктала. Бактың исә, әлеге әсәрләрнең геройларын Кормашы белән Г.Тукай гына үз иҗатларында кулланып калмаган, аларны атаклы В.Державин да күтәреп алган икән.

Хатыйп ага Миңнегулов хезмәтләренә соңыннан Марсель Әхмәтҗанов, Хәләф Курбатов, Фатыйх Урманче, Фәрит Хатыйпов, Фоат Галимуллин, Нурмөхәммәт Хисамов, Шакир Абилов, С.Исаков, Муса Мөләков, Резеда Ганиева, Флера Сафиуллина кебек һ.б. галимнәр бәя биргән.

Баш бирмәгән ата-бабаларның, Тавышлары ишетелеп китә...

Айрат СУФИЯНОВ

АВЫЛ БУЛГАН

1

…Бу урында элек авыл булган –
Мәчет торган балкып уртасында.
Яңгыраган азан авазлары
Хакны данлап таңгы нур астында,
Әйтерсең лә... ханнар урдасында!
Авыл булган... Дога кыла-кыла
Коръәнхафиз салган тәүге ташын.
Хәбәр иткән, имеш, хәсрәтләнеп,
Бәндә ашар көннәр, бәндә башын
Алда диеп, аннан әрнеп-әрнеп,
Өстәп куйган:(авыр фараз да соң...)
Диннән язып авыл тараласын,
Илне күмеп кара кайгыларга
Аяусызлык, вәхшәт яраласын,
Рәнҗетелгән меңнәр тарафыннан
Туачак көн үзе каргаласын.
Вөҗданнары чыктай саф килеш тә
Бинахакка җаннар караласын...

2

Түнтәрелеш кабынган чор килгән...
Ул – табигый үсеш юлымы соң?
Әллә, гыйсьян, шайтан коткысының
Тәмуг өстендәге кылымы соң?
Тигезлек вә хөрлек көткәннәр дә,
Җигелгәннәр, инде җиккәннәр дә,
Шул мохитнең мескен колымы соң?
Бәндәләрнең җылы тапканнары,
Яраклашып, калҗа капканнары
Комсыз нәфесеннән олымы соң?
Нигезенә кадәр тезгәнне
Җимергәннәр, белмим, сизенгәнме
Үзләре дә тиздән тапталасын?
Алданганнар өскә күтәргәннәр
Мөртәтлекнең мисез тантанасын...
Тамырыннан үзгәртергә теләп
Үткәннәрне ничек кайтарасың?
Дөньялыкның асты-өскә килгән,
Улы саткан газиз үз атасын.
Вакытлыча мәртәбәгә менгән
Түргә элүчеләр чабатасын.
Җир хуҗасы – җирдән аерылган,
Каерылган артка канатлары.
Һәр карыштан корбан күзе белән
Карап яткан күккә кан таплары.
Җаным сыкрый... Берүк сорамагыз
Тынганнарны нигә кузгатасың?
Изге ният астында да кайчак,
Мәкер йоклый – бөркәнчекле качак,
Аңа төбәп килде куз атасым...

3

Туган белән туган бугазлашкан,
Мәхәббәтне буып, нәфрәт шашкан,
Офыкларга канлы юл тоташкан.
Бәндә белән бергә ил саташкан,
Давыллы чор белән бәрелешеп,
Җәһәннәмнең ут-ялкынын эчеп,
Күпме гали җаннар күккә ашкан.
Күпмеләре мәҗбүр ителгән дә,
Мөһаҗирлек язмышына тарган.
Сөякләргә басып җанкыярлар
Артка карамый да, алга барган...
Имансызлар, надан алласызлар
Аударганнар мәчет манарасын.
Кыйбла-маяксыз да кавемнәрне
Кем якласын, кем соң араласын!?
Якты киләчәккә кулын сузып
Гомер буе кармаланасын
Күздә тотучылар булгандырмы,
Үлгәнгәчә җәзаланасын?
Мәчет манарасын кискән икән
Кулы күтәрелеп кемнең генә?
Ярымае килеп кадалгандыр
Соң булса да
Хөкем итеп мөртәт көрлегенә.
Бөтен җирне камап алган ялган...
Дин-тәрәксез, хокуксыз да калган
Халык – көтү, камчылылар куган.
Асылганнар, киселгәннәр белән,
Атылганнар белән дөнья тулган.
Авыз ачып, тел күрсәтеп кара –
Шәхси мәнфәгатьнең хезмәтчесе –
Бәндә, йөз чөерде асылыннан.
Өмет яфракларын җилдә коеп,
Үзе баскан ботагын да кыеп,
Агачын дар итеп асылынган.
Уздымы соң үлем тыны үбеп?
Иркен җуйган таркаулыктан җебеп,
Богау салкыныннан калтырата...
Өнсезләрне аяп тормый изгән,
Күпме япь-яшь гомерләрне өзгән
Дәүләт сәясәте – кырыккарта.
Мәчетләр дә, чиркәүләр дә арта...
Нигә һаман безне сазлык тарта?
Мөнбәрләрдә ахмак акыл сата...
Кысылдымы вакыт?
Чыгып өлгерми дә кояш бата...
Кем соң яклар изге һәр ниятне?
Курчакларны котлап кул чабучы
Көнлекчеләр басты җәмгыятьне…
Гаделлек юк илдә... Әхлак – түбән...
Күптән инде күккә тими түбәм.
Тәүбә итеп, җирдән киткәннәрнең,
Авыр хиҗрәт юлын үткәннәрнең,
Дога сеңгән кайтавазын үбәм.
Кайда калкан-кылыч, кайда көбәм?
Муенымны зәһәр елан буган...
Хәтер касәм кан, яшь белән тулган…
…Йөрәгенә сайрар былбыл кунган
Бу урында элек авыл булган...
Зират күкрәгенә алсу җәймә
Җәйгән чакта һәрбер яңа иртә,
Бәгырь кылларына чиртә-чиртә,
Анда, һаман бала-чагаларның,
Гармун тарткан мәрхүм агайларның,
Баш бирмәгән ата-бабаларның,
Тавышлары ишетелеп китә...
Бу урында авыл мәрхүм булган...
Гасыр фаҗигасе – җир суынган,
Тамырлар да мәхрүм им суыннан.
Валлаһи, дим, оят яшь буыннан.
Кемнәр генә кай тарафка качар?
Нинди офык киңлекләрен ачар?
Кайсыбыз соң курку белмәс кучкар?
Гомер бакый югалтуга дучар,
Бөтен илне нинди язмыш көтә?
Ялкын булып җанны сорау өтәр.
...Гөнаһ, савап бизмәненә салып,
Һәрбер гамәл өчен җавап алып
Ахирәттә Аллаһ хөкем итәр...
Кемдә кодрәт, шулар хаклы булган...
Әйтерсең лә гавам гомер бакый,
Хөрлек ишекләрен шакый-шакый
Кимсетелеп, көн күрергә туган.
...Бүген килеп, ни үзгәрде, туган?
Заман үзе, кеше бәдәне дә,
Тимерләрдә тилмерепләр туңган.
Тирән фикер йөрткән акыллылар –
Кирәк түгел илгә... кирәк коллар...
Һәр әмерне күндәм үтәүчене
Югарыга чөеп кем олылар?

4

Нинди бәхет көтсен, җинаятьнең
Нигезендә күтәрелгән илне.
Күптән инде безнең сулышларга
Кучкәне юк иркен дала җиле.
Үткәннәрнең тамырларын эзли,
Зинданнарда зарлы, зынҗырлы кош...
Тыңлап торам басып аягүрә,
Бәгырьләрне телеп тавыш бирә
Кош түгел, ул – безнең милли язмыш.
Исән-саубыз бүген, без уяумы?
Гамәлләребез дә күз буяумы?
Ни сөйләрләр икән безнең хакта?
Гаҗизләнеп карыйм офыкларга.
Бүгенгенең өрәгеме – мирас,
Йөрәгеме безнең оныкларга?..
Туар көннәр чалымлансын өчен,
Күрәзәче итеп акыл көчен
Ачыкларга кирәк... аныкларга...
Кызыл балчыккача җирне тишсәк, ишсәк
Нинди туфрак калыр орлыкларга?..
Түбәнсеткән тарлык изгәндә дә,
Күпчелектә гадел зурлык барга
Ышанасым килә... яшәгәндә,
Язлар кайтып, дөнья яшәргәндә.
Ышанасым килә күңелемне
Гафләт туты кумә алмасына.
Һәм сыймас та рухта уянуым
Бәгъре корыганнар карашына.
Ахирәттә фанилыкның сатлык
Бөтен кануннары алмашына...
Кеше исәбенә симергәннең,
Сорыкорттай тамыр кимергәннең
Хәрәм малы төшәр үз башына.
Гамәл дәфтәренә теркәлгәннәр,
Ахирәттә, (шигем, юк, әлбәттә)

МИН – ХӨКЕМДАР ТҮГЕЛ

1

Камилләшә бара кысулары...
Юк итүнең бөтен ысуллары
Кулланыла адәм тарафыннан.
Барлык нуры, терелтүче кодрәт
Агылырмы акыл карашыннан?
Сулык-сулык йөрәгемдә ярам,
Котып якка таба атлап барам
Янгын узган урман арасыннан.
Теләсәм дә, юк, котыла алмыйм
Янап иярүче кара шомнан.
Кайсы чорны хәтер-иләк аша
Үткәрсәм дә, тирән ярасыннан
Кан ургыла... Тормыш кан диңгезен
Ярып йөзгән кораб шикелләрәк.
Хәвефләнеп, тетрәп сорый йөрәк:
«Афәт чоңгылына юлыкмасмы?
Төпсезлектә батып, юк булмасмы?»
Җилкәне юк... Ишкәкләре – сынык.
Ихтыярың туплап күпме чынык,
Аяусыз да, куркыныч та чынлык...
Төшләргә дә керми аяз тынлык.
Мәртәбәдә – бетле астыртынлык.
Кайда кыйбла? Таянырлык терәк?
Бармы кояш күзгә сөеп баккан,
Кайный-кайный актарылып аккан,
Кысыр болытлардан биектәрәк?
Җавап көткәннәргә җавап кирәк...
Корбаннарын санап, кешелектән
Каһкаһәләп көлә вирус-әрәк.
Хет өметнең бер чаткысы калса,
Яшәп булыр кебек мәгънәлерәк.
Кабат дөрләп ялкын кабынър да,
Кайта-кайта хаклык намаз укыр,
Йөрәгемдә исән калган җырда.
Бәдбәхетләр ярама тоз салып,
Әйтмәгез сез: «Аны сәмруг чукыр...»
Яклаучысын күрер таланган чор.
Ул әлегә түгел тома сукыр...

2

Үзем белән үзем тарткалашып,
Шашып-шашып, түгеләм дә, ташып,
Хөкем күзе белән кырыс карап
Уятачак әле аларны да...
Сират күпереннән кичкән чакта
Искә төшерерләр Алланы да.
Гөнаһка да, савапка да сизгер
Күк бизмәне торыр алларында.

3

Яраланып, бар дөньяны айкап,
Күз яшемдә вөҗдемне чайкап,
Тәүбә тәмугында куырылам.
Дым шифасын тамырлардан эзләп
Егылам да... аска суырылам.
Син елыйсың, җаным... Ник, елыйсың?
Юк! Юк, еламыйсың, син җырлыйсың
Фанилыкның дәҗҗалларын чагып.
...Күк астында, киләчәктә шиксез
Минем катнашымнан башка, минсез
Чалыначак колын йөри чабып.
Йөксез, авызлыксыз, дагасыз да,
Һәр нәрсәдән ямь, гүзәллек табып.
Кешнәп куя, аннан, туктала да,
Яшел үлән каба, миңа багып.
Сөбханалла! Ни көткәнен алда
Аңламаган иң бәхетле чагы!
...Кызыл балчык каткан кулларыма
Тия яза маңгаеның агы.

4

Баш очымнан ап-ак болыт булып,
Кыйбла якка вакыт уза агып...
Озатып бара фәрештәләр сагы,
Салмак кына кагып канатларын.
...Кипкән иреннәрем көчкә ачып,
Йота-йота тормыш газапларын
Дөнья яшәр, диеп, кабатладым.
Яңгыр явып узды җилләп-җилләп.
Хәлләндем дә, күтәрелдем өскә,
Явызлыкның шәҗәрәсен җирләп.
Юк, буйсынмас дөнья киләчәктә
Иблис җитәкләгән кара көчкә.
Җан сагынган күк иреген биләп,
Аллаһ белән кереп бәйләнешкә,
Уралырбыз әмин(!) ап-ак төскә...

Чаллы.

Гаяз Исхакый инкыйраз авыруының иң хәтәр төре булган маңкортлыкка каршы үтемле чара итеп халыкның тарихи хәтерен уятуны һәм аның аңын милли рухта тәрбияләүне саный. Шул изге максатны күздә тотып иҗат ителгән «Олуг Мөхәммәд» тарихи драмасы (1944–1947) үзенең оптимистик рухы һәм патриотик лейтмотивы белән татар милләтен инкыйраздан сакларга ярдәм итүче әсәрләрнең үзгәендә тора.

МИЛЛӘТ ӨЧЕН

Гаяз Исхакый.

Җәмит Рәхимов.

Тарихи драма реаль нигезгә корылган. Бередә әсәрнең сюжеты Казан ханлыгы төзелү чорына караса да, Гаяз Исхакый тарихи драмага гаять зур мәгънә төсмере йөкләгән. Алтын Урда ханнарының берсе Олуг Мөхәммәд биредә яңа дәүләт – Казан ханлыгын төзүче итеп кенә түгел, ә бәлки таркау халыкны туплый алган милли юлбашчы, талантлы полководец, киләчәккә карап эшләүче дәүләт җитәкчесе итеп тә тасвирлана. «Олуг Мөхәммәд»тә сурәтләнгән тарихи вакыйгалар әдип идеясен көчәйтүче фон, драманың иҗтимагый-эстетик куәтен нигытучы әсәр компонентлары рәвешендә файдаланыла.

Тарихи драманың төп фикеренә яхшырак төшенү өчен, Г.Исхакый сурәтләгән чорны бераз күз алдына китереп үтик. Чөнки шунсыз «Олуг Мөхәммәд» тарихи драмасын аңлау җиңел булмаячак.

Тарихтан мәгълүм булганча, 1425 елда, Мәскәү кенәзе Василий I Дмитриевич үлгәч, тәхет варисы булып аның ун яшьлек улы Василий II Васильевич кала. Тәхет варисы артык яшь булу сәбәпле, бөек кенәз тәхетен мәрхүм Василий Iнең туган энесе, Галич һәм Звенигород удел кенәзе Юрий Дмитриевич дәгъвалый башлый. Нәтиҗәдә рус кенәзләре үзара тарткалашучы ике төркемгә аерыла һәм, бу бәхәсне гадел юл белән хәл итүне үтенеп, 1431 елда Алтын Урда башкаласы булган Сарай шәһәренә (хәзерге Саратов) киләләр һәм Олуг Мөхәммәд ханга мөрәҗәгать итәләр. Һәр ике якның да дәлилләрен бик игътибар белән тыңлаганнан соң, 1432 елда Олуг Мөхәммәд хан бәхәсне чишә һәм бөек кенәз тәхетен Василий IIгә бирә. Ләкин бу чакта инде Алтын Урда дәүләте дә, рус кенәзлеге кебек, тотрыксызлык һәм үзара низаглар чорына килеп керә. Җитмәсә Олуг Мөхәммәдиең туган энесе Кечек Мөхәммәд тә, Василий Iнең көндәше Юрий Дмитриевичны яклаган морзалар, рус кенәзләре һәм кайбер гаскәр башлыкларына таянып, фетнә оештыра һәм туган абыйсын Алтын Урдадан куып җибәрә. Берничә мәртәбә тәхетне корал көче белән кайтарырга тырышып та уңышка ирешә алмагач, Олуг Мөхәммәд бер мең кешелек атлы гаскәре һәм ике меңләп иярчене белән бергә Тула шәһәре тирәсендәге Литва кенәзлегенә буйсынган Белев шәһәренә юнәлә һәм шунда килеп урнаша. Олуг Мөхәммәд, биредә бераз хәл җыйгач, үзе бөек кенәз итеп раслаган Василий IIнең ярдәме һәм Сарайда калган фикердәшләренең булышлыгы белән тәхетен кабат яулап алырга ниятли. Ләкин Мәскәүнең бөек кенәзе Василий II, игелеккә игелек белән җавап бирәсе урынга, авыр хәлдә калган Олуг Мөхәммәд ханга карата гаять зур илтифатсызлык күрсәтә һәм шактый тупас рәвештә аңа рус җиреннән китәргә куша.

Шундый хәлгә калган Олуг Мөхәммәд үз гаскәреннән кырык бер тапкыр зуррак булган рус армиясе белән 1437 елның 5 декабрендә Белев шәһәре янында очраша. Рус тарихчылары да уңайсызланып искә ала торган бу сугыш кырык бер меңлек рус гаскәре өчен бик аяныч бетә: Олуг Мөхәммәднең бер мең кешелек хәрби берләшмәсе тарафыннан тулысынча тар-мар ителә. Дөньяда аналогы булмаган бу җиңүне тарихчылар төрлечә аңлата. Рус тарихчысы С.Соловьев Василий II гаскәренең җиңелүен Олуг Мөхәммәднең полководецлык талантыннан түгел, бәлки Мәскәү гаскәренә ярдәмгә җибәрелгән Григорий Протасьевның хыянәтеннән һәм ул көнге томаны иртәдән күрә. Ягъни ул, иртәнге томан аркасында руслар Олуг Мөхәммәд гаскәренең һөҗүм итүен күрмәгәннәр, дип расларга тырыша.

Олуг Мөхәммәд хан, зур трофей һәм күпсанлы әсирләр яулап, сахра юлы белән барып Идел елгасын кичә һәм Казан каласы янына туктала. Биредәге хакимиятне үзенә буйсындырып, бераздан ул Казан ханлыгы дип аталган яңа дәүләт төзи һәм рус гаскәрләре белән икенче бер бәрелештә бөек кенәз Василий IIнең гаскәрләрен тәмам тармар итә, ә үзен исә әсир итеп ала. Шуннан соң гына Мәскәү хөкүмәте Казан ханлыгына ясак түли башлый. Мәскәү Василий IIне зур акча бәрабәренә әсирлектән сатып ала һәм, солых шартлары буенча, рус җирендә Касыйм ханлыгының төзелүенә ризалык бирә. Олуг Мөхәммәд хан, Казан ханлыгын Европа, Азия илләренә танытып калдырып, 1446 елда вафат була.

«Олуг Мөхәммәд» драмасы татар әдәбиятына да йогынты ясады. Аерым алганда, ул бүгенге татар әдәбиятында нык үсеп киткән тарихи жанрның тууына сәбәпче булды, һәм бу өлкәдә Гаяз Исхакый игълан иткән гаделлек, миллилек, тарихилык, милләт язмышын кайгырту, киләчәк буын өчен милли ориентирлар калдыру, инкыйразга каршы актив көрәшү, милли аңны уяту һәм тәрбияләү, тарихи хәтерне тергезү, милли патриотизм кебек асыл принциплар тарихи темаларга әсәрләр иҗат итүче әдипләребезнең иҗатына яңа импульс бирде.

Шундый характердагы аерым уңышсызлыклар булуга карамастан, тарихи темаларга иҗат итүче әдипләребез татар милләтенең тарихи язмышы һәм киләчәге хакында уйлана башлады. Әйтик, И.Нуруллинның «Тукай» романы (1975), Ә.Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» повесте (1975), Н.Фәттахның «Сызгыра торган уклар» (Беренче китап) тарихи романы (1977), А.Расихның «Ямашев» трилогиясе (1967-1981), Б.Камаловның «Мирхәйдәр Фәйзи» повесте (1987), Р.Низамиевның «Фәрит Яруллин» (1990) һәм М.Хәсәновның «Галимҗан Ибраһимов» (1990) дигән әдәби-документаль повестьлары, Җ.Рәхимовның «Батырша» (1992), Р.Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» (1992), Ф.Латыйфиның «Хыянәт» (1993) тарихи романнары, Р.Зәйдулланың «Шаһгали» хикәясе (1993), В.Имамовның «Сәет Батыр» тарихи романы (1994), Р.Сибатның «Атилла» хикәясе (1994) халкыбызның данлы үткәнен гадел сурәтләп кенә калмый, бәлки аның милли үзаңын үстерүгә һәм нигытуга да намус белән хезмәт итәләр.

Җөмләдән Җ.Рәхимовның «Батырша», Р.Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» һәм В.Имамовның «Сәет Батыр» романнарына аерым тукталасы килә. Әдәби һәм гыйльми җәмәгатьчелектә зур резонанс тудырган һәм Г.Исхакыйның милли яшәеш өчен көрәш рухы белән сугарылган бу җитди әсәрләр халкыбызның үткән юлын гадел яктыртулары белән дә кыйммәтле.

Мәсәлән, Җ.Рәхимов «Батырша» романында үзәк планга XVIII гасыр уртасында Россия империясен тетрәткән һәм халыкка Батырша исеме белән кереп калган тарихи шәхес – Габдулла Галиевнең (1710–1762) образын куйган. Татар-башкорт дөньясында мәгърифәтче булуы белән танылган һәм 1755 елда Идел буенда яшәүче халыкларның баш күтәрүен оештырган бу легендар шәхес татар халкының милли азатлык өчен көрәш тарихында русларның И.Болотников, С.Разин, Е.Пугачев кебек кешеләре белән бертигез югарылыкта тора.

1552 елгы агрессиядән соң дәүләт бәйсезлеген югалткан татар халкы беркайчан да үзенең коллык хәле белән килешмәде. Бу хурлыктан котылу өчен ул гасырлар буена тигезсез көрәш алып барды, Гали Әкрәм, Сәет Батыр, Алдар, Күчем, Акай Батыр, Батырша, Канзафар Усаев, Бәхтияр Канкаев, Ярмөхәммәт Кадерматов кебек хәрби зшлекләре һәм И.Алкин, С.Максуди, Й.Акчура, Г.Исхакыйдай милли юлбашчылары җитәкчелегендә милли азатлык көрәшен гел яңартып торды. Шулар арасында Батырша җитәкчелегендә 1755 елда кабынып киткән восстание аерым урынны алып тора. Бу восстание патша хөкүмәтенең Идел буенда яшәүче халыкларны көчләп чукындырып, аларны христиан диненә ирексезләп кертү сәясәтенә көчле протест буларак кабынып китә. Җирсуын, мал-мөлкәтен һәм башка байлыкларын корал көче белән яулап алганнан соң гына буйсындырылган халыкларның әле Мәскәүгә тулысынча баш имәвен яхшы аңлаган патша хөкүмәте бу җиңүне икенче ысул белән нигытырга уйлый. Ягъни ул Идел–Урал буена җәза гаскәрләре озатуында күпсанлы рус миссионерларын җибәрә һәм

ИСХАКЫЙЧА КӨРӘШ

● Ренат Мөхәммәдиев.

● Вахит Имамов.

анда яшәүче халыкларны, төрле ташламалар һәм өстенлекләр белән кызыктырып, христиан диненә кертмәкче була. Баш имәгән халыкларның рухи дөньяларына шул рәвешчә хуҗа булу юлы белән аларны тәмам буйсындыру, кол итү максатын күздә тоткан бу яман сәясәт, билгеле, мөселман динен тоткан төрки халыкларда зур нәфрәт һәм кискен протест тудыра. Бигрәк тә Казан епископы Лука Канашевич дигән миссионер үзенең ерткычлыгы, җәлладлыгы белән нык аерылып тора. Халыкта Аксак Каратун дип йөртелгән бу поп мөселманнарны җәзалап, телләрен кистереп, кабыргаларыннан ыргакка асып куеп, христиан диненә күчерә торган булган. Аның бу гамәленә каршылык күрсәтүче авылларны җәза гаскәрләре ярдәмендә яндырып, урыннарын җир белән тигезләп йөргән. Менә шундый башбаштаклыкларга һәм рухи геноцидка каршы баш күтәрүчеләрнең юлбашчысы булган Батырша вөҗдан һәм намус иреген генә түгел, бәлки шәхес азатлыгын да яклап көрәшә, милли тигезсезлекне бетерү өчен дә кан түгә.

Инкыйраздан котылуның кырыс формасы булган бу милли восстание үзенең колачы һәм куәте белән ул чорда дөньяның иң көчле чыгышларыннан берсе була, һәм ул хәрәкәт Россия империясенең унбиштән бер өлешен каплап ала. Бу хәл ул вакытта Россия императрицасы, Петр I нең кызы Елизавета Петровнаны (1709–1761) гаять зур борчуга сала. Гәрчә Батырша восстаниесе җиңелеп, аның юлбашчысы кулга алынса да, бу милли азатлык хәрәкәтенең нәтиҗәләре эзсез югалмый. Мәскәү хөкүмәте дә хәзер инде дини сәясәтен сак һәм уйлабрак алып бара башлый.

Җ.Рәхимов романында милли азатлык көрәшенең юлбашчысы Батырша образы шактый тулы ачылган. Әдип аның тормыш юлын тасвирлау аша шул чорның катлаулы иҗтимагый-сәяси, мәдәни, милли, рухани картинасын тудыра һәм гаять авыр хәлгә куелган татар һәм башкорт халыкларының милли изелүгә каршы бердәмлеген үзенчәлекле детальләр аша ача.

Шул ук вакытта Җ.Рәхимов, милли инкыйразга каршы тора алучы көчләрнең ислам дине тирәсендә туплануын һәм бу рухани конфессиянең үзенчәлекле дәүләт институты вазыйфасын үтәвен күрсәтеп, миссионерларның «тәре походын» Мәскәү хөкүмәте сәясәтенең табигый дәвамы дип раслый. Корал көче белән буйсындырылган халыкларның соңгы терәге булган диннәрен юк итү нияте барып чыкмагач, Мәскәү тактикасын үзгәртә, басым ясау ысулларын төрләндерүгә керешә. Роман 1552 елгы фаҗигадән соң үз тарихын югалтуга дучар ителгән һәм аңына «монголлар кул астында яшәгән рус халкы алдында зур гаепле» дигән фикер сеңдерелеп килгән татар милләтенең олы фаҗигасен беренче мәртәбә бөтен кискенлеге белән ача. Ул, Г.Исхакыйның «Олуг Мөхәммәд» тарихи драмасында нигез салынган милли горурлык хисен тагын да үстереп, татар халкының милли азатлык өчен алып барган авыр көрәшенә яңа ориентир һәм өстәмә дәлил тәкъдим итүе белән дә үзенчәлекле.

Батыршаларның көрәш байрагын 1917 елда кабат бер җилфердәтеп алган татар халкының XX гасыр башындагы милли азатлык көрәше Р.Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» романында да чагылып алды.

«Сират күпере» романы документаль нигезгә корылган, шул сәбәпле аның һәр факты, һәр эпизоды ул дәвернең тарихи процессын чагылдыра. Роман үзәгендә күренекле татар большевигы һәм публицисты Мирсәет Хәйдәргали улы Солтангалиевнең (1892-1940) фаҗигале язмышы тора, әдип шул образ аша 1917-1919 елларда барган милли азатлык хәрәкәтенең катлаулы һәм каршылыклы нюансларын күрсәтергә омтыла. Рус империясен таркату өчен гаять зур тырышлык куйган, әмма шул ук вакытта яңа совет империясенең нигез ташларын үз куллары белән салышкан һәм аны ныгыту өчен утка-суга кергән бу трагик шәхеснең гамәлләре татар дөньясында төрлечә бәяләнә. Берәүләр аны 1918 елда оеша башлаган милли дәүләтне җимерүдә гаепли, икенчеләр аны күренекле большевик булуын кичерә алмый, өченчеләр исә татар дөньясында гына түгел, бәлки бөтен мөселман илләрендә дә хөрмәт ителә торган бөек шәхес дип саный. Һәрхәлдә әле бүгенге көндә дә бу үзенчәлекле шәхес хакында тотрыклы бер караш өлгереп җитмәгән. Ничек кенә булмасын, М.Солтангалиев – татар тарихында күренекле роль уйнаган һәм аның язмышын хәл итүдә актив катнашкан шәхес. Р.Мөхәммәдиев аның образын шул яссылыкта карый һәм үзенең герое яшәгән, хәрәкәт иткән чорның объектив күренешен тасвирларга омтыла. Мәскәү белән Казан арасында барган сәяси сөйләшүләр, ул чордагы иҗтимагый-сәяси процесслар һәм дәүләт эчендә кабынып киткән милли азатлык көрәше фонында М.Солтангалиевнең каршылыклы, үзенчәлекле, фаҗигале язмышы аеруча төгәл тасвирлана.

Әдип, героен шәхес һәм кеше буларак тасвирлап, аның рухи халәтен ачып, иң элек бу сәяси эшлекленең татар халкы алдында күрсәткән хезмәтләренә игътибар итә. Шул ук вакытта романда М.Солтангалиевнең бер татар халкы мәнфәгатьләрен яклап көрәшүе генә түгел, бәлки башка барлык төрки халыкларның милли статусларын рус халкы белән бертигез дәрәҗәгә кую өчен кылган актив гамәлләре дә күренә. Татар зыялылары һәм Г.Исхакый кебек милли көрәшчеләр белән үз вакытында уртак тел таба алмаган һәм уртак куркынычка – инкыйразга каршы тору өчен милли платформада берләшә алмаган М.Солтангалиевнең трагедиясен нечкә психологизм белән ачып, Р.Мөхәммәдиев 1917-1919 ел фаҗигаләрен бүгенге көн өчен дә әһәмиятен югалтмаган гыйбрәтле мисал рәвешендә күрсәтә һәм аңардан тиешле сәяси сабак алырга өнди.

Милли азатлык өчен көрәшнең ерак үткәнебездәге бер сәхифәсе В.Имамовның «Сәет Батыр» дигән тарихи романында да яктырып ала. Автор 1704–1722 елларда Сәет Батыр җитәкчелегендә Идел буенда барган милли азатлык хәрәкәтен тарихи документларга таянып яктырта.

Бу восстаниенең килеп чыгу сәбәпләре дә рус империясенең ул чакта алып барган милли изү сәясәте белән тыгыз бәйләнгән. Император Петр I (1695–1725) Нева елгасы буенда яңа башкала төзергә ниятли һәм шуның өчен мөселман динендә булган халыкларны, аеруча татарларны, гаскәр ярдәмендә кулга төшереп, төньякка китерергә әмер бирә. Башбаштак императорның әмерен үтәү йөзеннән, рус гаскәрләре меңнәрчә татар ирегетләрен, богаулап, яңа шәһәр төзелә торган урынга китерәләр һәм аларны каторга режимында эшләтәләр. Россия империясенең төньяк башкаласы Санкт-Петербург, шулай итеп, йөзләрчә мең татар кешесенең сөякләре өстендә төзелә. Әлбәттә, холыксыз патша Петр I нең сәяси гамәлен тормышка ашыру чарасы итеп сайланган татар халкы бу хәлгә түзеп тора алмый, Сәет Батыр җитәкчелегендә милли восстание күтәрә. Шведларны тар-мар итүе белән гел мактанып яшәгән Петр I гә татар халкының бу чыгышын бастыру өчен унсигез ел кирәк була.

В.Имамов үзенең әсәрендә Сәет Батыр кул астында көрәшүче татар каһарманнарын юк итәргә җибәрелгән патша солдатларының рәхимсезлекләрен һәм ерткычлыкларын гына тасвирлап калмый, бәлки рәсми пропаганда тарафыннан «реформатор, Европага тәрәзә ачучы, рус халкын мәгърифәтле итүче» диеп мактанган Петр патша турындагы мифның да ялган булуын фаш итә. Татар милләтен тулысынча чукындыру, баш тарткannарын исә җәзалап үтерү турында яшерен указ әзерләгән һәм үзенең бу ямьсез гамәлен вафат булуы аркасында гына тормышка ашыра алмаган Петр I нең җинаятьчел сәясәте әсәрдә яхшы күренә. В.Имамов XVIII гасыр башында көчәеп киткән руслаштыру сәясәтенең тулысынча уңышка ирешә алмавының, бу геноцидның барып чыкмавының сәбәбен татар халкының Сәет Батыр кебек милли юлбашчылары исеменә бәйләп аңлата, һәм авторның бу фикере тарихчы галимнәребез тарафыннан да раслана.

Гомумән, Г.Исхакый иҗаты, аерым алганда, аның «Олуг Мөхәммәд» тарихи драмасы әле әдәбиятыбызда үзенең лаеклы урынын ала гына башлауга карамастан, инде күргәнебезчә, аның татар әдипләре иҗатына йогынтысы көчле һәм бу тенденция тагын да көчәюгә һәм ныгуга таба йөз тота.

Миңнәхмәт СӘХАПОВ.
«Бердәм агым» китабыннан.
ТКН, 2006.

Мәдәни җомга
29 сентябрь
№38, 2023

ДӨЯ КҮЗЕ

Чыңгыз АЙТМАТОВ

(Дәвамы. Башы 35, 36, 37 нче саннарда).

Мин шундук җавап бирә алмадым. Әбәкер сөйләгән чакта миңа анын сүзләрендә күпмедер дөреслек тә бар шикелле тоелды. Ләкин ул шуны шулхәтле усаллык, дошманлык хисе белән әйтә! Ни өчен алай? Әллә мин кулсыз бер кешеме, йә булмаса Әбәкер эшләгәнне эшли алмаслык бер аңгырамы? Яисә минем укыган булуым миңа комачаулык итәме. Әнә шуны һич аңлый алмый утыра идем. Шулай да мин Сорокинга мөмкин кадәр тынычрак җавап бирергә тырыштым:

– Бирегә мин прицепщик булып эшләргә дип килдем. Минем өчен бик мөһим ул, ә камыт, чөелдерекләр белән эш итә беләм инде мин. Анысын бөтенегез дә беләсез, Әбәкер дә белә. Шул ук эшне дә эшләргә мөмкин дә, тик мин су ташырга теләмим. Принципиаль рәвештә теләмим.

– Бездә башка эш юк бит, – диде Сорокин.

– Булмагач, миңа кайтып китәргә туры килә инде, – дидем.

Хәлифә миңа күтәрелеп карады да кайгылы бер төс белән авыр сулап куйды.

– Камил, мин сиңа үз урынымны биреп, үзем су ташыр идем дә, син бит риза булмассың...

Хәлифә шулай әйтер дип беркем уйламаган иде. Үзенең яхшы күңелле булуы аркасындамы, әллә Әбәкер кычкырынган, сүгенгән чагында аның өчен гел уңайсызланганга, аның өчен оялгангамы, Хәлифә аның аның тупаслыгын, дорфалыгын һәрвакыт йомшартырга, шомартып җибәрергә тырыша иде – әллә шуннанмы яисә башка бер сәбәптәнме – Хәлифә әнә шулай дип әйтте, һәм мин, аны-моны уйлап тормастан:

– Риза! – дип ычкындырып ташладым.

Тирмә эче бөтенләй тып-тын булып калды. Учактагы чыбыкларның гына чыелдап, чырт-чырт итеп янганы ишетелә иде. Барысы да, аптырашып, миңа карадылар. Кешеләр, бәлки, мине акылыма килеп, сүземнән кире кайтыр дип уйлаганнардыр? Үземне дошман күргән, миңа көн күрсәтмәгән әшәке кешенең тырнагы астына үзем барып керәм булып чыга бит. Ләкин мин эндәшмәдем. Әйткән сүз – аткан ук. Сорокин миңа тагын бер тапкыр сынаган кебек текәлеп карады.

– Чынлап шулаймы? – дип сорады ул ике сүз белән генә.

– Әйе, – дидем мин.

– Ә миңа барыбер! – диде Әбәкер, учакка төкереп. – Тик алдан ук кисәтеп куям, бел, чак кына да ул-бу булды исә муен тамырыңа бирәчәкмен! – Ярым караңгыда Әбәкернең күзләре мыскыллы, үчлекле бер чаткы белән салкын гына ялтырап китте.

– Ә нәрсә? Алдан ук куркытып куймакчы буласыңмы? – диде, ниһаять, Әсәркәп, түземичә. – Эшләр, әллә ни сәләт җитмәслек эш түгел! Минем сабанда эшләп карады ул.

– Синнән сорамыйлар. Кеше эшенә тыгылма. Без үзебез карарбыз. Трактор өчен, эш өчен мин җавап бирәм...

Сорокин ризасыз бер төс белән:

– Туктале! – дип, Әбәкер сүзеннән бүлде дә миңа: – Иртәгә иртән эшкә кереш, – диде. Торып, ишектән чыгып барганда: – Ә хәзер ял итегез... – диде.

Бу төнне мин бөтенләй йокламадым диярлек. Әбәкер белән эшләр ничек булыр икән минем? Моңарчы бит мин аның белән ара-тирә генә очраша идем, ә менә иртәгәдән башлап көндез дә, төнлә дә аның белән бергә эшләргә, аңа буйсынырга тиешмен. Прицепщик эше түземлек, чыдамлык сораса да, мин ул эштән курыкмыйм. Билгеле, тракторны бер генә минутка да туктатмас өчен, сабан төрәннәрен нәкъ кирәк урынында тиз генә күтәреп, төшерә белергә өйрәнергә кирәк. Моннан тыш әле мин тракторчыга машинаны караганда, ремонтлаганда да гел ярдәм итәргә тиешмен. Әбәкергә ялгыш икенче бер ачкычны, башка болт яки гайканы биреп кара син...

Әлдәй дә йокламый ята икән. Караңгыда ул минем янга килеп утырды да башымнан сыйпап әйтте:

– Камил, шулай да уйлап кара әле. Аның белән эшли алмассың бит. Син юаш, йомшак күңелле егет. Интектереп бетерер үзеңне, яраша алмассың син аңа...

– Ә мин аңа ярашырга җыенмыйм да. Интектерүенә анысы гадәтләндем инде.

штурвалына чытырдап ябышкан куллар – бу минутта минем халәтем әнә шундый иде. Эшкә башлаганнан бирле мин дә бер сүз эндәшмәдем, хәтта Әбәкер тракторны ташлы җирләрдән әшәке-усал бер үҗәтлек белән уздырганда да ләм-мим сүз ычкындырмадым – андый төшләрдә әле сабан буразнадан чыгып китә, әле төрән кискечләре чакматашта чыкыр-чыкыр килеп очкыннар һәм көек исләре чыгара, ә мин утыргычта дырык-дырык сикергәләп барам. Кичке якта, Әбәкер тракторны туктаткач, гомеремдә булмаганча коточкыч бер арыганлык-хәлсезлек тойдым. Минем авыз, борын, күз, колакларыма тузан белән ком тулган иде. Шундук җиргә сузылып ятасы да йоклап китәсе килә

Әлдәй шыпырт кына:

–Ярар, алайса, үзең кара инде, – диде дә, көрсенеп куеп, урынына китеп ятты.

3

Әбәкер белән ике арада көрәш беренче көннән үк башланды. Сукаларга керешер алдыннан ул:

– Кара аны, йоклап китеп, төрән астына эләксәң, җавап бирмим! – дип, бер генә авыз сүз әйтте.

Йоклап йөрерлек хәлдә идемме соң мин! Бөтен тәнем-җаным белән җигелеп, беркем тел-теш тидерә алмаслык, әйбәт итеп эшләргә җыена идем. Берәр ничек төрән астына эләгү ихтималын уйласаң, бу эшкә керешәсе дә юк.

Анысы хак – мин аякларымны җәеп утырган сабан рамы астына гына кронштейннар белән корыч төрәннәр беркетелгән. Ул төрәннәр, кыйгачлабрак, бер-бер артлы урнаштырылган хәлдә, чирәм җирнең кәсле катламнарын актарып, тузан очырта-очырта әйләндереп сала баралар. Трактор бер дә туктамыйча, чылбырларын шалтыратып, каты гөрли-гөрли, әремнәрне җиргә сытып бара.

Әбәкер бер генә тапкыр да миңа таба әйләнеп карамады. Мин аның фәкать тискәрелек-үҗәтлек белән каткан таза муенын гына күрдем. Шушы хәл үзе генә дә Әбәкернең мине йә бу эштән баш тартканчы, йә эшли алырыма ышанганчы сынаячагын әйтеп тора иде. Ихтимал, ул юри мине хәлдән тайсын, бирешсен дип, тракторны туктаусыз куганды да. Кем кем дигәндә дә, Әбәкер бернинди сиртмәсе булмаган каты тимер утыргычта ачы төтен белән тузан йотып утырып йөрүнең нинди эш икәнен яхшы белә инде. Ләкин минем бирешергә исәбемдә дә юк иде. Бөтен дикъкатьне туплап киерелгән нервы, күз, колаклар, сабан

иде. Ләкин урынымнан кузгалмадым да, Әбәкернең боерыкларын көттем.

– Төрәннәрне күтәр! – дип кычкырды ул миңа, кабинадан башын сузып. Шуннан соң тракторны сөргән җирдән чыгарды да, моторны сүндереп, сабан янына килде. Төрәннәр өстенә иелеп, кискечләренең үткенлеген тикшереп карагач: – Алмаштырырга кирәк, үтмәсләнгәннәр. Иртәнгә чаклы эшләп куелган булсын! – диде.

– Ярар. Запас кискечләр калдыр, аннары тракторны сабаннан читкәрәк алып кит, – дидем мин.

Әбәкер мин әйткәнне эшләде дә дәшми-тынмый кыр станына таба китеп барды. Мин аның артыннан карап калдым, шунда үземнең аңа ачуым кайнавын гына түгел, аңардан көнләшүемне дә сиздем. Әбәкер, бөтенләй арымаган да, талчыкмаган да шикелле, салмак кына, җәйга гына атлап китеп бара. Ул минем тәмам җанымны суырды суырсын, әмма үзе дә бер минут ял итмәде бит. Менә ничек эшли белә бит ул, эт җан!

Тирән итеп сулап куйдым да кура җыярга керештем, кочак-кочак сабан янына китереп салдым. Төнлә ут ягып, төрән кискечләрен алыштырып өлгерергә кирәк иде. Зур бер өем итеп кура җыйгач, ашап килим дип, станга киттем.

Әй Әлдәй, мәрхәмәтле җан икәнсең! Миңа дип ул калдырган бишбармакны бер сүз дәшмичә ашыга-ашыга ашаган чагымда, Әлдәй шундый кайгырып, шундый борчылып карап утырды. Ә минем озаклап утырырлык вакытым юк иде. Аңардан фонарь сорадым – кирәк булганда-ниткәндә, безнең фонаребыз да бар иде.

– Нигә ул сиңа? – диде Әлдәй, фонарьны биреп.

– Кирәк. Төрәннәрне алмаштырам.

– Ниткән хәл инде бу, кая яраган эш инде бу! – дип кычкырып җибәрде Әлдәй, Әбәкергә карап. – Малайны шулхәтле мыскыл итәргә ирек бирмәм!

– Миңа ни, бирмә соң, – дип кенә җавап кайтарды Әбәкер, йокларга ята башлап.

– Кысылма син! Камилнең үз башы да бар, – диде Садабәк хатынына.

– Ярар, Камил, без сиңа булышырбыз. Әйдә киттек, Әсәркәп! – дип, Хәлифә дә кузгалып, минем белән барырга җыенды.

– Кирәкми. Борчылмагыз. Үзем дә алмаштырам мин аны, – дидем мин.

Шулай дигәч, фонарь белән юлны яктыртып, тирмәдән чыгып киттем.

Бөтен тирә-юньне өнсез-тынсыз, иксез-чиксез төн караңгысы баскан иде. Мин, су эчим дип, беравыкка гына чишмәгә сугылдым. Чишмә авызыннан ишетелер-ишетелмәс кенә, былык-былык итеп, су чыга, чишмә үзе рәхәт бер салкынлык һәм тынычлык сирпеп ята сыман. Кара-кучкыл уйчан чоңгылы эченнән тонык кына булып ялтырап тора. Чыннан да, дөя күзенә охшаган бит. Шунда теге сакманчы кыз искә төште. Теге вакытта мин аның хәтта исемен дә сорарга өлгермәдем. Хәзер кайда икән ул – маңгаенда чәч чугы йөрткән сөйкемле кыз?

Сабан янына килеп җитү белән үк, эшкә керештем. Төрәннәрне күтәртеп куйдым, учак ягып җибәрдем. Фонарь да бик ярап куйды. Мин гайкаларны берәм-берәм борып алып болтка кигезәм дә, югалмасыннар дип, кепкама сала барам. Төн буе сабан астында мәш килдем. Гайкаларны боруы бик авыр, аннан да бигрәк җайсыз. Алар ачкыч тыгып булмаслык бик җайсыз оялар да утыра иде. Ул арада учак та сүнеп китә. Мин, елан шикелле шуышып, сабан астыннан чыгам да, җиргә ятып, яңадан учак тергезергә керешәм. Төннең кай вакытлары җиткәндер – белмим, әмма бөтен кискечләрне алмаштырып бетермичә эшемнән туктамадым. Аннары, томанда йөзгән кебек чайкала-чайкала, трактор янына барып җиттем дә кабинага кереп аудым. Тырналып беткән беләк-кулларым йокларганда да әрнеп янды.

Иртән иртүк мине Хәлифә килеп уятты. Мичкә белән су китергән иде.

– Радиаторга су салдым. Кил, юын, Камил, су салып торам, – дип чакырды ул.

Хәлифә миннән берни сорашмады, шуның өчен аңа күңелемнән рәхмәт укыдым. Кешеләрнең сине һаман-һаман кызганулары да күңелгә тия шул. Мин юынгач, Хәлифә арбадан төенчек белән азык һәм бер шешә ярма алып килде. Кыздырган ярмадан әчеткән куасны эчкәч, шундый да рәхәт булып китте! Рәхмәт яугыры, Әлдәй шулай кайгырта инде.

Әбәкер дә килеп җитте. Бер сүз әйтмәде. Бәйләнерлек сәбәп юк шул. Дәшми-тынмый гына тракторны сабан янына китерде, мин сабанны алкасыннан эләктереп тагып куйдым. Һәм шуннан соң тагын кыр буйлап җир сөреп киттек.

Бу көнне инде сабанда бер дә курыкмыйча, тыныч йөрдем. Үз-үземә ышанычым артты минем. Беренче сынауга түзгәч, ахыргача бирешмәскә тырышачакмын.

Минем алда кабина тәрәзәсеннән һаман да үҗәтлегенә, үз кирсенә каткан таза муен күренеп бара. Трактор, чылбырларын чылтыратып, көчәнеп үкерә-үкерә, туктаусыз сөрә дә сөрә. Мин дә, кулларым белән штурвалга ябышкан килеш, сабан өстендә утырып йөрим.

Төш җиткәч, Әбәкер көтмәгәндә генә моторны сүндерде дә:

– Төш! Тәнәфес, – диде.

(Дәвамы киләсе санда.)

«Сугышчан Дан клубы» ассоциациясе рәисе Михаил Черепанов исеме «Мәдәни җомга» газетасы укучыларына яхшы таныш. Ул 1983 елдан бирле Бөек Ватан сугышы фронтларында ятып калган хәрбиләрнең җәсәден эзләү экспедицияләрендә катнаша, хәбәрсез югалган якташларыбызның исемнәрен һәм данын кайтару өчен бәһаләп бетергесез көч куя. «Россиядә андый гаилә юк» дип аталган акциядә катнашып, ассоциация тырышлыгы белән 2019 елның ноябреннән башлап кына да фронтта яки әсирлектә вафат булган, әмма хәбәрсез югалган дип саналучы 24500 дән артык татарстанлының үлем нечкәлекләре ачыкланган. Шул рәвешчә хәбәрсез саналган дип саналучы якташларыбыз арасыннан әле тагын 150 меңгә якын туганнарыбызның язмышын ачыклыйсы бар. Безнең өчен хәтер һәм дарыны уяу тоту мөһим. Фронтта һәлак булганнарның исемен дә, алар кылган батырлык үрнәкләрен тергезү дә үтә читен гамәл. Шулай да, сезнең игътибарга яу кырында каһарманлык кылып, Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителгән, әмма шул дәрәҗәне алалмыйча киткән милләттәшләр атын бәян итик әле.

Йолдызсыз калган татарлар

Абдраков Николай Гобәй (Григорий) улы, 1924 елда Башкортстанның Федоров районындагы Юрматы авылында туган. Фронтка 1942 елда Татарстанның Саба районыннан чакырылган. 1943 елдан башлап II, III һәм IV нче Украин фронтларында сугыша. 1943 елда яралана. Аннан соң III Украин фронтында, 4 нче гвардия армиясенең 40 нчы Кызыл байраклы гвардия дивизиясендәге 119 нчы гвардия укчы полкында автоматчылар отделениесе командиры, сержант булып хезмәт итә. Венгрияне фашистлардан азат иткән чакта, аның отделениесе Харта авылы янында Дунай елгасын иң беренче булып кичә, каршы ярда дошман траншеяларына бәреп керә. Кул сугышында 6 венгр, 5 немец солдаты юк ителә. Плацдармны киңәйтеп, Абдраковчылар башка совет сугышчылары өчен дә елганы югалтуларсыз кичү өчен җирлек хәзерли. Шушы каһарманлыгы өчен Н.Абдраков 1943 елның 2 декабрендә Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, әмма үзе бу хакта белмичә дә кала. Чөнки ул 1 декабрь көнне Венгриянең Калоча шәһәрен азат иткән чакта һәлак була һәм шунда җирләнә. Вафат икәнен белеп алгач, аны фәкать Сугышчан Кызыл байрак ордены белән генә бүләклиләр.

Габдрәфыйков Нурмөхәммәт - 1923 елда Башкортстандагы Ярмәкәй районының Усман-Ташлы авылында туган татар, фронтка 1941 елда Татарстанның Чистай комиссариаты тарафыннан чакырылган. 1943 елдан соң Үзәк фронтта һәм I Украина фронтында сугыша, аннары II Украин фронтының 52 нче армиясендәге 2 нче аерым Умань бригадасында 1329 нчы полкның орудие командиры, кече сержант була.

1944 елның 30 маенда Румыниянең Яссы каласы янында фашистлар 70 танк, 40 бронетранспортёр артына качып, 197 нче биеклекне кабат үзләренә кайтару өчен һөҗүмгә ташлана. Габдрәфыйков батареясы әлеге һөҗүмне нәкъ үзәктә торып каршылый һәм гитлерчыларның өч «Тигр» танкы белән 15 солдатын юк итә. Яу барышында Нурмөхәммәт орудиесе составындагы 3 сугышчы яралана. Орудие тулысынча сафтан чыккач, татар сержанты танкка каршы мылтыктан атып, дошманның тагын бер аждаһасын юкка чыгара. Аннары пулемёттан туктаусыз ут ачып, 50 гә якын гитлерчыны юк итә. 12 сәгать буе барган сугыштан соң гына, татар сержанты запас рубежга чигенә.

1944 елның 7 июлендә ул Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, ләкин аны да фәкать Кызыл байрак ордены белән генә бүләклиләр.

Әминов Зөфәр Закир улы, 1916 елда Башкортстанның Туймазы районында туа, 1941 елның 1 декабренда сугышка озатыла. 112 нче Башкорт дивизиясендәге 294 нче кавалерия полкында эскадронның отделение башлыгы, өлкән сержант булып хезмәт итә. Көньяк-Көнбатыш фронтта сугыша. 1943 елның 21 гыйнварында Ростов өлкәсен азат иткәндә Әминов 30 кызыл сугышчы белән бергә бер биеклекне яулау һәм аны дивизиянең төп көчләре килеп җиткәнче үз кулында тоту турында фәрман ала. Фашистлар 7 мәртәбә һөҗүмгә ташланып карый, ләкин зур югалтулар кичереп, кире чигенә.

22 гыйнварда биеклекне 10 дошман танкы штурмлап карый, Әминов үз иптәшләре белән аларның өчесен шундук юк итә. Моннан тыш, алар дошманның бер бронемашинасын һәм 300 гә якын пехотачысын сафтан чыгара. Ике тәүлеккә сузылган бәрелеш барышында совет солдатларының барысы да һәлак була, әмма дошман совет тылына үтеп керә алмый. Сержант Әминов Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, тик аны да фәкать «Ватан сугышы» ордены белән генә бүләклиләр.



Все графы заполнять полностью

Наградной лист

1. Фамилия, имя и отчество Аминов Зуфар Занирович
2. Звание Ст. Сержант 3. Должность, часть Ком. отделение 1-го эскадрона 294-го Кав. Полка 112-Кав. Див.

Представляется к Герою Советского Союза

4. Год рождения 1916 5. Национальность Башк. 6. Партийность б. п.
7. Участие в гражданской войне и в последующих боевых действиях по защите СССР (где, когда) Юго-Зап. фронт. 294 кавполка 112-КД. 14.1.43 г.
8. Имеет ли ранения и контузии в отечественной войне Убит 22.1.43 г.
9. С какого времени в Красной Армии С 1.12.41 г. 10. Каким РВК призван Туймазинским РВК. Баш. АССР.
11. Чем ранее награжден (за какие отличие) Не имеет.
12. Постоянный домашний адрес (представляемого к награждению или его семьи)

ДЛЯ ПОДШИВКИ

1. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг

[illegible]

(Дәвамы киләсе санда).

Михаил ЧЕРЕПАНОВ.
«Миллиард татар» челтәреннән.
Вахит ИМАМОВ тәрҗемәсе.

● Уразай мәктәбе диварына беркетелгән мемориал такта.

● Бөек Ватан сугышыннан исән кайткан әдипләр. Беренче рәттә (сулдан уңга): Әдип Маликов, Мөнир Мазунов, Сибгат Хәким, Зәйни Шаһиморатов, Мәхмүт Хөсәен, Шәрәф Мөдәррис. Икенче рәттә: Халик Садри, Шәйхи Маннур, Әхмәт Ерикәй, Афзал Шамов, Риза Ишморат, Госман Бакиров. Өченче рәттә: Габдрахман Әпсәламов, Гамир Насрый, Әсгат Айдар, Абдулла Әхмәт, Василий Земной, Хатыйп Госман. Дүртенче рәттә: Әмирхан Еники, Әхмәт Исхак, Әхмәт Фәйзи, Хәсән Шабанов. 1947 ел, 27 апрель.

РИЗА ИШМОРАТ

Танылган драматург, Бөек Ватан сугышы ветераны Риза ага Ишморатның тууына 100 ел тулу бәйрәмен әле яңарак кына үткәргән сыман идек. Гомер дәрьясы тау елгасы кебек кайнап ага, артка борылып карарга ди форсат калдырмый бит, менә инде Риза ага тууның 120 еллыгы да килеп җиткән.

Туган як һәрчак якын, газиз әткәй-әнкәй йорты сыман, гел-гел үзенә тарта инде ул. «Риза ага Ишморат тууның 120 еллыгын үткәрәбез», дигән чакыру алгач та, һич тә ялындырып тормыйча, ерак юлга чыктык. Гәрчә юл газабы – гүр газабы, дигәннәре дә хактыр, Чаллыдан соң һәр ун чакрым саен юлларны урый-урый, ә Пучы белән Актаныш арасының кайбер урыннарын шуышып кына үтәргә мәҗбүр булдык. XXI гасыр өчен коточкыч хәл, әлбәттә.

Ә Уразай авылы һәрвакыттагыча матур, күркәм, кабатланмас. Мәктәп алдында җәелгән искитмәле көләч, гаҗәеп зур күлне фәкать монда гына күреп, аның суларына тукталган аккошларга тик Уразайда гына сокланып буладыр. Аның әле «Ишморат аланы» дигән янә бер гүзәл почмагы да бар икән, менә шул алан безне кочагына алды.

Нәкъ Риза ага үскән йорт каршына сузылган тау итәген нарат, каен, усак, зирек, шомырт агачлары сырып алган һәм, алдан заказ биреп куелган шикелле, нәкъ шушы йорт каршында матур, ачык алан хасил итә. Бүген анда сәхнә ясап, эскәмия-утыргычларны йорт буена тезеп куйганнар. Без кайтканда җыелган халык саны йөздән арткан иде, иртәнге ун тулуга янә шул кадәрле килеп өстәлделәр.

Зәңгәр төскә буялган йортның диварында Риза ага Ишморат портреты. Икенче почмак янында әлегә ак чүпрәк белән каплап куелган махсус стенд. Аны бик озак сузмыйча, Риза аганың тантанага кунак булып кайткан 86 яшьлек улы Рафаил Ишморат, Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат, Тукай бүләгенә лаек булган әдип Вахит Имамов, Актаныш район башлыгы урынбасары Илшат Габделхәев ачып җибәрде. Бактың исә, Бөек Ватан сугышына Риза аганың бертуганнары – 1902 елгы Зыя, 1908 елгы Һади, 1914 елгы Нәҗип атлы абый-энекәшләре дә чыгып киткән, шушы дүрт бертуганның дүртесе дә Кызыл Йолдыз орденнарына лаек булган, тик Зыя, Һади, Нәҗип чит-ят җирдә ятып калган икән... Риза аганың үзенә дә Воронеждан алып Берлинга кадәр канлы сугыш юллары аша узарга туры килә, Берлин урамындагы һөҗүмнәр вакытында авыр яралана, Ходай Тәгалә тәкъдире белән генә сәламәтләнеп, аягына баса... Бер гаиләдән дүрт Кызыл Йолдыз ордены кавалеры – бик тә сирәк фидакярлык, сирәк очрак...

Шушы дүрт малай да бүген зәңгәр төстәге диварлары белән балкып торган йортта аякка баскан. Гәрчә өч өлкәне Яңавыл районының Бәдрәш авылында дөньяга килә. Уразай егете Фәхретдинне XIX гасыр ахырында шул Бәдрәш авылындагы мәдрәсәгә хәлфә итеп

● **Сугыштан кайтмый калган язучыларыбыз. Өстән беренче рәт (сулдан уңга): Абдулла Алиш, Аитзак Аитов, Демьян Фәтхи, Әгъзам Камал, Хәбрә Рахман. Уртадагы рәт: Мөхәммәт Әхмәтгалиев, Нур Баян, Касыйм Вахит, Мифтах Вәдүт, Фатих Кәрим. Астагы рәт: Муса Җәлил, Гадел Кутуй, Габдулла Галиев, Макс Гатау, Мансур Гаяз.**

● **Биш татар әдибе.**

АЛАНЫ

чакыралар да, аның яшьлек еллары сабыйларга гыйлем биреп үтә. Аннары ул Йосыф авылына мулла булып күчә. Һәм фәкать 1913 елда гына кабаттан туган авылы Уразайга әйләнеп кайта.

Риза агабыз да Бәдрәш авылында 1903 елда туган. Әүвәл әтисе эшләгән мәдрәсәдә, ә 1910-1915 елларда Сараш авылында рус-татар мәктәбендә белем алган. 1916 елда ул инде Минзәлә шәһәрендә гыйлем эстәвен дәвам итә, аннары Уфа каласындагы «Госмания» мәдрәсәсендә укый. 1919-1922 елларда педагогия техникумын, 1923-1926 елларда Казан театр техникумын тәмамлый. Аны тәмамлауга ук Казан драма театрында режиссерлык эшенә алына, бер-бер артлы ике пьеса язып, аларны үзе үк сәхнәләргә куя. 1927 елда Риза аганы Ленинградның югары сәнгать тарихы институтына укырга җибәрәләр. Аны тәмамлау кайтуга, 1931 елдан башлап ул Татар дәүләт театрында режиссерлар коллегиясе җитәкчесе һәм әдәби бүлек мөдире булып эшли башлый. Утызынчы елларда үзенең дистәгә якын драмаларын сәхнәгә мендерә.

Үзе үк ялварып диярлек йөрийөри, 1942 елның май аенда Бөек Ватан сугышына китә, 1 Украина фронтонда «Ватан намусы өчен» газетасында әүвәл хәрби хәбәрче, соңрак редактор урынбасары булып эшли, майор дәрәҗәсенә ирешә, «Кызыл Йолдыз» һәм «Ватан сугышы» орденнары белән бүләкләнә. Сугышның иң соңгы көннәрендә, Берлин урамнарында яралануы турында әйтеп үттек. Сугыштан соң Риза ага тулысынча иҗат эшенә бирелә, барлыгы 40 ка якын пьеса тудыра. «Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе» дәрәҗәләренә лаек була.

Ул, әлбәттә, Татарстанның һәм аеруча Актанышның патриоты иде. Аның ел саен җәй җитүгә Уразайга яисә Сөн буендагы Чишмә, Меңнәр авылларына кунакка кайтып төшүе турында бүген дә сагынып искә алалар. Кайвакытта ул үз янына Казаннан Сара Садыйкова, Мостафа Ногманнарны да дәшеп кайтара, «Бер гүзәлен сагынам Чишмәнең» яки «Акчарлаклар очып уйный» җырлары нәү шулай, бергәлектә туа...

Актаныштa терәк табуы белән Риза ага, мөгаен, бәхетледер. Яңавылда, әнә, шул туфракта туып-үскән һәм татар-башкорт халыкларының уртак мәдәнияты өчен хезмәт иткән Нурихан ага Фәттах, Саҗидә Сөләйманова, Нил Юзеевларның һичбер төрле истәлек тактасы да, һәйкәлбюстлары, алар исемнәрендәге мәктәп-китапханәләр дә юк. Шул исәптән Риза ага да – алар өчен үги. Ходайның рәхмәте белән, ярый әле, Актаныш туфрагы бар. Бирedә район үзәгендә Риза агага бюст куелган, Уразай тугызъеллык мәктәбе аның исемен йөртә. Мәктәптә музее эшли, иң мөһиме – ул кәгазь яки такталарда түгел, ә халык күңелендә, хәтерендә яши...

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

Россиянең патша хөкүмәте үз тырнагы астында калган татар һәм башкорт милләтләрен туктаусыз талау гына түгел, ә дәүләт мәнфәгатьләрен яклау, империянең чикләрен киңәйтү өчен дә алар көченнән оста файдаланган. Алтын Урда составында татар-башкорт җайдаклары Туктамыш хан кул астында Воркcла (Бурсыклы) елгасы буена җитеп, анда Литва кенәзе Ягайло янына качкан хыянәтче Идегәй морза гаскәренә каршы милләт өчен бөтенләй дә кирәкмәгән яуларда кан койса, XVIII гасырдагы патша хөкүмәте гаҗәеп тугрылыкка ия мөселман яугирләрен империя мәнфәгатен инде Европа күләмендә яклаучы яңа хәрби походларда да бик оста рәвештә куллана башлый. Шундыйларның беренчесе – 1757 елда Пруссиягә каршы оештырылган яу походы. Гәрчә Мәскәү һәм Уфа тарафыннан чыгарылган барча китапларда әлеге яу «Башкорт-мишәр гаскәренең Пруссиягә походы» дигән мөһер белән тасвир кылынса да, анда катнашучы җайдакларның ким дигәндә яртысын татар яугирләре тәшкил итә.

волосте башлыгы Ибраһим Мерәсев җыеп килә. Аннары Казан юлында Дуван-Табын волостеннан – Муаш Чирмәнев, Канлы волостеннан (бүгенге Бүздәк районы) - Муса Сөлтеков, Телтем-Юрматы олысыннан – Пулат Җилекәев, Юрматы олысыннан (Туймазы) – Моталлап Кулчуков, Каршиннан – Әхмәр Шәрипов, Кыр-Елан волостеннан (Шуран-Ярмәкәй) – Мәскәү Дәүләткулов, Елан олысыннан дык Айдаров, **Җәнжегеттән** (Краснокама районы) – Аблай Сәетов, **Кабаннан** – Ырысбай Сәфәров, **Мерәстән** – Мәсәгуть Үтәмешев, Сөендек Биккенин, **Апачтан** – Мансур Мортазин, Сатый Бәширов, Ибраһим Уразов, **Такталачыктан** – Мокай Чәчәнев, **Илчебайдан** – Курманай Ишалин, **Бикбаудан** (Минзәлә районында) – Габдулла Карашаев, Морат Мусеев, Акай Мукаев, Мәсәгуть Мөслимов,

ТАТАР ҖАЙДАКЛАРЫ

ПРУССИЯГӘ ПОХОД

Сүзебез буш булмасын, тасвирлауга күчик. Ул чакта Россия империясе белән Петр Беренченең кызы патшабикә Елизавета идарә итә. Елизавета – әтисе кебек үк, Россиягә җаны-тәне белән гашыйк хаким. Ә аның улы Петр III – моның нәкъ киресе, ул Пруссия короле Фридрих Вильгелм II каршында ләббәйкәгә бии, хәтта, үзенә бирелгән өйрәнчек полк солдатларын да Пруссиянең хәрби киемнәренә төреп бетерә, муштралау һәм сугышчан кораллану да немец таләпләренә буйсындырыла. Король Фридрих үзе дә дуамал, тәкәббер һәм туймас, ул 1740 елларда ук Австрия империясенә һөҗүм итеп, Силезия өлкәсен тартып ала. Дошманнар котырасын алдан сизенгәндер, прусс короле Фридрих Англия белән дуслык килешүе төзеп куя. Рәнҗетелгән Австрия, җавап итеп, әүвәл Франция белән хәрби союз төзи, аңа тора-бара Россия дә кушыла. Пруссияле Фридрих үз кул астында 200 мең кешелек армия төзесә, аңа каршы «өчлек» союзы 420 мең солдатлы гаскәр туплап куя. Елизавета Петровна фәрманы буенча, Россия 65 мең кешелек корпус әзерли, аның составына 500 «башкорт»-мишәр җайдагы да кертелә.

1757 елның җәендә фельдмаршал С.Ф.Апраксин кул астындагы рус корпусы Көнчыгыш Пруссия җиренә басып керә, Гросс-Егерсдорф крепосте янында алар прусс армиясен тар-тар итүгә дә ирешә. Шул вакытта Апраксинга патшабикә Елизаветаның Петербургта кинәт чирләп китүе турында хәбәр килеп җитә. Әгәр Елизавета вафат булып, тәхеткә Петр III менсә, ул пруссак Фридрих мөриде бит, фельдмаршалга үтә яман җәза эләгү дә мөмкин. Менә шундый уйлар кичереп, Апраксин үз корпусын Пруссиядән Курляндия (хәзерге Литва-Эстония) җиренә алып чыга. Ә мондый хыянәтне белеп алгуа, Елизавета Апраксинны кулга алырга боера да төрмәгә ташлаттыра, теге бичара бер

● **«Башкорт» җайдаклары 1813 елда Германиядә.** Б.П. Виллевальде. XIX гасыр.

● **Иравыл-разведка отрядындагы «башкорт».** Г.Верне эше. XIX гасыр.

ел да чыдый алмыйча, шунда җанын тәслим кыла...

Бик данлыклы, күкрәк сугып мактанырдай поход түгел-түгелен. Әмма барыбер яугирләрнең байтагына медаль өләшәләр, «Прусс походы» телдән-телгә күчә. Инде хәзер ошбу яуда кайсы төбәк яугирләре катнашуын күрик.

Походта 500 яугир өстеннән Кара-Табын волостеның (Башкортстанның хәзерге Әлшәй һәм Дәүләкән җирләре) башкорт старшинасы Кыдрач Муллакаев баш житәкче булып йөри (бу кеше әле 26 ел үткәннән соң да исән-сау, ул Пугачев явы барышында әле фетнәчеләр, әле җәзачылар ягына күчеп йөри, ахырда Әби патша җәлладлары на «падишаһ» бригадиры Канзафар Усаевны /Хөсәеновны/ арканнарга бәйләнгән көенчә китереп тапшыра). Бүгенге Актаныш районы чикләрендә урнашкан Гәрәй волостеның «башкорт катламы»на язылган татарлар старшинасы Тимер Мутин (атаклы драма артисты Мохтар Мутинның ерак бабасы) Кыдрачның ярдәмчесе ролен башкара.

Походта, әлбәттә, улчактагы Уфа провинциясендәге Себер һәм Ногай юлларыннан берничә башкорт старшинасы да катнаша. Себер һәм Ногай юлларыннан Шайтан-Көзәй волосте (Салават Юлаев туган җир) старшинасы Хәсән Муллакаев (аны бераздан Юлай Азналин алыштырачак), Кыркүлә-Мең волосте башлыгы Галибай Морзагулов (ул бераздан Ногай юлының баш старшинасына әверелачәк һәм Пугачев явы барышында ике якка да күчеп йөриячәк), Бөрҗән олысы старшинасы Шәрип Казанчиев, Йомрак-Табын олысы башлыгы Кәипкул Аслыкаев, Кумырык-Табын волостеннан старшина Якшымбәм Ырысов үз командаларын туплап килә. Яныш Абдуллин атлы мишәр старшинасы – Себер юлында, Галикәй Мөслимов атлысы Казан юлында яткан волостьлардагы мишәрләрне туплый. Яныш Абдуллинга соңыннан Пугачев явында мишәр бригадиры булып танылачак Бәхтияр Канкаев туган Кущин волостеның Олы һәм Урта Ака, Бәхтияргә үз яугирләрен биргән Кызылбай, Мишәр, Усак, Богалыш һ.б. авыллардагы сугышчылар буйсына. Казан юлында Галикәй Мөслимов хәзерге Кушнаренко районындагы Байталлы, Кормаш авылларыннан, алардан тыш Бүздәк, Чакмагыш, Тәтешле, Чишмә районнарыннан да татар-мишәр сугышчыларын җыя. Уса юлыннан мишәр старшинасы Сөләйман Диваев үз отрядын туплый. Ногай юлыннан татар-типтәрләрне Үршәк-Мең (Илеш районы) – Үтәгол Нурбакин, Әгерҗе жирендәге Йәнәйдән – Айдар Уразмәтов, бүгенге Актаныш-Мөслимдәге Буләр волостеннан Гали Ярмөхәммәтов үз отрядлары белән 500 кешелек махсус полкка кушыла. Чокыр авылы йөзбашы Йосыф Күчкилдин туплаган йөзлек тә бүгенге Тәтешле районындагы авыл җайдакларын тәшкил итә. Аннары хәтта Кыдрач Муллакаев кул астына баскан җайдаклар да әлек Кара-Табын олысына караучы Әлшәй, Сипәш, Әгерҗедән күчеп киткән Иске Эсләк, Актаныштан аерылып чыккан Чуракай авылы татарларыннан һәм күршедәге Чишмә районына буйсынучы салалардан җыеп алынган бит...

Тагын да тәгаенрак булсын өчен, без **Йәнәй** волостеннан (нигездә, бүгенге Әгерҗе һәм Актаныш җирләре) тупланган җайдакларны саныйк. **Байсар** авылыннан «башкорт катламы»на язылган – Корыч Ирмәшев, Мостай Йосыфкулов, Баязит Бикчәнтәев, Исергәп Рангулов, **Әҗәкүлдән** – Габделмәннан Морзакаев, Сәетъягъфәр Габдуллин, Ишмөхәммәт Якупов, Мөхәммәтрәхим Мәхмүтов, Габдри Габдуллин, Әлкәй Ромашев, Шәриф Томралин, Рахманкул Гомәров, Якуп Мокаев, Мерәс Солтанов, Әҗәкүл Солтанаев, Сагынмөкъсин Мостаев, **Өшәрдән** (Семиостров) – Рысай Абызаев, Байсар Абызаев, Баязит Үтәмешев, Чәнәй Бигешев, Морат Сөрмәтев, Гомәр Бикмәтов, Ишәй Язүкәев, Бирдегол Чурагулов, **Суыксудан** – Арслан Сөендеков, Йөзекәй Юзеев, **Каентүбәдән** – Муса Бохаров, Уразай Юлдашев, Уразман Уразмаев, **Шәбездән** – Бакый Дөнгөлтеков, Муса Булатов, Ишдәүләт Ишәев, Мокай Акманаев, **Терпелебәдән** – Ишбулды Сүбәкев, Мәһди Иткинин, Әмир Кинҗәгулов, Усман Кинҗәков, **Үрмәкәйдән** (Туймазы районында) – Сәләй Искәндәров, Юныс Ибрашев, Әлкеш Гаделев, **Мәсәгутьтән** (Мөслим районы) – Ракай Туктаров, **Балтайдан** (Минзәләдә) – Тәмка Исәнәев, Алдияр Гаделев, **Көчектән** (Әгерҗедә) – Сәфәр Юлдашев, Песләктән (**Эсләктән** – Әгерҗе) – Сыртлан Таңатаров, Сарыйм Исәнбәтов, Сәгыйт Болтаев, Назырымбәт Бикчурин, Игеш Мөслимов, **Яңа Богадыдан** – Карашай Хөрмәтев, Кенәз Таһиров, Әит Туктаголов, Җәки Карашаев, Муса Заишев, Тайчи Ураев, **Сабайдан** (Бүздәк районында) – Арслан Юлдашев, **Аккүз** авылыннан (Әгерҗедә) Габдекәй Булатов, Йосыф Атнаголов, Мортаза Тукманов – барлыгы 80 гә якын җайдак! Алар өстенә, әле йомышлы татарлар

ЕВРОПАДА

көенә **Адай** авылыннан походка барган Мөхәммәт Кадермөхәммәтов һәм **Җизмыек** авылында туып, походтагы старшина булып йөргән һәм Казан юлындагы **Кыпчак, Мәскәү, Әсән, Бишкурай** авылы (Илеш һәм Дүртөйле районнарында) ирләрен буйсындырган Котлыкадәм Әитов. Әле Такталачык авылында яшәгән көе Гәрәй волостеннан (Актаныш районы) старшина Тимер Мутин иярте п шага азатлык таләп итеп яуга күтәрелә. Фетнәне канга батырып бастыру өчен Россия патшабикәсе Екатерина II – Әби патша 1771 елның 8 октябрендә Уфа провинциясеннән ашыгыч рәвештә 3000 җайдаклы корпус юллау турында фәрман игълан итә.

Хөкүмәтнең тугры коллары 1771 елның 16 декабрена «Башкорт» гаскәрен туплап та бетерә. Дүрт юлда исәпләнүче җайдагы белән бергә старшина Имәнгол Кутлин да кушыла. Шушы ук команданы бүгенге Илеш районында урнашкан һәм старшинасы Балта Сәфәров булган Сеңрән волосте һәм шул ук Илеш җирләренә туры килгән Елан волостеннан (старшиналары Сәлим Әитов) 50 ләп ир, Татарстанның бүгенге Мөслим районы җирләрендә урнашкан Ирәкте волосте старшинасы Шәрип Киеков юллаган 100 гә

Дүртенче партияне Ногай юлының бүгенге Әлшәй һәм Дәүләкән районнарында урнашкан авылларыннан туплыйлар. Кара-Табын волосте старшинасы булып торган һәм Пруссия походында катнашкан мишәр яугире Кәип Җыямбәтов команда башлыгы итеп билгеләнә. Шушы ук волостьта башкорт старшинасы булып торган Кыдрач Муллакаев, шушы ук Ногай юлында булып исәпләнгән Чүби-Мин олысы башлыгы Гайсә Якупов, бүгенге Актаныш районы җирләрендә урнашкан Гәрәй-Кыпчак олысы старшинасы Күчәдек Рахманкулов, Юрматы волосте (бүгенге Шаран һәм Туймазы) башлыклары Ишали Теләүмбәтов, Габдулла Әитов, Күчем Сөләев, Микәй Габдрахманов, Микәй Йосыпов, Атнагол Тимеров (атаклы Мутиннар нәселеннән, этисе Тимер Мутин Пруссия походында яу йөри), Зәет Абдуллин, Сабих Сарманов алып килгән җайдаклар буйсына.

Сигезенче партия Себер юлындагы Кущин олысы (Бәхтияр Канкаев иле) башлыгы Исәкәй Садиров кулына бирелә. Ләкин аңа да Уса юлындагы Гайнә олысыннан Туктамыш Ишбулатов алып килгән татарларны, Илеш Шарыев белән Таулыкай Чураков кул астында килгән Бөрҗән олысы башкортларын да кушып куялар.

● **Ялга туктаган «башкорт». җайдаклары.** А.О.Орловский эше. 1810 еллар.

● **«Башкорт-мишәр» гаскәрендәге җайдаклар.** А.Ф.Чернышев эше.

килгән актанышлы җайдакларның исемлеге ахыргача һаман ачыкланмаган. Ләкин шушы бер Йәнәй волосте буенча саналган һәм Казан белән Ногай юлында урнашкан олыслардагы татар старшиналарының исемнәрен атап чыгу үзе үк – Пруссия походында катнашкан «башкорт» җайдакларының яртысын татар һәм мишәр яугирләре тәшкил итүне бәхәссез исбатлый.

Татар җайдаклары Польша походында

«Башкорт» һәм мишәр җайдаклары бу рәвешле үзләренең патша тәхетенә тугрылыгын раслап күрсәткәннән соң, билгеле ки, аларны «майлырак» тагарак янында тоту һәм яңа хәрби максатларда файдалану үрчи генә бара. Әүвәл аларны казах ханлыклары чигендә төзелгән хәрби крепостьлардагы гарнизоннарда бишәр йөз яки бер мең кешелек отряд рәвешендә бер ел буе тотып, чик буен саклау хезмәтенә җигәләр. Ә көнбатыш чикләрдә Россия бөтенләегенә куркыныч туган очракта аларны Европа илләренә каршы җибәрүдән дә тартынып тормыйлар. Мондый яңа хәрби поход Пруссия явыннан соң 14 ел вакыт үткәч тә пәйда була. 1771 елда элекке Речь Посполитая дәүләтендә яшәүче конфедератлар Поль- төрле волостьлардан тупланган 3000 җайдакны 300 әр яугирле командаларга бүлеп чыгалар. Поляк крестьяннарына каршы юнәлтелгән «экспедиция» (кыру-җәзалау операцияләрен мендәрдән дә йомшаграк итеп тасвирлау буенча алар азау тешен чыгарган) корпусын генерал-поручик А.И.Бибиков җитәкли (ул ике елдан соң Пугачев фетнәсен һәм анда төп көч булган татар-башкорт крестьяннарын канга батыру өчен дә башкомандующий булып озатылачак һәм шунда җанын тәслим кылачак). Ә «башкорт корпусы» генерал-майор А.Урусов кул астына беркетелә. Һәр партия урыс офицерлары командалыгына бирелсә дә, «башкорт» яугирләре белән үз старшиналары җитәкчелек итә.

«Башкорт корпусы»ның баш старшинасы итеп бүгенге Башкортстанның Балтач районыннан чыккан Кулый Балтачев атлы мишәр яугирен билгелиләр. Һәр 300 яугирле команданың да аерым старшинасы пәйда була. Беренче партияне Уса юлының татарлар яшәгән Гайнә волосте старшинасы Рахманкул Иртуганов җитәкли. Партия составына Казан юлындагы Бүләр олысыннан (бүгенге Актаныш, Минзәлә, Мөслим авыллары) 110 га якын якын яугир белән дә ныгыталар.

Икенче 300 кешелек партия Себер юлындагы Сарт волосте старшинасы Үмәтәй Уразембәтов кулына бирелә. Аның кул астына Красноуфимск каласы белән чиктәш һәм бүгенге Мәчетле районында урнашкан Кущин волостеннан (атаклы Пугачев бригадиры Бәхтияр Канкаевны үстереп биргән Олы Ака, Урта Ака, Габдулла, Әзекәй, Богалыш, Кызылбай кебек татар-мишәр авыллары) старшиналар Малай Әсәнов белән Яхья Яхшыев кул астында килгән җайдакларны, Морзалар волостеннан нәкъ шундый ук татар-мишәрләрне җитәкләгән старшина Туманча Янбашкин, Казан юлының Елан волостеннан (бүгенге Илеш районы) старшина Сәлим Әитов һәм Дуванәй олысыннан (Чакмагыш, Кушнаренко) старшина Ихсан Баязитов яугирләрен өстиләр.

Өченче команданы Казан юлы старшинасы Миндекәй Габделгазизов җитәкли. Бу партиягә Йәнәй волосте (бүгенге Актаныш һәм Әгерҗе) старшиналары Шәрип Айдаров һәм Гали Ярмөхәммәтов, Байлар олысы (Минзәлә, Тукай, Актаныш) башлыклары Муса Хәсәнов белән Туйхуҗа Мәмәтов (Тукай районының Оргыды авылыннан) алып килгән йөзләкләр кертелә.

Котлыхуҗа Сәфәргулов белән Юлдаш Кутлин, бик тиздән Ногай юлының баш старшинасына әвереләчәк башкорт Галибай Морзагулов алда без атаган мишәр Кәип-яугир кул астына баса.

Бишенче партия, нигездә, Ногай юлындагы Катай һәм Тәмьян олысларыннан туплана. Команданы Катай волосте старшинасы Ишкенә Гаисов җитәкли. Ләкин бу команда да Юрматы (Туймазы) волосте старшинасы Сәйран Сәетов алып килгән татар җайдаклары белән ныгытыла. Алтынчы партия – Себер юлындагы 115 йортлы Шайтан-Көзәй волосте старшинасы Юлай Азналин – Салаватның этисе кулына бирелә. Ләкин бу командага да Ногай юлындагы Тәмьян волосте яугирләрен һәм Гәрәй-Кыпчак олысыннан (Краснокама районы) Арсланбәк Макшыгулов алып килгән җайдакларны кушып куялар.

Җиденче партияне Бүләр волосте (Актаныш, Мөслим, Минзәлә) старшинасы Муса Мөслимов җитәкли. Аңа Юрми (бүгенге Азнакай), Сарайлы-Мең (бүгенге Сарман), Гәрәй (Актаныш), Кыргыз (Актаныш һәм Илеш), Уран (бүгенге Тәтешле) волость старшиналары Биккенә Яушев,

Тугызынчы 300 кешелек командагы әлеге дә баягы Елан волосте (Илеш) старшинасы Зөбәер Йосыпов җитәкли. Аңа Казан юлындагы Елдәк, Гәрәй, Кыр-Елан, Каршин, Кыргыз, Нәдер олысларында (Илеш, Чакмагыш, Бүздәк, Актаныш, Әлмәт районнары) Баязит Килмәтов, Сабих Сарманов, Әхмәр Шәрипов, Аптыкай һәм Юлдаш Мәскәүовлар, Биккол Нурбакин, Зәет Абдуллин, Сөләйман Миңнегулов, Йосыф Нәдеров (атаклы Нәдер Урәзмәтовның улы) кебек старшиналар туплап юллаган татарлар буйсына.

Унынчы партияне Ногай юлының Тәмьян волостеннан чыккан Качкын Самаров җитәкли. Аңа Бушмас-Кыпчак олысы старшинасы, Пугачев явы барышында «Башкорт гаскәренең башкомандующие» дәрәҗәсенә ирешәчәк Кинҗә Арсланов, Пугачев гаскәренә иң беренче булып кушылган Ямансарый Япаров кул астындагы башкортлар, Казан юлындагы Шәмшәде һәм Кыпчак олысларыннан Ишбулды Мостаев белән Бүләк Гомәров, Кыр-Танып волостеннан шәхсән Кулый Балтачев алып килгән татар-мишәрләр буйсына.

(Дәвамы киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.

«Сезнең дустыгыз,

Казанда каһарман Зорге хөрмәтенә куелган бюст астында разведчик сүзе баш хәрефтән язылган. Анда: «Я сам себя обрёк на вечные скитанья. Не нужен страннику покой...» дигән җөмлә дә бар. Кайчак бу бюст янында ир-атлар туктап тын тора, шул ук вакытта: «Ә кем соң ул Зорге?» – дип сораучы яшьләр дә күп...

Разведчикларның язмышы катлаулы һәм күп очракта аларның үлеме билгесезлек пәрдәсе белән капланган. Аларның үлеме белән бәйле риваятьләр дә туа... Бу язмыш та шундый. Әйтик, исән калган фашист эте О.Скорцениның рус теленә тәрҗемә ителгән «Билгесез сугыш» китабында Германия чит эшләр рейхминистрының Япониядәге махсус илчесе Штамер рапортында «Р.Зорге русларга әсир төшкән Квантун армиясенең япон агентлары төркеменә алыштырылган», дип язылган җөмләне укып була. Шул ук китапта Зорге белән Токиодагы илчелектә очрашкалаган сәркатип (алар үзара дус булмый) Ганс Отто Мейснер («Өч йөзле кеше» китабы авторы, 1957) фикеренчә, «Әсирләр белән алышу Португалия Макаосы территориясендә булды, Зоргены анда генерал К.Доихара алып килде. Р.Зорге иң югары классلы агент, суперשпион булганга күрә, бу – бик тә мөмкин хәл», дип тә өстәлгән. Аның раславынча, имештер, суд карары чыгарга берничә атна калгач, Зорге: «Мин немец гражданы түгел, мин Советлар Союзы гражданы» дигән. Имеш, төрмә табибе карар чыгарып алдыннан аның тешләрен дәвалаган, ә төрмә тегүчесе Зоргеның киемен рәтләгән. Имештер, Зорге Советлар Союзының үзен кемгә дә булса алыштыруын көткән. Чөнки андый очраклар булган...

Әлбәттә, әлеге разведчикның ничек тә булса исән калуы безне куандырыр иде. Кайберәүләр: «Әгәр дә аны алмаштырган булсалар, Сталин аңа зур сәясәттән читтә яшәргә рөхсәт иткәндер, әмма ул барыбер күзәтү астында яшәгәндер, чөнки ул куркыныч кеше бит инде», дип тә уйлана башларга мөмкин. Тик барысын да күздән кичерсәк, мондый өметкә урын калмый.

Япон ханымы Ханако Исии аның хакындагы беренче китабын 1949 елда бастыра. Ул гомере буе Токио читендә, Зорге күмелгән зыярат янәшәсендә гомер итә. Илебез аңа башта шактый суммадагы матди булышлык күрсәтә. Ә 1990 елдан алып, СССР Ханакога, Зоргеның Япониядәге җәмгате буларак, пенсия түли башлый. Бу зур сумма булмаса да, ул моңа да шатлана. 1935 елның 4 октябрендә, Р.Зоргега 40 яшь тулган көндә башланган үзара дуслык разведчикны кулга алган көнгә кадәр дәвам итә. Ә 1935 елда япон кызы Токио үзәгендәге «Рейнгольд» немец ресторанында хостесс булып эшли. Алар шунда танышa...

Җанын фида кылырга әзер Р.Зоргеның эшчәнлеге хакында китаплар да, хәрби әсбаплар да язылачак әле, Икенче бөтендөнья сугышы тәмамлангач, америка хәрбиләре Япония архивыннан «Зорге эше»н табып алачак һәм анда тасвирланган мисалларны озак еллар буе үз хәрби мәктәпләрендә өйрәнәчәк.

Р.Зорге 1895 елның 4 октябрендә Россия империясенең нефть башкаласы – Баку янәшәсендәге Сабунчи шәһәрчегендә туа. Әтисе Адольф – бораулау скважиналары технигы, немец. Әнисе – Нина, Рязань губернасында туып үскән рус. (Әнисенә 1952 елга кадәр ГФРда яшәргә насыйп булачак). Рихард – гаиләдәге сигезенче, төпчек бала. Аның 4 абыйсы, 3 апасы бар. Аңа 3 яшь тулгач, гаилә Германиягә әйләнеп кайта. Алар яхшы яши, чөнки әтисе банк идарәсендә эшли. 1907 елда әтиләре вафат була, әмма алар әле I Бөтендөнья сугышына кадәр хәлле гаилә булып санала. 1914 елда 19 яшьлек Рихард немец армиясенә кушылып, сугышка керә. Кайнар патриотизм берничә ай эчендә тирән уйланулар белән алышына. Бу сугыш нигә кирәк соң? 1915 елда ул яралана. Аннары Берлин университетының медицина факультетында укый башлый, ләкин тиздән тагын сугышка китә. 1916 елда янә яраланып, госпитальдә ята. Түшенә II дәрәҗә Тимер тәре таксалар да, югарырак звание бирсәләр дә, ул инде сугышларга каршы зат. Тагын да сугышка кергәч, һөҗүм вакытында снаряд шартлап, кыйпылчыклар аягын яралый, күп кан югалта, авыр җәрәхәт ала, операция ясагач, аның бер аягы берничә см.га кыскарак булып кала. Сугышка кадәр спортсмен булып, Германиянең җиңел атлетика буенча җыелма командасына керүче, яхшы йөгерүче, диск ыргытучы, биеклеккә сикерүче сау-сәламәт ир-ат гарип хәлендә калу ачысын татый. Ул инде гомере буе чатанлап йөриячәк һәм баскычлардан да авырлык белән төшәчәк. Госпитальдә ятканда Рихард марксизм идеялары хакында ишетә һәм шушы хәрәкәт белән кызыксына башлый. Өстәвенә, аның нәселендәге туганнан туган бабасы Ф.А.Зорге – Ф.Энгельсның сәркатибе һәм АКШ Коммунистлар партиясен оештыручы булган икән! Рихард та яшерен эшчәнлектә актив катнаша. Төрле университетларда укый, 1919 елда, Гамбургта фәнни диссертация яклап, дәүләт һәм хокук докторы дәрәҗәсен ала. 1919 елда Германиянең коммунистлар партиясенә керә, шахтада эшли. 1922 елда Золингенда коммунистлар матбугаты белән хезмәттәшлек итә, эшчеләргә лекцияләр укый, немец милләтле Кристина белән гаилә кора. Әмма Рихард ул чакта ук «Тамырларымны тоймыйм, юлда йөрү йортым кебек булып тоела» дип тә яза. Кристина да коммунист. 1923 елда партия эшчәнлеге рөхсәт ителмәгәч, Зорге Э.Тельман элемтәчесе булып китә. 1924 елда Россиядән Германиягә немец коммунистларның IX съездына килгән совет коммунистларын урнаштыруда һәм саклык чараларын күрүдә катнаша. Шул ук елда гаилә Мәскәүгә күченә, һәм ул 1925 елда безнең илдәге партиягә кереп, Коминтерна эшли башлый. Совет гражданы. Кристина 1926 ел көзендә үк Германиягә кайтып китә. Гаилә 1932 елда гына Берлинда рәсми рәвештә таркала. Кристина исә Лондонга китә. Аның рус разведкасы бурычын үтәве хакында да язылган.

1928 елда Зорге совет хәрби разведка агенты булырга ризалык бирә. 1929 елда Англиягә, Ирландиягә бара. Аннары аны Шанхайга ук юллыйлар. Гади агент булып китсә дә, төрле дәүләт разведка вәкилләре, Кытай разведкасы, полициясе һ.б. мәш килгән Шанхайда аңа совет резидентурасын җитәкләргә туры килә, чүттән генә кулга алынмыйча кала. Аның челтәрендә 90 нан артык кытай һәм немец, алар җәмгыятьнең төрле катлавыннан, арада хәрбиләр, журналистлар да бар, ул бирелдә үз рациясе дә булмаган Коминтерн хезмәткәрләренә дә булышлык итәргә мәҗбүр. Зорге туктаусыз гәп корuda, Япониягә дә барып килә... Шанхайдагы төрле хәрәкәт җитәкчеләре белән дә таныша. Кытайдагы атаман Г.Семенов та, берсе дә аның игътибар үзәгеннән читтә калмый. Алар арасында хатын-кызлар да күп була, талантлы америка журналисты А.Смедли да Шанхайда, ул Зоргены «Асахи симбун» корреспонденты, киләчәктә Япониядә бергәләп эшләячәк Одзаки Хоцуми белән таныштыра. Одзаки, журналист булудан кала Көньяк-Маньчжурия тимер юлы тикшеренү бюросы белән хезмәттәшлектә дә булып, Квантун армиясенең тимер юллар буенча күчеше хакындагы бар мәгълүматны белеп торучы шәхес. 1932 елда Р.Зоргены Советлар Союзына чакырып алалар. Аның зирәк һәм нәтиҗәле эшчәнлегеннән барысы да канәгать! Мәскәүдә ул җәмәгате Екатерина Максимова белән ял итә. Екатерина – 1929 елда Коминтернның герман бүлеге хезмәткәре белән килгән шушы разведчик белән танышып, аның рус телен камилләштергән яртылаш немец милләтле ханым. 1933 елның августында алар гаилә кора. Соңрак ханым фашистларга булыша дигән яла буенча кулга алына һәм 1944 елда Красноярски төрмәсендә дөнья куя...

Аналитик фикер йөртүче Р.Зорге 1933 елның 6 сентябрендә Токиога килә. Моңа кадәр Франциядә совет курьеры белән очраша, АКШка барып, андагы япон илчесеннән Япония чит илләр министрлыгы өчен рекомендация хаты яздырта, аннары 3 ай Германиядә яшәп ала. Зорге 1930 елларда ук хәрби Ойген Отт белән танышкан була. Алар икесе дә сугыш кичкән ир-ат. «Көндәлек күзәтү» газетасының сәяси редакторы, доктор Зеллер Р.Зоргене Оттка «Һәрьяклап ышанычлы кеше» дип таныштыра. О.Отт 1938 елдан Германиянең Токиодагы илчесе вазыйфаларын үти башлый. Әммa Япониядәге сәясәт нечкәлекләренә тулысынча һич кенә дә төшенә алмый. Бу форсаттан генерал-майор Отт Зоргега гына таяна, менә ул аның өчен барлык диярлек яшерен язмаларны язып бирәчәк тә инде! Һәм Рихардка Берлин белән Токиодагы илчелек арасындагы аеруча яшерен элемтә кабельләре белән файдаланырга рөхсәт бирә. Дуслар бергәләп шахмат уйный, гапләшә, бергәләп ашый... 1939 елда Европада сугыш башлангач, Зоргега Германия мәгълүмати бюросы директоры тарафыннан мәгълүмати бюллетеньны редакторлау хезмәте тәкъдим ителә, моның өчен акча да түләячәкләр икән. Зоргега офис бирелә, ул инде илчелекнең пресс-атташе вазыйфаларында, бар телеграммалар аның аша үтә. Шулай итеп, Р.Зорге иң каты полиция режимы булган дәүләттә дөнья тарихында иң эффектив дип табылачак

● **Рихард Зорге.**

резидентура ядрәсен төзергә керешә. Ул бирелдә куркынычсызлык гомумән дә юк икәнен тиз арада аңлый, шуңа күрә аның эше шулкадәр тынгысыз, киеренке һәм ардыра торган булып чыга. Шик тудырмас өчен аңа 1934 елда нацистлар партиясенә, 1940 елда аларның матбугат ассоциациясенә керергә туры килә.

Әүвәл аның янында нибары 4 кеше генә була: төп агент – Одзаки Хоцуми, француз яңалыклар агентствосының Токио бүлеге мөдире булышчысы, серб милләтле журналист Гавас Бранко Вукелич, 1933 елда совет разведкасы АКШтан Япониягә юллаган рәссам Мияги Ётоку һәм радист, аңа Шанхайда чакта ук ярдәм иткән, ә бирелдә фотофирма ачачак немец Макс Клаузен. Тик Клаузен күпме генә тырышса да, бер көн төркемнең хәлен кыл өстенә куя: 1937 елда акчаны, Зоргеның инглизчә язылган отчетын таксида онытып калдыра. Берничә көннән соң югалту хакында хәтта газетага игълан да бирә. Акча да, документлар да табылмый. Бәхеткә, борчу да килми...

Тора-бара, 10 ай эчендә диярлек резидентурада 35-38 (кайбер чыганаклар буенча 18-19) кеше эшли башлый. Разведчик мәгълүматларны 160 ка якын чыганактан җыя. Болар: дингез, хәрби атташе, министрлар, генераллар, премьер-министр принц Коноэ, эре сәнәгатьчеләр... Зорге ике ел буе элемтәләр җайлый. Үзенең Кытай һәм Япония буенча искиткеч яхшы белгеч булуын раслый. Ул моңа кадәр дә Кытай икътисады, аның авыл хуҗалыгы хакында язып шөһрәт казанган журналист буларак мәгълүм була. Хәзер инде Япония сәясәте һәм икътисады белгеченең мәкаләләрен Германиядәге «Геополитика» журналы, 4-5 немец газетасы һәм Голландия газеталары көтеп тора. Токиодагы эш 1935 ел җәендә тукталып ала, разведчик Мәскәүгә кайтып килә. Ләкин август аенда ул янә Япониядә. Екатерина аңа үзенең бала көтүе хакында хәбәр итүгә, Зорге аңа бүләкләр юллый. Әмма бу мәхәббәттән туарга тиешле бала тумый һәм Рихард бу хәбәрне бик тә авыр кичерә. 1936 елның көзендә үк ул Германия белән Япония арасында Советлар Союзына каршы үзара

Рамзай...»

● Рихард Зорге Токиода.

мөнәсәбәтне өйрәнеп, илгә хәбәр юллый. Сталин моңа ышанмый. Параноик шәхес хәбәр янәшәсенә «Бу, минемчә, герман даирәләренең буташтыруы» дип язып куя. Ләкин разведчик үз фикерләрен еш кабатлый. 1936 елда япон полициясе аңа карата да игътибарын арттыра, чөнки Зорге бик активлаша. 1936 елда Зорге белән Клаузен «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнүгә тәкъдим ителә. Тик аларга орден тапшырылмый. Һәр көн саен баш миен киеренке халәттә тоткан бу ике шәхес орден хакында уйладымы икән?!

Әйе, радист М.Клаузен да (1899-1979) юк кына җайланмалардан радиостанция хәстәрли, аның детальләрен һәрчак сүтеп, теләсә кая куеп тора, радиограмма кирәк булганда гына яңадан җыя. Владивостокка шифрланган хәбәрләр юллана, аларны японнар 1937 елда ук эфирда тота, тик шифровка ясый алмый. Күпме генә эзләсәләр дә, радистның эзенә төшә алмыйлар. Зорге төркеме кулга алынгач, Клаузенда радиостанция, шифр таблицалары, шифрлы хәбәрләр табыла. Ул японнарга үзенең совет разведкасына эшләве хакында иң беренче булып таный. Йөрәгем авырта, дип йөрсә дә, ул ГДРда, Р.Зорге урамында 80 гә кадәр яшәп дөнья куя. Аны әле японнар ук хөкем иткән була, ләкин 1945 елның октябрендә америка хәрбиләре азат иткәч, аны һәм японнар тарафыннан 3 елга хөкем ителгән җәмәгате Анназы Мәскәүгә кайтаралар. Элеккеге радистка операция дә ясыйлар. Һәм сорау алгач, гаепсез дип табалар. Клаузен үз тормышын ГДРда дәвам итә. 1965 елда СССР аны – Кызыл Байрак ордены белән, җәмәгате Анназы Кызыл Йолдыз ордены белән, ә ГДРның Дәүләт куркынычсызлыгы министры Халык армиясе алдындагы хезмәтләре өчен аларны алтын медальләр белән дә бүләкли, 1964 елда Зорге хакында күп язмалар басылгач, ул гомумән һарманга әйләнә. Ә чын дөресен әйткәндә, Клаузен беренче сорау алганда ук шифрларны японнарга тапшыра, аның буенча эфир аша тотып, җыеп барылган Зоргенең берничә еллык радиограммалары шифр белән укыла. Ул японнарга иптәшләре хакында да алар бик начар иде, дип сөйли.

1937-1938 елларда Мәскәүдәге разведка җитәкчелеге алышынып кына тора. Алдагыларының күбесе юк ителә. 1937 елның икенче яртысында Р.Зоргены кире кайтарырга, ә аның резидентурасындагы 32 агентның барысын да юк итәргә дигән карар кабул итәләр. Разведидарә башлыгы вазыйфаларын үтәүче С.Гендин бу карарга каршы төшә, 1938 елда яла ягып, аны 1939 елда атып үтерәләр. Ә Зорге резидентурасы папкасына «сәяси камил түгел» – «мөгаен, дошман тарафыннан ачылган һәм аның контроле астында эшли» дигән гриф сугыла...

Зорге Япониядә 5 нче ел. 1938 елның язында ул инде Мәскәүгә кайтырга да әзер. Арып беткән разведчик Үзәккә үзенең иске яралары сызлавы, бик нык талчыгуы, гаиләсе дә булмавы хакында хәбәр юллый һәм Мәскәүгә ялга кайтаруларын, яки башка разведчикка алмаштыруларын өмет итә. Ә февральдә Зорге Гонгконгта, Отт кушуы буенча, Көньяк Кытай хакында сәяси чыгыш ясарга юнәлә һәм шунда совет элемтәчесенә 1212 фотосурәтле 38 микрофильм тапшыра, резидентура эшчәнлеге өчен акча да ала. Гонгконгка барганда О.Отт аңа хәтта дипломат кейсын да ышанып тапшыра. Соңрак Р.Зорге Советлар Союзына каршы сугышның 1938 елның язында да, җәендә дә башланмаячагын хәбәр итә. Үз эшчәнлегенең уңышын ул эрудициясе, белем югарылыгы белән дә аңлата. «Мин Кытайны тулысынча һәм Япониягә детальләштерерлек итеп нык өйрәнүем аркасында гына илчелектә шундый дәрәҗәгә ирештем. Мондый белемнәрсез илчелектәге бер хезмәткәр дә минем белән үз мәшәкатьләрен уртаклашып һәм минем фикеремне сорап тормас иде... Аларның берсе дә күпсанлы сәяхәтләрем һәм күпьеллык өйрәнүләрем нәтиҗәсендә Кытай һәм Япония турында тупланган минем мәгълүматларга ия түгел иде», – дип яза.

1938 елның май кичендә мотоциклына утырып зур тизлектә чапкан Зорге америка илчелеге янәшәсеннән узып барганда, башы белән диварга килеп бәрелә. Ул Одзакидан алган үтә мөһим хәбәрне бик тиз арада Үзәккә тапшырырга теләп, Клаузен янына чапкан икән. Илчелек полициесские йөзе канга баткан, каты яраланган журналистка табибләр чакырта. Ул, аңын югалмаска тырышып, дусты Урахның адресын әйтә. Урах бик тиз арада килеп җитә, Рихард аңа: «Клаузенга әйт, ул тиз арада килеп җитсен», – дип пышылдый. Клаузен госпитальгә килеп кергәч тә, Зорге аңа үз кесәсендәге, инглиз телендәге яшерен отчетны һәм зур суммадагы америка валютасын биреп, шундук аңын җуя. Госпитальдән чыккач та, Клаузен аның өенә барып, разведкага кагылышлы бар документларны һәм көндәлеген алып китә. Бераздан ук Германиянең яңалыклар хезмәте хезмәткәре Р.Вайзе килеп җитә, беркем дә аның әйберләренә тимәсен өчен Зоргенең кабинетын пичәт сугып яба. Әгәр ул Клаузенга кадәр алданрак килгән булса, резидентура эшчәнлеге юк ителер иде. Ханако авызы, күзләре, сул кулы бинтлар белән бәйләнгән Рихардны күргәч, аны җәлләп елый һәм 3 ай хастаханәдә яткан ир-атына шифаланырга булыша. Аның башы селкенгән, теш казнасы чатнаган, җилкәсе каерылган була. Соңрак алдагы тешләре сынган Зоргега ике аңкавы өчен дә теш протезлары ясыйлар.

О.Отт Рихардның совет разведчигы икәнен бөтенләй аңышмый. Өстәвенә, Зорге еш кына эчә, өч дистәдән артык хатын-кызның башын әйләндерә, мотоциклына утырып каядыр чабулап йөри. Ул нинди разведчик булсын ди инде... Бу хактагы уй Оттның башына да килми. Гомумән, Зоргега берничә ел уңыш юлдаш була. Әмма разведчик үз эшчәнлегендә беркайчан да хатын-кыз булышлыгына таянмый. Ул аларга разведка эшен тапшырмый һәм аларга беркайчан ышанмый да.

(Дәвамы киләсе санда).

Зилә **НИГЪМӘТУЛЛИНА** әзерләде.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

30 сентябрь (шимбә). ***Рабигүл әүвәл аеның 15 нче көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 18.35 сәгатьтә калка, 7.37 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 11.41 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Йөрәккә дәва

Җәй көне кыяр, ташкабак, карбыз, кавын, кабак орлыкларын киптереп, аерым-аерым кечкенә тукыма капчыкларда саклыйлар. Барысын да яртышар стакан алып, каһвәтарткычта тарттыралар, шуңа бал кушып болгаталар (төелгән гөлҗимеш, дуләнә, әстерхан һәм әрбет чикләвекләре дә кушсаң, дәвалау үзлекләре тагын да арта). Сай тәлинкәгә җәеп, өстен марля белән каплыйлар һәм төн буена катыралар. Аннары 1 сантиметрга 1 сантиметрлы шакмакларга бүлеп, кәгазь пакетка тутыралар. Иртән ач карынга һәм йокларга ятар алдыннан берәр шакмак суыралар.

1 октябрь (якшәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 16 нчы көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 18.41 сәгатьтә калка, 9.08 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 11.36 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Безләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Сельдерейлы лимон

Диабеттан интеккәндә, кандагы шикәр микъдарын болай киметеп була. 500 грамм сельдерей тамырын 6 лимон белән бергә иттарткычтан чыгаралар, эмальләнгән кәстрүлгә салып, капкачын ябып, аны кайнар сулы зуррак кәстрүлгә утырталар һәм сүрән утта 2 сәгать парлыйлар. Барлыкка килгән массаны пыяла банкага бушатып, суыткычта саклыйлар. Көненә 1 тапкыр, иртән ач карынга, ашарга ярты сәгать кала, 1 аш кашыгы кабалар. Әзерләнгән дару 2 ай дәваланырга җитә.

2 октябрь (дүшәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 17 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 18.54 сәгатьтә калка, 10.42 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 11.32 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Сихәтле сок

Калкансыман бизне файдалы минераллар һәм туклыклы матдәләр белән тәэмин итү өчен, 2 аш кашыгы балан, 1 чөгендер һәм 3 кишернең согын сыгалар да, көненә 1 тапкыр яртышар стакан эчәләр. Мондый сок канны да сыекландыра, аның әйләнешен дә яхшырта.

3 октябрь (сишәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 18 нче көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 19.11 сәгать-***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

мый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь.

Ютәлдән – банан

Чистартып, кисәкләргә бүленгән бананны, бераз какао порошогы сибеп, блендерда издерәләр, 1 стакан кайнаган сөт кушып, тагын күпертеп алалар. 1 чәй кашыгы бал кушсаң, файдасы тагын да күбрәк була. Көненә бер тапкыр, йокларга ятар алдыннан, кайнар килеш эчәләр. Дәва курсы – 1 атна.

27 сентябрь (чәршәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 12 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында,18.07 сәгатьтә калка, 4.13 сәгатьтә бата.2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.55 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Фейхоа сихәте

Фейхоа йодка бай, шунлыктан аны калкансыман бизләрендә проблема булган кешеләргә, шулай ук киеренке акыл эшчәнлеге таләп ителәндә куллану яхшы. Анда С витамины да цитрус җимешләрендәге кадәр. Бу җиләк кандагы зарарлы холестерин микьдарын киметә, атеросклероздан, стресстан саклый. Фейхоаны иттарткычтан чыгарып, шулкадәр үк микьдарда шикәр йә бал кушалар, суыткычта саклыйлар. Кан басымын нормага китерү өчен, көненә 3 тапкыр 1 әр чәй кашыгы кабалар.

28 сентябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигүл әүвәл аеның 13 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 18.16 сәгатьтә калка, 4.33 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.50 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бирәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Кабак тынычландыра

Төнлә йокларга ятар алдыннан 1 стакан кабак согы эчү нерв системасын тынычландыра һәм йокыны яхшырта. Кабак согы кариесны кисәтү өчен дә яхшы чаралардан санала. Халык медицинасында кабак С гепатиты белән чирләгәннән соң тулысынча сихәтләнү өчен дә кулланыла – аны, пешереп, мөмкин кадәр күбрәк ашарга кирәк.

29 сентябрь (җомга). ***Рабигүл әүвәл аеның 14 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 18.24 сәгатьтә калка, 6.05 сәгатьтә бата. 12 сәгать 58 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 11.46 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Файдалы кәнфит

1 әр стакан күрәгә һәм йөзем, 2 аш кашыгы солы ярмасы (хлопья), 3 аш кашыгы төелгән чикләвек кирәк. Күрәгә һәм йөземне яхшылап юып, бераз кипшендергәч, коры табада бераз кыздырып алынган солы ярмасы белән бергә иттарткычтан чыгаралар, шарчыклар ясап, чикләвектә әвәлиләр, суыткычка куеп торалар.

Сәйдә абыстай:

«Барча

Хөрмәтле абыстай, күп еллар дәвамында дин сабаклары укыткан мөгаллимә Сәйдә АППАКОВА, өлкән яшьтә булуга кармастан, һаман җитез, дәрт-дәрманлы. Аны өендә очрату да кыен, туктаусыз юлда, республикабыз район авыл-шәһәрләрендә очрашуларга чакырып торалар. Тоташ 3-4 сәгать буе вәгазь сөйләп, халыктан кергән сорауларга җавап биргәннән соң да ару-талуны белми. Бала тәрбияләү, гаилә тормышы, эти-әнигә мөнәсәбәт хакында сөйләштек.

– Сәйдә абыстай, сез бервакыт “вәгазьне бик бәләкәйдән башлаганмын”, дип сөйләгән идегез. Сүзебезне әниегезнең тәрбиясе хакында сөйләшүдән башлыйк әле.

– Әниебез Түбән Кама районының Җәмәкәй авылы указлы мулла кызы булып, 18 яшендә кияүгә чыкканда 4 тел белгән: татар, гарәп, төрек һәм фарсы телләрен. 3-4 яшьтә миңа гарәп хәрефен өйрәткәне истә калган: болай-тегеләй дип түгел, табагачны алып. «Карале, кызым, нинди матур борылык белән ясалган, ул бит – гарәпнең бер хәрефе. Отып кал син аны, «айн», «айн», – дип әйттерә торган иде. Әле тора күз алдымда. «Шушы табагачның өстендә бер җимеш булса, анысы калын «га», «гайн» дип әйтелә. Син дә әйтеп кара әле, ничек чыгар микән», – дип өйрәтә, йөрәккә керерлек итеп.

5 яшемнән намазга бастырды. Без – бар балаларыда намаз укый белә идек. 6 яшьтә вәгазьгә өйрәтте: ничек сулыш алырга, ничек күтәрергә, түбән төшерергә, тыңлаучылар белән ничек эшләргә. Ә ун яшемдә мин инде 30-40 лап кеше каршында кадер кичәләрендә, сугыш вакытында орчык белән җеп эрләп кич утыруларда әни өйрәткән «Йосыф-Зөләйха»ны сөйли идем. Мостафа Ногмани тәфсирендәге гарәпчәдән 2 битлек «Пәйгамбәрләр тарихы»н әнигә укып тапшыргач кына, иртәнге ашка килергә рөхсәтем булган. Алай гына да риза түгел, үзе мал карарга чыкканда, әни мине дә алып чыга. Тавыклар янына китерә дә: «Кызым, кичә мин сөйләгәннәрне сөйлә тавыкларга», – ди. Алар «ко-ко-ко» килеп минем тирәдән урый да тарала. Мин елыйм: «Әни, алар мине тыңламый!» – «Кызым, нишләп тыңламасыннар, тавышлары чыктымы?» – «Чыкты, ко-ко-ко, диләр». – «Менә, кызым, рәхмәтләре шул бит инде». Кичә Шумбатыдан килгән иде поп, аның – үз теле, безнең үз татар телебез бар, тавыкларның үз теле аларның. Шуңа син аларга: «Рәхмәтегезгә рәхмәт», – дип әйт. Алар әйтә, «моның өчен без сиңа әле йомырка да салырбыз», диләр».

Әни шулай дигәч, тагын мин боларга сөйлим. Әни төзәтәсе җирләрен төзәтә дә, соңыннан мин халыкка сөйлим икән. Тәрбия менә шулай бирелә ул. Акыл сатып түгел.

– Балага бөтен нәрсәне уен аша бирергә кушалар. Әниегез бу юлны бик яхшы белгән, димәк.

– Әни кеше баласын әни булырга, хатын булырга уен аша өйрәтергә тиеш. Курчагын алып, әйдә уйныйк, дип. Миңа 4 яшь тулганда, авыл умартасына баргач, әни: «Кызым, эш башлаганчы, башта, әйдә, сиңа йорт салыйк әле», – ди. Ботак өзде дә дүртпочмак ясады, өй булды. «Син, кызым, зур булдың, 4 яшькә барасың. Үскәч, үз гаиләң булыр. Кайнанаң-кайнатаң булыр. Алар – бик кадерле кешеләр. Тормышка чыккач, никахтан соң, кызы өчен аны үстергән анасы җавап бирми. Кайнана-кайнатасы җавап бирә. Минем белән синең кайнанаң арасында тары бөртеге кадәр генә аерма бар, ул – бик кадерле кешең. Аларга урын түрдә. Балаларың бер җирдә, үзегез бер почмакта, йокы урыны чаршау белән бүленгән булырга тиеш», – дип, мин сабыйга өйрәтә.

– Үзегезнең балаларны да шушы үрнәктә тәрбияләдегезме?

– Авыр сорау. Чөнки безнең чор кешеләре өйләнә, кияүгә чыга белмәде. Ә тормышка чыкканда, яхшы белән яманны, хәләл белән хәрәмне аера белә торган кеше сайларга кирәк. Безнең гаиләдә беребез намазда булса, икенчебез ата коммунист булды. Партком секретарена чыктым мин тормышка. Мин намаз укыганда, харап итәсең син мине, дияр иде. Тормышка чыккач, миңа намазларымны алып бару бик кыен булды. Ул минем «подполье»да булды. Гомер буе артистланып яшәдем. Кирәксә җырлыйм, аларча киенәм, шаярам-көләм, өйгә кайткач, «Аллаһым, бу бит – синең кушканнарың, гафу ит инде», – дим. Иремне намазга бастыру өчен 36 ел кирәк булды. Аллаһ кушканны аңлата барырга кирәк.

Ирем балалар табуга каршы булды, хәерче арттырмыйк, тормышыбыз начар, инженер акчасы аз, диде. Бер баланы үстерәбез, 10 яше тулды. Бервакыт апам янына хастаханәгә баргач, (ул астмалы иде), кызым әйтә: «Әни, сез ярый 3 кыз, бер-берегезгә ярдәм итәсез, кирәк чакта киңәш бирәсез. Миңа кем киңәш бирер?» – диде. Менә кем кемне тәрбияли! Үйгә калдым. Иремне тыңлап ялгыш эшләгәнмен, шуны аңладым. Иптәшемә сөйләдем. «Син бала тапсаң, мин чыгам да китәм», – ди. Шуның белән куркыта. «Ярар, – дидем, – минем талак әйтергә хакым бар». Әгәр ир кеше кыйнап торса, начар гадәтләргә өйрәтсә, талак әйтеп, хатынның үзе китәргә хакы бар. Иремә: «Мин сиңа талак әйтеп, үзем китәм алайса, башка кеше белән никахлашып, барыбер бала табам. Кызыбызга киләчәк тормышта иптәш кирәк», – дидем. Ирем уйга калды, аннан, «ярар, синеңчә булсын», ди. Шулай итеп, икенчесен таптым. Ул баладан да мәхәббәтле бала булмагандыр ирем өчен. Күтәреп кенә йөртте баланы. Менә, иргә дә аңлата белергә кирәк.

Олы кызым Луиза исемле. 11 яшемдә стеналарга корым белән язып чыкканмын, кызым туса, Луиза исеме кушам, дип. Икенче кызыма әнинең сеңлесе Лилия дип куштык. Аллага шөкер, балаларыбыз бик әйбәт. Балага нәтиҗә кайсы вакытта куябыз – син урын өстендә ятканда, кем чәй китерер, кем мине чистартыр икән, дигәндә, балаларың килеп тәрбия кылса, бу бала тәрбияле атала. Әлегә синең өстәлеңдәге ризыкны ашап киткәндә, барысы да әйбәт булалар. Аллаһның биргәненә шөкер бүгенге көнем өчен!

Олы кызым Луиза – конструктор. 9 айдан сөйләшергә өйрәнде. Мәктәп тәмамлагач, безгә әйтеп тормый гына, үзенә кирәк уку йортына барып, имтиханнар биреп кайткан. Бу кызым намазда түгел, динне бик яхшы белсә дә. 3 телдә рәхәтләнеп сөйләшә.

Икенчесенә исә яшь ярымда кухняда ашатып утырганда, радиодан Штраус вальсын бирделәр. Балам өстәлдәге ризыкларны этеп тә җибәрде, «Алып бир!» дигән ишарә ясап күрсәтте. Анысы 3 яшьтән генә сөйләшә башлады. «И Раббым, рәхмәт сиңа, бу баламны абыстай итеп тәрбияләрмен. Олысына әтисе рөхсәт бирмәде, үземчә тәрбияли алмадым. Син бу балама музыканы җибәргәнсең икән, рәхмәт сиңа, аңа ярдәм итәрмен», – дидем. Ул – музыка белгече. Без әтисе белән нотаны да белмибез, ә ул училище, консерватория, аспирантура тәмамлады. Татарстанда әлеге профессия әһеле ул бердәнбер әлегә. Русча да, татарча да сөйли, намазын да алып бара, бу кызымнан бик канәгать. Әниемә охшаган. Аңа акча да, байлык та кирәкми, булганын кешегә бирү кирәк.

– Чит кешеләргә белем бирәсез, вәгазьлисез, ә оныкларыгызга белем бирергә, аралашырга вакытыгыз җитәме?

– Мин аларны берсен – олы кызымның кызын – 6 нчы класска кадәр үзем укыттым. Аңа укытучылык бирелгән: һаман курчакларын укытты, кайсын бәргәләде, кайсын төртте, үзенчә интекте. Гарәп һәм инглиз телен өйрәнгәч, 5 ай Америкада стажировкада булды да, диплом алгач, шунда китте. Инде 13 ел шунда яши, мәктәптә укыта. Баласы үсә, бик шук,

сыйфат – нәселдән!»

мөстәкыйль. Завуч булып та эшләп алды оныгым, әмма ире каршы булды. «Әйдә, дәү әнидән сора әле, ни дияр микән?» – дигән. «Завуч ул – идарә кешесе, бүген эшлисең, иртәгә төшәсең. Укытучы бул», – дидем.

Икенче кызымның баласын карар өчен (энисе 2 айдан эшкә чыкты), бер дә җибәрәселәре килмәсә дә, мәктәптән чыктым. Бервакыт аңа фломастер алдым. Алдагы көнне әниләре коридорга обой ябыштырган иде, ике төс белән ясый торган вакыт бу. Мин ашарга пешергәндә, коридорга чыккан да, дөньяны ничек күрә: урамны – урам итеп, йортны йорт итеп ясаган, мине дә, әниләрен дә ясаган, 1 см буш урын калмаган. Мине чакырды: «Дәү әни, матурмы? Монысы син», – ди. Әтиләре кайтырга тиеш эштән. Фатирдан чыгып каршы алдым. Лифттан чыгуларына: «Балага сүз әйтә күрмәгез», – дим. «Әни, нишләде? Берәр нәрсә ваттымы?» – «Сүз әйтә күрмәгез! Миңа сүз бирегез, кертмим өйгә!»

Кергәч, бераз басып тордылар тып-тын. Аннан, әтисе: «Ай-һай әйбәт булган, мин болай эшли алмыйм», – ди. Кызым бер сүз әйтә алмады, тынсыз калды. Бала сөйли, кайсы нәрсә икәнен. Әйттем кызым белән киявемә: «Балага уйлау бирелгән. Дәү әтисе кебек», – дидем. Дәү әтисе – 1 нче разряд конструктор. Үскәч, бала КАИга керде. Хәзер Берлинда магистратураны бетерергә тиеш. Диплом яза. «Мин – ир кеше, ата-ана өстендә ятарга тиеш түгел», – дип, КАИны эшләп бетерде. Көндез укырга барды, кичен эшләде. Балалар – Аллаһы Тәгалә хәзинәсе.

Кечкенәдән аңлатам мин моңа: «Ир кеше хатын-кызны хөрмәтләргә тиешле. Картларга урын бирергә тиешле. Транспортта ир кеше басып торырга тиеш», – дип өйрәтәм. Коръән ашларына барганда, бик бәләкәй килеш, үзем белән ала идем. Бервакыт транспортка кергәч, урын бар – утырмый, тотынды. «Егылыр», – дип, утырырга кушалар моңа. «Я муччина», – ди. Дөрес итеп әйтә белмәсә дә, аңлата. Көлештеләр инде. Төшәр вакыт җиткәч, алдан төшеп, кул бирә миңа, янәсе, мине кайгырта. Менә шулай өйрәткәч, шул көенә бара, Аллаһның биргәненә мең шөкер.

– Кызларыгызның да, оныкларыгызның да нинди һөнәргә тартылуын тоемлый алдым, дидегез. Моны ничек эшләргә?

– Бала тугач, без, тоемлау белән, Аллаһы Тәгалә аңа нинди һөнәр биргәнен белергә тиешбез. Берәүне – урам себерүче, берәүне – галим, берәүне тегүче иткән. Мисал китерәм: мин төзелеш институты ректоры, ди. Әлбәттә, баламны мин шунда укырга кертәм. Ә балага табиблыкны биргән, ди. Бу бала үз гомерендә итек киеп, прораб булып эшләми. Һаман шул Аллаһы Тәгалә биргәнгә тартыла. Шуңа күрә ата-ана баласына кайсы юнәлеш бирелгән 3 яшькә кадәр тоярга тиеш, уенчык белән. Баланың уенчыгы күп булмасын. Күп булса, бала фикер йөртергә өйрәнми, «әзергә бәзәр»леккә генә гадәтләнә. 3-4 кенә уенчык булганда, ана бер көнне бер уенчык бирә, күзәтә: уйныймы бала моның белән, юкмы? Уйнамый. Икенче көнне икенчесен бирә, уйнамый. Өченче көнне өченчесен бирә – уйный. Фикер йөртә ана: «Ә-ә-ә, балага шушы бирелгән икән», – дип. Киләчәктә уку йорты сайлаганда, эти-әни фикерен әйтә: «Балам, монда керсәң, ничек булыр микән?» Әгәр бала тәрбия алып үскән булса, эти-әнине тыңлый.

– Хәзер әтиле килеш әтисез үсүче балалар бик күп. Ялгыз әниләргә ир бала тәрбияләүдә киңәшләрегезне бирегез әле.

– Бала бер кулда тәрбияләнергә тиеш. Баланы әтисе янына китереп йөртсәң, әни тәрбияли бер төрле, эти – икенче төрле. Бала кая аварга белми. Ата белән көрештермәү хәерле. Дөрес ата булса, аерылмый ул. Матди яктан ул булышырга тиеш. Аерылса да, хатынны, баланы тәрбияләргә тиеш. Балага аңлатабыз: «Син үсәрсең, укырсың, өйләнерсең. Хатының-балаларың булыр. Син илгә эшли торган кеше булырсың. Борынгы бабаларыбыз ничек тәрбияләгән – мин сине шулай тәрбияләргә тырышырмын. Дин кагыйдәсен дә кертермен. Менә уч төпләренең берсендә 81, икенчесендә 18 – Аллаһның 99 исеме. Шуңа карап дога кылабыз, әйдә, «әппәр»еңне ит, дип, кечкенәдән баланы битне сыпырырга өйрәтәбез. Баланы кечкенәдән суга төкермәскә, иснәгәндә авызны капларга, һ.б. әдәп кагыйдәләренә өйрәтәбез.

«Менә боларны, улым, сиңа эти кеше өйрәтергә тиеш иде. Безгә Аллаһы Тәгалә шулай биргән, мин сине әтиең өчен дә, үзем өчен дә өйрәтәм», – дип, яшүсмерлек чорында – 12 яшендә – тартынмый-оялмыйча, интим тормыш турында өйрәтә башларга кирәк. Бездә оят санала бу. Дини гаиләдә бөтенләй өйрәтү юк! Элек вакытта утырмаларда аны аңлата торган булганнар. Ирләргә ирләр өйрәткән: ничек ир булырга, ничек өйләнергә, кияү керү тәртибен... Кияү керү көненнән башлана ирләрне хөрмәт итү. Әгәр ул хатын-кызга хөрмәтле булмаса, диндә атап язылган, хатынының сикереп менмә, көйлә, дигән. Ул ике якның теләге буенча булырга тиеш, куркытма, дип аңлата. Сперматозоидларга кадәр язылган «Коръән»дә, «мәни» диелгән.

Ир бала белергә тиешне өйрәтә ана: «Әтиебез шушыны эшли иде, бабай болай эшли иде, отып ал әле», – дип. Кайнатам әйтә иде: «Хатын-кыз – ул роза чәчәге, армаска тиеш, аңа кайнар су сибәсең икән, мәхәббәт бетә». 9-10 яшендә бала мәхәббәтне бик яхшы белә. «Син мине ничек яратасың, хөрмәтлисең, хатыныңа да шундый хөрмәт кирәген башыңа салып куй. Син хатыныңны тәрбия кылырга тиешле. Яхшы тәрбия алган егет, дип әйтерлек булсын. Минем исемемә тап төшә күрмәсен. Мин синнән бик канәгать. Дөрес итеп дәресеңне әзерлисең. Булышмыйм, үзең тырышасың. Идәнемне дә юасың, себерәсең, башкасын да эшлисең. Үз чалбарыңны үтүклисең, рәхмәт, балам!» – дип баланы сыпырырга кирәк.

Аны олы кеше итеп сөйләшә белергә кирәк. Менә шуннан соң аңлатырга кирәк: «Мин синең белән олы кеше кебек сөйләшәм. Өйләнешү бала вакытта да, 15-16 яшьтә дә бирелмәгән. Никах дигән берлек бар. Аны Аллаһы Тәгалә егет белән кызга, ир белән хатынга бүләк итеп бирә. Син бер йә ике һөнәр алганнан соң никахлансаң, уңышлы була тормыш. 17-18 яшеңдә өйләнеп куйсаң – ни акыллы, ни юләр, һөнәрегез дә юк икегезнең дә, укырга да кирәк, балагыз да булса, син надан каласың, дворник кына буласың. Шуңа, балам, һөнәр алырга кирәк. Син, балам, уйлап йөр, нинди һөнәр ошый сиңа?» – шушылай сөйләшәсең. «Дусларыңны тикшер. Начарга өйрәтәме, яхшыгамы. Әгәр сыра эчәргә, тартырга өйрәтә икән, матур итеп кенә, син ачуланма, «минем әнием ялгыз, мин кайтыйм» дип, кит бу баладан.

Аллаһы Тәгалә бөтен кешегә дә көнчелек бирә. Яхшы көнчелек бар, начар көнчелек. Әле якын туганың да көнләшәчәк, аны да белеп тор. Шуңа барын да дустыңа сөйләп бетермә. Пәйгамбәр хәдисендә болай дигән: «Дустыңны да артык дус итеп яратма, килер бер көн – ул сиңа дошман булыр, уртача бул», – дип өйрәтәсең.

Бала начар юлга кереп китә икән, монда эти-әни гаепле, нәсел гаепле. Моңа тәрбия кермәгәннән. Ялгыз тәрбияләүдән дә курыкмаска кирәк. Аллаһы Тәгаләгә ышанырга, дин һәм фәнне параллель алып барырга кирәк.

– Дөрес ата булса, аерылмый ул, дидегез. Гаиләдә ныклыгы өчен ир дә, хатын да тигез җаваплы бит.

– Тормышка чыкканда да, ир баламы, кыз баламы – ата-ана сүзенә колак салырга кирәк. Ата-ана беркайчан да баласына начар булсын дип теләми. Аның башыннан инде яхшы-яманы үткән, үзе ясаган ялгышларны баласы җибәрмәсен дип тырыша, өйрәтә, аңлата. Ә бала 3 яшендә тәрбия алмаган булса, 20 яшендә «мы сами знаем» була инде.

Никахлары бозылган яшь гаиләләргә барам. «Кызым, никахың нидән бозылды?» – дим. Иңсәсен сикертә – белми! Димәк, моңа әнисе бернәрсә дә өйрәтмәгән. Аерылганнардан кайберләре әйтә: «Әй абыстай, белмәдем, яшь чак, юләр чак булган. Бер ачуланышкач, кайттым да киттем. Беркем өйрәтмәде. Өч кияүгә чыктым, берсе дә беренче иремә тормый. Гомер буе шуны сагынып яшәдем», – ди. Менә шуңа балага 3 яшенә кадәр аңлатырга кирәк: «Балам, син тормышка чыгарсың, ирең булыр. Кайнатаң-кайнанаң булыр. Алар – бик хөрмәтле кешеләр. Балам, менә болай итеп бәреп кара әле (учларын бер-берсенә суга), тавыш чыга. Ә син юл куй, менә болай!» (Кара-каршы килгән учлар бер-берсенә бәрелми генә китәләр.)

Элек әбиләребез әйтә иде, «кызым, күп сөйләшмә, яхшы сәгать бар, начар сәгать бар», диләр иде. Гәрчә ирегез белән сугышып торсагыз да, «ирем яратмый», дип әйтмәгез, дип. Аллаһы Тәгалә, бу бәндәгә ире яратмавы кирәк икән, дияр ди. Бәхетсез начар сәгать шуны аңлата икән. Шөкер, мине ирем бик ярата, дип әйтергә кирәк икән. Без канәгать була белмибез.

Ир ачуланганда, хатын-кыз тыңлап тора. Хатын-кыз дулаганда, ир кеше: «Әй яратам да инде шушы ачуланган вакытыңны, бигрәк матур буласың, төкерекләрең чәчелеп китә», – дип яратып көлсә, хатыны: «Синең шул булыр инде», – дип, тынычлана. Чәйнекне куярга да өстәл янына чакырырга кирәк.

Һәр кешене – ирләрне дә, хатын-кызларны да – мактарга кирәк. Ире хатынны мактаса, «Рәхмәт, ашың бигрәк тәмле булды», – дип, гәрчә ул тозлы йә әчегән булса да, хатыны йөрәгендә дә очып йөри башлый: ире мактады! 24 сәгать эшли, армый! Әгәр инде ире: «Син нәрсә пешерә беләсең соң, ашың тозлы булган!» – дип тотынса, хатын-кызга кислота сипкән кебек була. Ул иренә хөрмәтен югалта.

Кеше бер тапкыр ялгыш ясамый, хата җибәрми торып, яхшысын эшли алмый. Үзем дә җибәрдем ул хаталарны. Хәзер әйтәбез, әй шушы хәзерге акылым кияүгә чыкканда булган булса, дибез. Акыл дигәннән, шушы яшемә җитеп, яшьләрдән акыл җыйган чакларым да була. Кайбер кешегә «акыл» дигәнне бик иртә салган ул.

Бервакыт ашка баргач, бер хатын утыра. Үзе ябык, үзе сары. «И, авырыйдыр инде, Раббым, бу балага сәламәтлек бир», – дип дога кылдым эчемнән. Хуҗа хатыны килеп утырды да сөйли, күрше килене бу, ди. Бәхетсез булды, ди. Хуҗа хатын чыгып китте, бу яшь хатын үзе сөйләде: «Минем ирем кыйный торган булып чыкты. 5 ел торабыз, 5 елга 1 балабыз булды, 2 мәртәбә генә өйдә кундым. Мин өйгә керсәм, кыйный башлый», – ди. «Ник торасың соң ул ир белән?» – дим. Уйлап торыш юк, үзем – абыстай! «И абыстай, аның эти-әнисе – бик яхшы кешеләр. Алар хөрмәтенә яшим. Әгәр мин аны ташлап китсәм, ул төрмәгә эләгәчәк, ә ата-ана өчен бала газиз бит. Ничек итеп ташлап китим мин ул карт белән карчыкны? Миңа Аллаһы Тәгалә савап бирсен», – ди. Кочаклаштык та, икебез дә елыйбыз. Менә ул тәрбия, кем кемне тәрбияли! Менә нинди гаиләләр дә бар. Шуңа да безгә очрашырга, бер-берләребезне вәгазьләргә кирәк. Шуңа динне дә, фәнне дә өйрәтергә кирәк. Фән дөньяда яшәү өчен кирәк. Фәнне белмәсәң, динне белеп, селкенеп кенә утырыр өчен өйрәтмәгән Аллаһы Тәгалә. Кара урман эчендә кычыткан арасыннан сукмак сала ул дин. Аннан үзеннән-үзе кешенең, «миңа шул кирәк икән, өйрәним әле, Аллаһы Тәгалә шулай кушкан» дип, китап артыннан китап укырга омтылышы була.

– Үзегезнең кайнана-кайнатагыз сезне ничек кабул иткән иде?

– Ирем Ринат артымнан йөри башлагач, «Әни, артымнан шушы кеше йөри, керәшен түгелме икән алар?» – дигән идем, «Юк, кызым, юктыр», – тынычландырды әнием. Алар 7 буын Аппаковлар булганнар. Ап-ак аларның тәннәре, чәчләре – бөтенесе дә. Ә ни өчен бер генә «п» – Апаковка калдырганнар: дәү әтиләрен төрмәгә утырткач, егетләр фамилияләрендәге бер «п»ны төшереп, икенче паспорт алалар һәм «Без – башка нәсел», – дип исән калалар. Менә нинди баш йөрткәннәр! Монысын кайнатам сөйләде.

Кайнатам белән кайнанам әйбәт кешеләр булды. Алар 7 буынга кадәр беренче гильдия сәүдәгәрләр булган. Һиндстан, Кытайга йөргәннәр. Алар нәселендә бер артист, бер имам юк – дөньяви кешеләр. Олы кызым нәкъ әтисе холкында. Дүртенче буыннан килә нәселдәнлек. Шуңа күрә, тормышка чыкканда, нәселне карарга кирәк. Әтиәнинең сүзенә колак салырга кирәк – алар тормыш иткән, алар нәселне белә. Гарип бала бар икән нәселдә – гарип бала туарга мөмкин яшьләрнең, исерек бар икән нәселдә – исерек булуы, мулла бар икән нәселдә – шуннан сиңа мөфти булып туа ул. Шундый имамнарыбыз да бар – эти-әниләре исерек булган да, менә дигән галим килеп чыккан – бу да дүртенче буыннан.

Гөлназ ХӨҖҖӘТОВА.
intertat.tatar.

Салават КАМАЛЕТДИНОВ фотосы.

Сәламләшү нечкәлекләре

Дөньяда иң киң таралган сәламләшү ысулы – кул кысышу. Ул бик борынгыдан килә. Гасырлар буена исәнләшү этикеты эшләнгән. Мәсәлән, төрле яшьтәге кешеләр сәламләшкәндә, өлкәнрәге кулын беренче булып суза. Яшьрәге исә, икеләнеп тормыйча, шул мизгелдә үк аның кулын кысарга тиеш. Утырган килеш кул бирергә дә, перчатка кигән килеш исәнләшергә дә ярамый. Кул кысышу шактый нык булып, 2-3 секундтан артмаска тиеш. Россиядә бусага аша кул бирешмиләр. Сәламләшүнең иң сәер традицияләре Африка кыйтгасында очрый. Мәсәлән, Кениядәге акамба кабиләсе вәкилләре очрашканда бер-берсенә төкерә. Мозамбикның Замбезия провинциясендә, чүгәләп, кул чабалар. Конгода бер-берсенә кулларын сузалар һәм аларга өрәләр. Сахара чүле чигендәге кабиләләрдә исә сәламләшү ритуалы 100 метр ара калгач ук башлана. Аборигеннар башта баскан җирендә катып кала, аннары сикерә, чүгәли, бии. Мисырда учны маңгайга куеп исәнләшәләр. Гарәпләр күкрәк турысында кулларын чалыштыра. Лапландиядә борыннарын тидереп сәламләшәләр. Латин Америкасында кочаклашалар. Японнар һәм кытайлар баш иеп сәламләшә. Тибетта башта уң кул белән баш киемен салалар, аннары сул кулны колак артына куеп, телләрен чыгаралар. Төньяк Африкада, иелеп, кулны маңгайга, иренгә һәм күкрәккә тидерәләр, бу: "Мин синең турында уйлыйм, синең турында сөйлим, сине хөрмәт итәм", – дигәнне аңлата. Һиндстанда, кулларны кушырып, күкрәк турысына куялар. Самоада бер-берсен исниләр. Франциядә исә символик үбешеп – башта 2 тапкыр уң яктагы, аннары 2 тапкыр сул яктагы яңакны тидерешеп сәламләшәләр.

("Мир новостей").

Су асты пиратлары

Индонезия, Сингапур һәм Малайзия ярларын юа торган диңгез суларында дистәләрчә шхуна йөзә, янәсе, балык тоталар. Чынлыкта исә болар – баткан корабларны талау белән шөгыльләнүче су асты пиратлары. Алар тирәнлеге 100 метрдан артмаган сай суда гына "эшли" ала. Халыкара хокук Икенче бөтендөнья сугышы вакытында батырылган корабларга тиюдән тыя, әмма пират водолазлар әлеге тыюны санга сукмый. Алар инде Британия, Америка, Япония, Нидерланд, Австралиянеке булган дистәләрчә корабны турап өскә чыгарган. Водолазлар су астында корабларның корпусын кисә, аннары металл кисәкләрен йөзмә краннар белән баржаларга тутыра. Пиратлар бу төбәктә атом сынавы үткәрелгәнче җитештерелгән металлга кызыга, батырылган кораб корпуслары – нәкъ менә радиация тимәгән металлның соңгы чыганагы. Әлеге корыч бик югары бәяләнә һәм Гейгер санагычлары, космик сенсорлар, медицина җиһазлары кебек бик төгәл үлчәү таләп итә торган аппаратура җитештерүдә кулланыла. Урта тоннажлы бер хәрби корабтан 1 миллион долларлык корыч сатып була. Җиз торбаның бер тоннасы 2 мең долларга, бакыр чыбыкның тоннасы кимендә 5 мең долларга сатыла.

("Die Presse").

Азат бул!

Без күбесенчә "Исәнмесез!", "Хәлләр ничек?" дип исәнләшәбез. Кытайда күрешкәндә: "Син бүген иртән дөге ашадыңмы?" – дип сорыйлар. Японнар исә: "Көн туды", – дип сәлам бирә. Африкадагы Ботсвана гел корылыктан интегә, шунлыктан анда: "Яңгыр яусын!" – дип сәламләшәләр. Зулуслар исә бер-берсенә: "Мин сине күрәм", – ди. Немец "Барысы да тәртиптәме?", француз "Хәлләр ничек?", италияле "Ничек басып торасың?" дип күрешә. Малайзиядә: "Кая барасың?" – дип сәламләүгә һичшиксез: "Йөреп киләм әле", – дияргә кирәк. Памирда һәр очраган кешегә: "Ару-талуны белмә!" – диләр. Төньяк Америка һиндиләре: "Син – икенче мин ул", – дип шаккатыра. Гренландиядә: "Нинди матур көн!", Иранда: "Шаян бул", – дип сәламләшәләр. Грузиннар: "Гамарджоба!" ("Хаклы бул!" яки "Җиңәргә язсын!"), вайнахлар: "Азат бул!", Африкадагы басуто кабиләсе: "Сәлам сиңа, ерткыч!", маорилар: "Бу иртә (көн) өчен рәхмәт!", Таиландта исә: "Вааау!" дип күрешәләр.

("Bloomberg").



Австралиядә рус Тарзаны

Михаил Фоменко исеме россиялеләрнең күбесенә таныш та түгел. Ә менә Австралиядә аның турында легендалар йөри. Михаил 1930 елда Грузиядә туган. Әнисе – грузин кенәзе кызы Елизавета Мачабели. 30 нчы еллар азагында гаилә СССРдан кача һәм, башта Кытайда, аннары Японииядә яшәгәннән соң, Яшел кыйтгага барып төпләнә. Михаил спортчы була, аны 1956 елда Мельбурнда узачак Олимпия уеннарында катнашырга әзерлиләр. Әмма егет кешеләр арасында үзен уңайсыз тоя, табигатьне артыграк күрә. Көннәрдән бер көнне исә Австралиянең төньягына сәяхәткә дип китә дә, югала. Квинсленд урманнарында яши, крокодилны һәм кабан дуңгызын беренче коралсыз үтерә торган була. Шалаш та төземи, агач башында йоклый. Үзенә каноэ әмәлли һәм ялгызы гына диңгездә йөзә. 1964 елда Михаилны атлы полицейский очрата һәм кулга ала. Сукбайлыкта гаепләп, башта 6 айга төрмәгә ябалар, аннары психиатрия клиникасында көчле дарулар белән "дәвалыйлар". 1969 елда ирекккә чыгарылгач, Фоменко шундук кабат яраткан джунглиена китә. Җирле халык аны "рус Тарзаны" дип йөртә. Михаил ике тапкыр хәтта репортерлар белән дә сөйләшә. Ун елдан соң инде "ак кыргый" турында бөтен кыйтга белә, аның хакында китаплар, җырлар языла. Ул әнисен дә онытмый – исән икәнен белгертер өчен, аңа әледән-әле үзе үтергән кабан дуңгызларының казык тешләрен җибәреп тора. Беркайчан да сәламәтлегеннән зарланмый, бик көчле була. 2012 елда 82 яшьлек дәрвишне картлар йортына урнаштыралар, 6 елдан соң ул шунда бакыйлыкка күчә.

("Вокруг света").

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

2 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем...» 12+
12.00, 22.10 «УКЫТУЧЫЛАР». 16+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Акыл батл» һәм «Учимся вместе».
17.30 «Ватандашлар». 16+
18.00, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
19.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
23.00 «СЕМЕЙНЫЙ ДОМ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Родная земля». 12+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Саҗидә Сөләйманова турында телеочерк. 16+
15.20 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 «Заман көзгесе». 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 «Калеб». 6+
21.55 «Туган авылым». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ДРУЖИНА». 16+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ВДОВА». 16+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Чужая память. Дежавю». 12+
16.30 «ВЕРОНИКА. БЕГЛЯНКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ОТЛИЧНИЦА». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «СПРОСИ МАРТУ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДОКТОР КРАСНОВ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного.
7.35 Черные дыры. Белые пятна.
8.15 «Жизнь и судьба».
8.40 «СВЕРСТНИЦЫ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «После свадьбы».
11.45 «Добро пожаловать, или Посторонним вход воспрещён». Без сюрпризов не можете?!»
12.45 Новости. Подробно. АРТ.
13.05 Большие и маленькие.
14.55, 23.40 «Три минуты тишины».
15.00 «Среди тверских пирамид».
15.40 «Забытое ремесло».
15.55 «Агора».
17.20 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Лауреаты.
18.35 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Дневники конкурса «Учитель года России».
21.30 «Сати. Нескучная классика...»
22.15 «КОНЕЦ «ЧЁРНЫХ РЫЦАРЕЙ».
23.45 «Магистр игры». «Реквием по Боголюбу. Кто отравил Моцарта?»

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.15, 0.00 «ДАЙВЕР». 16+

Сишәмбе

3 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «УКЫТУЧЫЛАР». 16+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Төймә» һәм «Учимся вместе».
17.30 «Заман көзгесе». 6+
18.00 «Таяну ноктасы». 16+
19.30 Хоккей. «Ак Барс» - «Северсталь». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.00 «СЕМЕЙНЫЙ ДОМ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате». 16+
15.20 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ОТЛИЧНИЦА». 12+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ВДОВА». 16+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Романовы. Судьба русского Крыма». 12+
16.30 «ВЕРОНИКА. БЕГЛЯНКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «СПРОСИ МАРТУ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДОКТОР КРАСНОВ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Забытое ремесло».
7.50 «Почерк эпохи». «Майя Плисецкая. Великая Майя!»
8.15 «Жизнь и судьба».
8.35 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ».
9.45 Оттепель. В добрый час. Евгения Уралова.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Рассказы цыгана».
12.10 Цвет времени. Владимир Татлин.
12.45 Новости. Подробно. Книги.
13.00 Оттепель. В добрый час. Олег Даль. Рассказывает Юрий Поляк.
13.20 «Крым. Мыс Плака».
13.50 «КОНЕЦ «ЧЕРНЫХ РЫЦАРЕЙ».
15.15, 23.35 «Три минуты тишины».
15.20 «Аксаковы. Семейные хроники».
16.05 Юбилей Терезы Дуровой. Линия жизни.
17.15 «Передвижники. Михаил Нестеров».
17.40 Оттепель. В добрый час. Татьяна Доронина. Рассказывает Анастасия Дьячук.
18.00 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Лауреаты.
19.10 Оттепель. В добрый час. Олег Ефремов. Рассказывает Дмитрий Лысенков.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.30 «Белая студия».
22.15 «СУДЬБА ИГРАЕТ ЧЕЛОВЕКОМ...»
23.40 «Рассекреченная история».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.15, 0.00 «ДАЙВЕР». 16+

Чәршәмбе

4 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 16+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «УКЫТУЧЫЛАР». 16+
13.00, 0.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Учимся вместе».
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Гаилә учагы». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Соотечественники». 16+
23.00 «СЕМЕЙНЫЙ ДОМ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10, 8.30, 18.20, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Рәмис Аймәт турында телеочерк. 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05, 21.25 «Кунак БИТ Шоу». 16+
15.20 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00, 0.15 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ОТЛИЧНИЦА». 12+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ВДОВА». 16+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Романовы. Судьба русского Крыма». 12+
16.30 «ВЕРОНИКА. БЕГЛЯНКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «СПРОСИ МАРТУ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДОКТОР КРАСНОВ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Забытое ремесло».
7.50 «Почерк эпохи». «Михаил Зощенко. Ключи счастья».
8.15 «Жизнь и судьба».
8.35 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ».
9.40 Оттепель. В добрый час. Алексей Баталов. Рассказывает Максим Севриновский.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Космос: дорога к новому дому?»
12.10 «Первые в мире».
12.45 Новости. Подробно. Кино.
13.00 Оттепель. В добрый час. Татьяна Лаврова. Рассказывает Дарья Урсуляк.
13.20 Искусственный отбор.
14.05 «СУДЬБА ИГРАЕТ ЧЕЛОВЕКОМ...»
15.20, 23.35 «Три минуты тишины».
15.25 «Аксаковы. Семейные хроники».
16.05 «Белая студия».
17.15 «Библейский сюжет».
17.40 Оттепель. В добрый час. Владимир Ивашов. Рассказывает Павел Чинарёв.
17.55 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Лауреаты.
19.10 Оттепель. В добрый час. Геннадий Шпаликов.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Дневники конкурса «Учитель года России».
21.30 Памяти Глеба Панфилова. Острова.
22.15 «ПЕЩЕРНЫЕ ЛЮДИ».
23.40 «Рассекреченная история».

«НТВ»

4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.15, 0.00 «ДАЙВЕР». 16+
0.50 «МЕДИАТОР». 16+

Пәнҗешәмбе

5 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «УКЫТУЧЫЛАР». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Память сердца». 16+
14.15 «Классный час». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Шома бас», «Алты хәреф» һәм «Учимся вместе».
17.30 «Точка опоры». 16+
19.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Авангард». 6+ По окончании - «Погружение на 100». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.00 «СЕМЕЙНЫЙ ДОМ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Гаилә учагы». 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.20 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.20 «Кунак БИТ Шоу». 16+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00, 0.15 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 12+
21.25 «Йөрәктән - йөрәккә». Марсель Галиев турында телеочерк. 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ОТЛИЧНИЦА». 12+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30, 18.30 «Подружки». 16+
13.00, 23.50 «ВДОВА». 16+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Романовы. Судьба русского Крыма». 12+
16.30 «ВЕРОНИКА. БЕГЛЯНКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00, 18.30 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «СПРОСИ МАРТУ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».

9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Наши». 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ДОКТОР КРАСНОВ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Забытое ремесло».
7.50 «Почерк эпохи». «Осип Мандельштам. Будет и мой черед...»
8.15 «Жизнь и судьба».
8.35 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ».
9.40 Оттепель. В добрый час. Владимир Земляникин. Рассказывает Севастьян Смышников.
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «В гостях у Николая Озерова».
12.45 Новости. Подробно. Театр.
13.00 Оттепель. В добрый час. Татьяна Самойлова. Рассказывает Полина Рафеева.
13.20 «Игра в бисер» «Антон Макаренко. «Педагогическая поэма».
14.05 «ПЕЩЕРНЫЕ ЛЮДИ».
15.25, 23.35 «Три минуты тишины».
15.30 «Аксаковы. Семейные хроники».
16.15 «2 Верник 2».
17.15 Пряничный домик. «Сибирский туесок».
17.40 Оттепель. В добрый час. Никита Михалков. Рассказывает Юрий Цокуров.
17.55 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Лауреаты.
19.10 Оттепель. В добрый час. Евгений Урбанский. Рассказывает Василий Симонов.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Татьяна Толстая. «Истребление персиян».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 80 лет со дня рождения Инны Чуриковой. Острова.
21.30 «Энигма. Олег Виноградов».
22.15 «ГРАВЮРА НА ДЕРЕВЕ».
23.40 «Рассекреченная история».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.15, 0.00 «ДАЙВЕР». 16+

Җомга

6 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.00 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Семь дней+». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!», «Алты хәреф» һәм «Учимся вместе».
17.30 «Кто мы татары?» 12+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 12+
21.00 «Юлчы». 16+
22.10 «БАРЫШНЯ-КРЕСТЬЯНКА».

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 18.20, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Таяну ноктасы». 16+
12.05 «Кунакка... Рәссамга». Искәндәр Рәфыйков турында телеочерк. 16+
15.20 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 16+
21.25 «Татар әдәбияты дәресләре». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «СВИДЕТЕЛИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ОТЛИЧНИЦА». 12+
11.30 «КАРАМЕЛЬ». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.00 «ЗИТА И ГИТА». 16+
15.55 «Заповедники РФ». 12+
16.30 «ВЕРОНИКА. БЕГЛЯНКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ЛЮБОВЬ НАПРОКАТ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 12.15, 17.00 Информационный канал. 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Голос. Уже не дети». 12+
23.50 «Дэймон Албарн. Современная британская сказка». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым». 12+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+
23.55 «Истории Большой Страны». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 15.55 «Забытое ремесло».
7.50 «Почерк эпохи». «Сергей Рахманинов. Я русский композитор».
8.15 «Жизнь и судьба».
8.35 «ЮРКИНЫ РАССВЕТЫ».
9.40 Оттепель. В добрый час. Инна Гулая. Рассказывает Мариэтта Цигаль-Полищук.
10.20 «УЧИТЕЛЬ».
12.00 Открытая книга. Татьяна Толстая. «Истребление персиян».
12.45 Оттепель. В добрый час. Андрей Миронов. Рассказывает Михаил Тройник.
13.05 Власть факта. «Франко-русский союз».
13.50 «ГРАВЮРА НА ДЕРЕВЕ».
15.10, 23.50 «Три минуты тишины».
15.15 «Энигма. Олег Виноградов».
16.15 «Реалист».
17.15 Письма из провинции.
17.40 Оттепель. В добрый час. Станислав Любшин. Рассказывает Максим Керин.
17.55 XVII Международный конкурс имени П.И. Чайковского. Лауреаты.
19.10 Оттепель. В добрый час. Олег Табаков. Рассказывает Владислав Миллер.
19.45 «Союз - Аполлон».
20.40 «ВАССА».
22.50 «2 Верник 2».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «ПЁС». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ПЕРВЫЙ ОТДЕЛ». 16+
22.15 «ДАЙВЕР». 16+

Шимбә

7 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Siңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30, 0.45 «Музыкальный майдан». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Болгар радиосы» бәйрәм концерты. 16+
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит-шоу». 16+
23.00 «КЛАДОИСКАТЕЛИ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Нуретдин Нәҗмиев турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Siңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган көндә җырлыйк бергә...» Рәмис Әймәтнең иҗат кичәсе. 16+
17.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Сагынам, дуслар». Айгөл Сагынбаева концерты. 16+
23.05 Спектакль «Гайфи бабай, өйлән давай!» 16+

«ЭФИР»
5.00 «Заповедники РФ». 12+
6.00 «Лекарство от глупости». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30 «Первые в мире». 12+
8.45 «ВЕТЕР В ЛИЦО». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЛЮБОВЬ ДЛЯ БЕДНЫХ». 12+
14.45 «Ночной дожор». 12+
15.45 «ЦВЕТЫ ЗЛА». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЖАНДАРМ ИЗ СЕН-ТРОПЕ». 16+
22.40 «ТОРН: ПУГАЯ ВОРОНА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Наше всё». 12+
11.05 «ПроУют».
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «ТОТ САМЫЙ МЮНХГАУЗЕН».
16.00 Валерия, Лев Лещенко, Елена Ваенга в праздничном концерте ко Дню учителя. 12+
18.20 «Михаил Задорнов. вся жизнь». 16+
19.15 «Эксклюзив». 16+
20.05 «Кто хочет стать миллионером?»
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+
23.50 «ТРИ БИЛБОРДА НА ГРАНИЦЕ ЭББИНГА, МИССУРИ». 18+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.50 «В кругу друзей».
12.50 «Доктор Мясников». 12+
14.50 «Юморина». 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ДЕВОЧКИ НЕ ПЛАЧУТ». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 «ВАССА».
9.15 «Мы - грамотеи!»
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «ЖИЗНЬ ПРОШЛА МИМО».
11.55 Земля людей. «Гинухцы. Там, где летают орлы».
12.25 Черные дыры. Белые пятна.
13.10 «Союз - Аполлон».
14.00, 23.00 «Три минуты тишины».
14.05 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.20 «Нобелевские победы российской науки».
16.05 Большие и маленькие.
18.10 «Энциклопедия загадок». Документальный сериал.».
18.40 «Доминанты».
19.45 «КОРОВА».
22.00 «Агора».
23.05 «НЕ ВРЕМЯ ЛЮБИТЬ».

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.10 «Попутчик». 16+
14.20 «Игры разумов».
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 18+

Якшәмбе

8 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Син минем тиң ярым». Зинира һәм Ризат Рамазановлар. 16+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 Мультфильмы.
9.00 «Яшьләр тукталышы».
9.30 «Дуслык илендә». 12+
10.00 Хоккей. «Адмирал» - «Ак Барс». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Татар халык җырлары».
14.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Каравай». 6+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 16+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ЛЮБИТЕ КУПЕРОВ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять».
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 Спектакль «Бәхеткә биш минут кала». 16+
9.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Дамир Сираҗиев турында телеочерк. 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Tatarstan today. Дөньяга ачык». 12+
14.20, 21.50 Спектакль «Гаугалы гаилә». 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Заповедники РФ». 12+
6.00 «Нанолюбовь». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Сергей Радонежский. Земное и небесное». 16+
8.45 «ЦВЕТЫ ЗЛА». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «КРУЖЕВА». 12+
14.45 «Блин.Ком. Некоторые любят погорячее». 16+
15.45 «ВЕТЕР В ЛИЦО». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЖАНДАРМ В НЬЮ-ЙОРКЕ». 16+
22.45 «ЛЮБОВЬ ДЛЯ БЕДНЫХ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Произвольная программа». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Играем свадьбу!» 12+
11.05 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
12.15 «Повара на колесах». 12+
13.10 Лев Лещенко, Александр Серов, Надежда Кадышева, Николай Басков в праздничном концерте ко Дню работника сельского хозяйства. 12+
15.10 «НАЧАЛО».
16.55 «1993. Осень в огне». 16+
19.00 «Перепой звезду». 12+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»
23.45 К 150-летию Алексея Щусева. «Тайна архитектора №1». 12+

«РОССИЯ»
6.05 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО МАЙОРА БАРАНОВА». 16+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
12.00 «Большие перемены».
13.00 «ДИРЕКТОР ПО СЧАСТЬЮ». 12+
17.50 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.15 «ЕДИНСТВЕННЫЙ МУЖЧИНА».
9.30 Диалоги о животных.
10.10 «Рина Зеленая. Несравненная ЕкатеРина».
10.50 «ПОДКИДЫШ».
12.00 «Настоящее-прошедшее. Поиски и находки».
12.30 «Ставропольский край. Из Кисловодска к Бештау».
13.10 Невский ковчег. Теория невозможного. Осор Будаев.
13.40 «Игра в бисер» «Александр Блок. «Скифы».
14.20 «Коллекция».
14.50, 23.45 «СИНЕВА В СИНЕВЕ».
16.25, 23.10 «Три минуты тишины».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.15 «Пешком...»
17.50 «Прощай, ХХ век!»
18.35 «Романтика романса».
19.30, 19.45 Новости культуры.
20.25 «Романс о влюблённых». Никто не виноват!»
21.05 «РОМАНС О ВЛЮБЛЕННЫХ».
23.15 «Краснодар. Особняк Василия Рубежанского».

«НТВ»
4.45 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер! Суперсезон». 6+
23.35 «Звезды сошлись». 16+

Адәм баласына кул селтәү, аны читкә этәрү хак гамәл түгелдер. Шулай да, күп тапкыр авыр җинаять кылучылардан ераграк тору хәерлерәк. Ләкин явыз рецидивистлар да дус-ишне таба. Алар чираттагы җинаятен дә үз даирәсендәге кешеләргә карата кыла.

Бөкрене төрмә турайтмый

1970 елгы Альберт Вәлиев Ташкент өлкәсендәге Алмалык шәһәрендә туып үсә. Беренче җинаятен шунда кылып, 14 яшендә өч елга ирегеннән мәхрүм ителә. Гаҗәп, ләкин ул колониядә утырганда әлеге срок кимисе урынга арта бара, чөнки алданрак эшләнгән явызлыклары ачылып, яисә колониядә җинаятьләр эшләп, шул исәптән, надзирательләргә каршылык күрсәтеп, яңа хөкемнәргә тартыла. Әйтик, бер ел утырганнан соң өч еллык срок 6 елга, тагын өч елдан 9 ел ярымга җитә, хәтта 13 елга ирегеннән мәхрүм ителүе турында да игълан ителә. Димәк, вак-төяк хилафлыклар түгел, үтерү, кеше сәламәтлегенә зыян китерү, ир кешене көчләү, талау һ.б. авыр җинаятьләр була бу. Шул рәвешле, йөгәнсез бәндә Красноярск крае, Чита, Иркутск өлкәләре, Үзбәкстан судлары тарафыннан 8 мәртәбә хөкем ителеп, тоташтан диярлек 29 ел гомерен колониядә уздыра һәм 2013 елда азат ителә.

А.Вәлиев шул ук елны Әлмәт якларына кайтып урнаша. Бу инде өметсез кеше җинаятьләрен Татарстанда кыла башлагандыр дигән фикер уята. Хәтта гаҗәпсенергә туры килә, 2019 елда үтерү белән янаган өчен 320 сәгатьлек мәҗбүри эшләр бирелүен исәпкә алмаганда, ун ел буена хөкемгә тартылмый ул. Шул районндагы Васильевка авылында бер хатын-кыз белән яши, 2015 елда уртак кызлары туа, Әлмәттә балык эшкәртү оешмасында эшләп йөри. Аралашкан кешеләре Альберт турында тупас, ярсып китүчән, җәнҗалчы, еш эчүче, көнче икәнен сөйли.

Холыксыз ир хатыны белән дә озак тора алмый. А.Вәлиев аның өеннән чыгып киткәч, кайда туры килсә шунда яшәдем, ди. Танышлары исә Әлмәттә тулай торакта торды, диләр. Иш-ишен таба дигәндәй, соңгы вакытта ире белән аерылышып, балаларын аның белән калдырып аерым яшәүче хатын белән тора. 35 яшендәге Екатеринаның (кайбер исемнәр үзгәртелгән) үзенә тиң, ягъни шулай ук балаларын иренә калдырып Әлмәт читендәге Урсала бистәсендәге агач йортта аерым торучы дусты Эльмира бар. 1977 елгы ошбу хатын Альбертны да яхшы белә.

Быел 28 июньдә дус хатыннар, үзләре әйтмешли, ял итеп алырга була. Шул нияттән Эльмира иртәнге якта ук Катя фатирына килә, тиздән төнге сменадан Альберт кайтып керә. Күп тә үтми, хуҗабикәнең күптәнге танышы Руслан Фәхриев пәйда була. Дүртәүләп сыйланырга керешәләр. Бераздан кунак ханым шешәдәшләренә үз өенә кайтырга тәкъдим итә. Дүрт кеше такси белән Урсалага китә, мәҗлес анда дәвам итә.

1989 елгы Р.Фәхриев та элегрәк шул ук балык эшкәртү цехында эшләгән, соңгы вакытта шабашкаларга йөргән, хатыны, баласыннан аерылып, әти-әнисе белән яшәгән. Беркайчан да хөкем ителмәгән ир-ат турында туганнары уңай фикердә, аны әлеге мәҗлестәге ике хатын да мактый, исерек булса да сүгенмәде, тупас кыланмады, диләр. Әмма аның хәмергә хирысылыгын кире кагып булмый, ошбу сәрхүшләргә кушылуы да шуның сәбәбе. Әлеге эчкечеләр җыены да аяныч тәмамлана.

Ике хатын-кыз А.Вәлиевнең кызып китү сәбәбен бер төрле аңлата, аның көнчелек мәсьәләсен телгә алмый. А.Вәлиев «сожительница»ның күптәнге дусты килеп керүен хупламагандыр һәм бу вәзгыятьнең кискенләшүенә этәрми калмагандыр кебек. Кыскасы, бер мәлне салмыш Альберт исергән Катяны күп эчәсең дип әрепләргә керешә, ошбу «тәрбия чарасы» ярамаган сүзләр кычкырып башкарыла. Шул вакытта Руслан Катяны яклагандай итеп, 53 яшендәге агайга шелтә ташлый. Таза гәүдәле Альберт кечерәк буйлы Русланны, кисәк уңаченнән алып, кухнядан түр бүлмәгә өстерәп кертә, сугып ега һәм ир-ат хәрәкәтсез калганчы бик озаклап тибә.

Авыз-борыныннан кан киткән Р.Фәхриев урыныннан тора алмый, тегеләр өнсез кешене исерек булганга йокыга талган, дип уйлый. Соңрак, хуҗабикә Эльмира, аннан соң парлылар йокларга түнә. Хуҗа хатыны иртүк Альбертны уятып баш төзәтергә тәкъдим итә. Идәндәге Руслан янына килүче булмый, һаман йоклый дип белдәләр.

Эльмира рецидивистан шикләнә башлый, ул хәмергә чыгып киткәч ишекне бикләп куя. Ләкин ярсу ир кухня тәрәзәсен ватып кереп тавыш куптара, бераз эчкәннән соң тынычлангандай була. Ул яңадан кибеткә киткәч, Эльмира өеннән чыгып шыла һәм балалары янына Әлмәткә китә. Икенче көнне, 30 июньдә Эльмира Катяга шалтырата, аңа Альберт җавап бирә, Руслан турында сорашкач, аның үлүен әйтә, бу хакта беркем дә белергә тиеш түгел дип лыгырдый. Алар Р.Фәхриевның тәне салкын икәнен ачыклап, өстенә җәймә япкан була. Кирәкле оешмаларга Эльмираның аерылышкан ире хәбәр итә, хатынны Урсалага илтеп тә куя. Эльмира үз өенә табиблар белән керә, кухня өстәле артында берни булмагандай эчеп утырган Лиза белән Альберт күренә.

Суд-медицина экспертизасы 34 яшьлек ир-атның иң элек баш миенә кан саву нәтиҗәсендә җан бирүен белдерә. 28 июнь кичендә кыйналган Р.Фәхриевның 30 июньгә каршы төндә үлүе мәгълүм була. Бер тәүлек буе исән килеш ятканга, аның канындагы этил спирты да чыгып бетә язган була. Эксперт мәрхүмнең яңак сөяге, өч кабыргасы сыну, башында биниһая күп җәрәхәтләр булуын күрсәтә.

А.Вәлиев кыйнавын таный, 8 яшендәге кызы булуын исәпкә алуны сорый, ошбу балага даими рәвештә акча җибәреп торуын әйтә. Исерек булганга көннәрне дә, кыйнавының сәбәбен дә буташтырып сөйли. Ишекне ачмаганга ачуым килде, хатыннар йоклый, Руслан гына эчеп утыра иде, тәрәзәне ватып кергәч, шул ачудан дөмбәсләдем, дип бара. Аннары өйдә башка кеше булмады, дип барысын да үз өстенә ала. Тикшерү комитеты тикшерүчесе Салават Сөнгатуллин аны аңлы рәвештә үтерүдә гаепли. А.Вәлиев үтерергә теләмәдем, дип килешми, җиңелрәк җәзага өметләнә. Җинаять эше шәһәр суды каравына тапшырылды.

* * *

Бу елның январь аенда Әлмәттә өч рецидивист һәм бер хатын-кыз катнашындагы хәмерле мәҗлес тә фаҗигале тәмамлана.

33 яшьтәге Сергей Чатуров яшьтән наркотиклар куллана, шул зәхмәт белән бәйле җинаятьләр кылып берничә тапкыр утырып та чыга, соңгы тапкыр Чиләбе өлкәсендәге колониядән узган ел азат ителә. 1955 елгы әнисе аның эшләмичә туктаусыз эчеп йөрүеннән зарлана, ун ел элек аерылышкан хатыны, ике баласы белән аралашмавын, аларга ярдәм итмәвен әйтә. Туганнары алып биргән бер бүлмәле фатирда яшәүче хөрәсән, Түбән Мактамадагы наркология диспансерында 20 көн дәваланып, быел 10 январьда чыга. Ләкин эчүдән туктамый, бичара анасы тәрбиясендә яши, өлкән яшьтәге апа көн саен диярлек шәһәрнең икенче почмагыннан аңа ашарга китерә, юасы керләрен алып, фатирын җыештырып китә.

16 январьда да була ул анда. Юньсез малаена фатирны пычратмасыннар өчен сәрхүш дусларын кертмәскә киңәш итә. Әмма эчкече Сергей шешә кыстырып килгән кешеләрне борып җибәрә алмый... Әни кеше икенче көнне кичкә таба такси белән тагын килеп җитә, чөнки улының телефоны җавап бирми. Үз ачкычы белән ачып фатирга кергәч, юыну бүлмәсенә таба сузылган кан тапларын күреп кире борыла, полициягә хәбәр итә. Алар белән бергә кергәч, киенгән килеш ваннада утырган Сергейны күреп, бер мәл өнсез кала, табиблар аның үле икәнен рәсмиләштерә. С.Чатуровның кыйнап үтерелүе сукыр күзгә дә күренә. Экспертиза мәрхүмнең башына зыян ясалу, күп кан югалту аркасында үткән төндә үлүен күрсәтә. Химик тикшерү аның канында наркотик матдәләр булмавын ачыклый.

Җинаятьне ачуда подъездагы видеокүзәтү җайланмасы ярдәм итә. Полиция оперативнигы А.Фазлыев язмадагы берничә мәртәбә кереп-чыгып йөргән ике ир-ат, бер хатын-кыз арасында Андрей Лопаткинны танып ала. 1986 елгы ир бер ай элек кылынган урлашуда төп шикләнелүче зат буларак тикшерелә. Ул гына түгел, А.Лопаткин - «вымогательство» дигән талауда катнашып, 15 яшендә өч елга ирегеннән мәхрүм ителгән һәм амнистиягә эләгеп җәзадан котылган кеше. 20 яшендә төркем белән кеше үтерүдә гаепләнеп, 15 елга утыртылган, әле 2021 елда гына азат ителгән явыз бәндә ул. Әлмәткә кайткач, Андрей әнисе һәм шулай ук кеше үтергән өчен утырып кайткан абыйсы Александр белән яши. Видеоязмага эләккән икенче ир-ат өч яшькә өлкәнрәк А.Лопаткин, ә хатын-кыз - аның сөйгәне Алсу Вафина (исеме үзгәртелә) булып чыга.

Ике шаһит кыйнаучының Андрей икәнен таный, моны ул үзе дә кире какмый, бары тик аеруча авыр зыян салган ике җәрәхәтнең ул сугу аркасында түгел, ә егылганда башы белән тумбочкага бәрелү нәтиҗәсендә ясалган дигән фикерне алга сөрә. Рецидивист саксызлык белән үтерү дигән җиңелрәк җинаятьтә генә гаепле булып калырга тырыша.

С.Чатуров белән ярты ел чамасы элек танышкан була ул. Мәгълүм ки, ялгызы яшәүче сәрхүшләр эчкечеләр арасында абруйлы санала, чөнки алар сыеныр урын бирә. 16 январьда ике Лопаткин белән А.Вафина ишегалдында өчесенә бер литр аракы эчәләр. Салкында туңа башлагач, Андрей С.Чатуровка шалтырата, анысы ике ярты аракы тоткан өч кунакны куанып каршы ала.

Эчә торгач, тәҗрибәле төрмәчеләр бик «житди» мәсьәлә буенча бәхәсләшә башлый. Сергей агалы-энеле Лопаткиннарны колониядә утырганда андагы тәртипләрне үтәп, җитәкчеләр белән хезмәттәшлек иткән «красные» дип йөртелүче түбән дәрәҗәләргә рәтенә куя, ә үзен кагыйдәләрне санга сукмаучы абруйлы «черные» арасында дип белдерә. Ошбу кимсетү 15 ел утырып кайткан Андрейны чыгырдан чыгара. Нәтиҗәдә, хуҗаны дөмбәсләргә тотына, арага кереп маташкан Александр белән Алсуны «ераккарак» озата. Аннан соң агай-энеләр канга баткан Сергейны өстерәп ваннага алып керә. Аннары кибеткә китәләр, кайткач, ваннадагы мәетне күрәләр. Ишекне бикләп, өчесе дә Лопаткиннар фатирына кайтып йоклый...

Андрей үтерергә теләмәдем дип, аңлы рәвештә үтерүен дә кире кага. Әмма Әлмәт шәһәр судында гаепләү ягы фикеренә өстенлек бирелде. А.Лопаткинны 10 ел ярымга кырыс режимлы колониягә озатырга дигән хөкем карары игълан ителде.

Наил ВАХИТОВ.

Рәсемнәрдә – заман сулышы

9 августта халыкара каллиграфия көнен «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә күргәзмә оештырып, беренче тапкыр без дә билгеләп үттек. Экспозициянең бер өлеше 1920 еллар графикасына багышланган иде, чөнки графика һәм каллиграфия бер-берсеннән аерылгысыз, ике бертуган сәнгать төрләре дип әйтергә мөмкин. XX гасыр башы иҗат әсәрләрен графика сәнгате буенча белгечебез, сәнгать фәннәре кандидаты Ольга Улемнова әзерләгән.



● А.Коробкованың «Азат хатын» журналы тышлыгы эскизы.

Казан ханлыгы яулангач юкка чыккан каллиграфияне торгызу башкалабызда 1840 елда Казан университетында шәрык телләрен өйрәнү факультеты оештырылгач башлана. Университетта укучыларга каллиграфияне өйрәтү өчен мәдрәсә тәмамлаган Мөхәммәтгали Мәхмүдовны чакыралар. Матур язу остасы, педагогика буенча күпләгән хезмәтләр авторы, абруйлы мөгаллим Гали Мәхмүдов ул вакытта университетта татар милләтеннән һәм югары белеме булмаган бердәнбер кеше була, ди аның тормыш хәлен өйрәнгән галимә Фирдәвес Ваһапова. Шәрык факультетын Санк-Петербургка күчергәч Гали Мәхмүдов шәһәрнең 1 нче гимназиясендә укыта башлый, аның директоры була. Соңрак исә Казанда татарлар өчен беренче дөньяви уку йорты – укытучылар мәктәбен оештыра. Нәкъ шул мәктәпкә мәдрәсә тәмамлаган Шакирҗан Таһиров укырга керә. Соңрак ул мөгаллим булып танылачак, татар һәм төрек телләрен укыту буенча дәреслекләр язачак. Әмма безнең өчен бу очракта барыннан да бигрәк аның, махсус профессиональ белеме булмаса да, гадәти мәктәпләрдә рәсем дәресе укытырга рөхсәт алуы, моның өчен житди әзерләнүе әһәмиятле. Шулай итеп Шакирҗан Таһиров милләттәшләребез арасыннан чыккан беренче рәссамнардан дисәк тә була. Һәм бу дәрәҗәгә ирешергә аңа матур язу остасы Гали Мәхмүдов ярдәм итә, рәсемгә осталыгын күреп, шәкертне үстерү җаен карый. Шакирҗан аганың улы Фаик исә чып-чын рәссам буларак танылa. Бүген аның графикасы Россия график сәнгате кысаларында өйрәнелә. Каллиграфия һәм графиканың бер-берсе белән тыгыз бәйләнешен шушы өч шәхеснең тормышы мисалында да күрергә була. Экспозициядә нәк менә Фаик Таһировның һәм аның хатыны, иҗатташы, шулай ук талантлы рәссам Александра Коробкованың иҗат әсәрләре һәм тагын бер милләттәшебез керәшен татары Дмитрий Красильниковның иҗат әсәрләре урын алган.

1920 еллар уртасында газета-журналлар күпләп басылу график рәссамнарга иҗатларын үстерергә мөмкинлек бирә. Фаик Таһиров, мәсәлән, гарәп язуын реформалау буенча зур хезмәт башкара һәм тиешле оешмаларга юллый, әмма аның бу хезмәтләре игътибарсыз кала һәм вакыт үтү белән югала. Иҗатының башлангыч чорында Фаик Таһиров китап, журнал бизәлешләрендә гарәп шрифтын гына кулланса, аерым алганда конструктивизмга бик кулай булган куфи стиленә игътибар бирсә, соңрак Александра Коробкова белән бергә иҗат итә башлагач, алар бизәгән журналларда рәсемнәр дә пәйда була.

Сурәтләр XX гасырның китап-журналларын, график сәнгатьне күзалдына китерергә ярдәм итүе белән генә түгел, ул елларның идеологиясен чагылдыруы белән дә зур кыйммәткә ия. Берсендә, мәсәлән, пәрәнҗәләргә төренгән бер төркем хатын-кызлар, кызыл әләмнәр күтәреп, югарыга Ленин бабай сурәтләнгән тарафка баккан. Әләмнәрнең берсендә, яшәсен шәрык хатын кызларын азатлыкка алып чыккан Ленин партиясе, дигән язу күрәбез. Илдәге милләтләрнең ул елларда азатлыкка чыкмаганын, бер капкыннан икенчесенә килеп капканын хәзер аңладык-аңлавын. Элек-электән, ата-бабалардан килгән гореф-гадәтләр, гаилә мөнәсәббәтләре җимерелүнең, милләтне бетүгә илткән катнаш никахларның башы булганын хәзер үз күзләребез белән күрәбез. Әмма ул чорда идеология белән агуланган милләттәшләребез азатлыкка чын-чынлап ышанган бит. Хәзер дә ышана, идеология генә башка...

Еллар үтәр, бүген без Таһиров-Коробковаларның рәсемнәрен алып караган кебек, киләчәк буыннар бүгенге ялгышуларыбызның сурәтләрен карый алырмы, дигән сорау да тынгы бирми...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

● А.Коробкованың «Азат хатын» журналы тышлыгы эскизлары.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип өчен В. ИМАМОВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 29.09.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2540 данә

Заказ 2637

16+